PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2015 СЕНТЯБРЬ № 9

СӨЕМБИКӘ


«ЗӨЛӘЙХА КҮЗЛӘРЕН АЧА»
Россиянең «Ел китабы»

«КҮҢЕЛЕМДӘ ИКЕ ЯЗ»
бер караштан туган җыр

РӨСТӘМ ЗАКИРОВ
дуслар күп, хатын бер генә

Алинә ШАКИРОВА:

«МИН – ТАТАР КЫЗЫ!»



PRESSA.RU



70
1945–2015

Сугыш язган хатлар

«Сугыш башланганда без гаилә белән Васильевода ял итә идек. Әти шул көнне үк өйгә кайтып китте, — дип сөйли Илгизә апа. — Судья булып эшли иде, аңа бронь бирделәр, әмма әти ул хакта ишетергә дә теләмәде: «Шушы озын буем белән оялмыйча ничек монда халык алдында йөрим?» — диде. 1941 елның 22 августында бер сәгать эчендә җыенып чыгып китте ул... Миңа берәр сумнан тугыз сум акча биреп калдырды. Шуңа сөенгәнем истә. Тугыз яшьлек балага соң... Хатларны ул бик еш язды. Көн саен диярлек! Төш күрдем, әти яна торган мунчага кереп китте. Әни кушканча, төшемне чыгып җилгә дә сөйләгән идем дә бит... «Кара кәгазь» безгә март аенда килде.

Хаят җаным Илгиза кызым

«Хаят җаным, Илгиза кызым! Сезгә кайнар сәлам. Үзем исән-сау, сәламәт кенә Кызыл Армия сафларында хезмәт итәм. Сезнең язган хатларыгызны алып укыдым, бигрәк тә Илгизаның отличнога укыйм дигән сүзләрен күреп шатландым. 30.09 да салган 300 сум, 10.10.41 дә салган 400 сум акчаны алгансыз икән, бик яхшы булган. Болардан тыш 18.11.41 дә 500 сум, 31.12.41 дә 500 сум акча җибәргән идем. Бу суммаларны да алгансыздыр. Шулай ук военкомат аша һәр айны 800 әр сум акча алу өчен ценный хат белән аттестат җибәргән идем. Хаят, Илгиза! Зариф абыйларга миннән күп сәлам диген. Мин сезгә истәлек өчен бик начар гына төшкән ике данә карточка җибәрәм. Әтиләрдән хат аласыңмы, әйтеп яз. Хаят, миннән хат алгач, пока хат салмый тор, иске адрес белән. Кайнар сәлам белән сезнең Хәбиб. 21.01.42»

«Җанкисәкләрем Хаят һәм Илгиза! Менә бүген мин сезнең 23, 24.03.42 язган ике хатыгызны алып укып бик шатландым, сезнең тормышлар белән таныштым. Гомумән, соңгы вакытта хатны бик еш алам һәм үзем дә язам. Хаят! «Бер хатыңда «авыртам» дип язган идең, шуннан соң сине кайтыр дип көткән идек» дип язасың. Моңар җавап итеп бер-ике сүздән аңлатам. 1. Минем армия сафында хезмәт итә башлаганнан бирле һич тә авыртканым юк, сәламәтлегем яхшы. 2. Бөек Ватан сугышында минем илем өчен, халкым өчен, Бөек Сталин өчен, сезнең һәм үземне, туганнарым өчен, киләчәктә бәхетле тормыш өчен актык сулышыма кадәр фашист этләре белән көрәшәчәкмен. Ул фашист җирәнгеч, ерткыч. Шушы теләкне тормышка ашыру өчен сез тирән тылда исәпләшмичә фронтка ярдәм итәргә тиешсез. Шулаймы, җаным? Аннан соң Илгизага төрле уенчыклар, төрле кызык китап алып, аны үстерергә кирәк. Гомумән, аңар бөтен мөмкинлекләр булдыру кирәк, ул мөмкинлекләр бездә бар.»

«Хаят! Моннан алда язган хатыңны үпкәләгәндәрәк язгансың дисең миңа. Юк, җаным, һич тә алай үпкәләгәнем юк. Әгәр дә үпкәләсәм, сезне сөймәсәм, яратмасам көн саен хат язмас идем. Ярый, хушыгыз, тиз-тиз хат языгыз. Яхшы торыгыз. Сезне үбеп, Хәбиб. 9.04.42 ел. Адрес әүвәлгечә.»

«Хаят җаным, акыллым! «Илгиза соңгы көннәрдә сине бик сагына һәм бик ябыкты» дип язасың. Сагынгандыр, мин дә сагынам. Шулай да ул сагынуларны без искә алырга тиеш түгел, чөнки күп миллионлаган иркенлек сөючән бөтен совет илендә яшәүче халкыбыз фашист этләренә үзенең нәфрәтен белдерә һәм иле өчен, киләчәктә үзенең бәхете, иркен тормышы өчен көрәшә. Мондый вакытта сагынып тору һәм уйлау урынсыз. Бездә бер уй булырга тиеш: ул да булса фашист этләрен юк итү. Сәлам белән сезне кысып-кысып үбеп, Хәбиб.»

(Хәбибулла САФИУЛЛИНның фронттан язган хатлары Мамадыш районы Түбән Тәкәнеш авылында яшәүче бердәнбер кызы – Илгизә ИСХАКОВАда саклана. Хатлар кыскартылып, язылу стиле үзгәртелмичә бирелә.)



Действующая Красная армия

Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз. Сайтыбыз аша сугыш кырларында ятып калган якыннарыгыз турында мәгълүмат таба аласыз.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты.
1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде.
Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Алинә Шакирова
Фото: Эрик Асаев

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Газинур Хафизов
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 4.09.2015 ел.
Заказ О-2451.
Тираж 6236.

Учредитель:
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU



Марсель ГАЛИЕВ

Этюд

Газоннарда – яфрак көшелләре,
Тып-тын яна җәйнең хәтере.
Күз, Кояшка сары учын сузып,
Үтеп барган вакыт кадерен
Искәртте дә... Якты балкыш булып,
Кулләвеккә төште өзелеп.
Көзге моңнар узды биекләрдән, –
Ноталары калды тезелеп.
Сагышлану кая бу киңлектә,
Нинди чиксез аяз һавалар!
Карашымны чигеп күк йөзенә
Экваторга очты торналар.







«Көзге элегия». Мәдияр Хаҗиев эше.

Салисә ГӘРӘЕВА

Көзге күлләр

Көз чагыла күлләр көзгесендә,
Сары толымнары иңендә!
Мин дә багам суга, чал Иделгә,
Көз миңа да килде, димен дә!

Ак томаннар сарган су буйларын,
Чыклар төшкән җиргә мул булып.
Көзләр күзе суда, мул чыклары
Керфегемә сеңгән моң булып.


Казансуның аргы ягы – серле,
Ак томанда коена урамнар.
Шәһәремне әкияттәге кальга,
Таш кала дип була уйларга.

Бакчаларда сары каеннарның
Парча киемнәре алтыннан.
Бөтен тирә янып китәр төсле
Усакларда янган ялкыннан!


Көзге кичләр килә көттермичә –
Кояш инде офык артында!
Үзе юк, ә биек болытларны
Буяп куйган кызыл алтынга.

Яфракларның тамчы кандай кызыл
Таплар булып коелган чагы;
Көз – дөньяның яңгырларда, моңда,
Сагышларда коенган чагы!

Учакларның очкын сикерткәләп
Ялкынланып дөрләгән чагы.
...Туган җирдә уңыш бәйрәменең
Шатлык булып гөрләгән чагы!



PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





КЕШЕ КАЙЧАН МАТУР БУЛА?
Р. Галләмова
24

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8
ЭШЛИСЕ ЭШЛӘР КҮП ӘЛЕ!
М. Авзалова

16
БАЛА КҮҢЕЛЕ – ДАЛАДАМЫ?..
Л. Хәерова





12
БДИ ДИГӘН СЫНАУ
Ф. Мостафина

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ






20
МАДАМ САДОВИНОВА
Г. Хәсәншина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ



30

ЗӨЛӘЙХА КҮЗЛӘРЕН АЧА
Г. Яхина

ЯШӘЕШ



44

«МИН СИНЕ КИЧЕРДЕМ...»
М. Авзалова

48



СҮЗ ХИКМӘТЕ
Р. Камалетдинова

ШУЛАЙ УК:

38

МӘЧЕТТӘ
Р. Гасыймова

42

КҮҢЕЛЕМДӘ ИКЕ ЯЗ
Р. Гаташ

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ



ГАЕТ СЫЕ

58

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА:

ОЧРАШУ УРЫНЫ – МИЛЛИ КИТАПХАНӘ.

КУБА – МӘХӘББӘТЕМ МИНЕМ. Милләттәш.

«МИН СИНЕ ШУНДЫЙ САГЫНДЫМ». Бер җыр тарихы.

ЭНӘ КҮЗДӘН СЫНАР. Язмыш.

ШАРФ-СНУД. Мастер-класс.



PRESSA.RU



Зөһрә әби белән урамда таныштык без. Даруханәдән кайтып килеше иде аның. Яше туксанга җитеп килсә дә, үз көнен үзе күрә икән әле.

«1925 елның 2 декабрендә Тәтеш районының Келәш авылында туганмын. Зөһрәбану дип исем куйганнар. Шөкер, туксанга җитсәм дә, үз аякларымда йөрим», – диде ул үзе турында. Сүз иярә сүз чыгып, сөйләшеп киттек тә, мине өенә үк чакырды. Өйдә яшьләрчә җитезлек белән чәй куеп җибәрде, табын әзерләде. «Сыйлан, кызым. Окоп казыган чакта паекны кулга алуга ук ашап куя идек тә, икенче көннең паегын көтә торган идек. Ачлык бик яман нәрсә», – дип, кыстый-кыстый чәй эчерә башлады. «Окопны кайда казыдыгыз соң?» – дим. «Тархан районының Бидәнге авылына төяп алып киттеләр. Икешәр-өчәр балалы хатыннарны да алдылар. Анда өч ай буе окоп казыдык. Атарга да өйрәттеләр. Инде сугыш уртасына ук алып китәләрме дип торганда, безне Казанга һөнәрчеләр училищесына укырга җибәрделәр. Мин буяу-штукатур эшен үзләштердем һәм шуннан ук безне – 300 кешене Горький шәһәренә төзелешкә җибәрделәр. Ә анда көн саен «тревога» була икән. Берсендә мине мастер базарга җибәрде. Барып керсәм, мәхшәр: кешеләр тараканнар урынына качыша. Күктә немец очкычы үкерә. Мин дә бер өстәл астына качтым. Ходай кызгангандыр, ул көнне ул-бу булмады.

Ә беркөнне... гомер онытылмаслык могҗиза булды – Горький урамында гармун тавышын ишеттем. Гармунга кушылып татарча җырлыйлар иде. Без, өч татар кызы, гармун тавышы килгән якка йөгердек. Барсак, ике егет һәм ике кыз урам буйлап гармун уйнап бара. Монда да татарлар бар икән бит! Горький мишәрләре! Иң якын туганнарыбыз белән очрашкандай, кочаклашып күрештек. Аннан үзебез яшәгән тулай торакка кайтып, әй биеп тә күрсәттек соң. Башка милләт кешеләре, исләре китеп: «Сез артистлармы әллә?» – диләр. Милли моңның, туган телнең кирәген аңламаучылар күп бүген. Соңгы өметең өзелгәндә дә яшәү утын тергезеп җибәрү көче бар аларда.

Горький шәһәреннән безне өч төркемгә бүлеп, өч шәһәргә җибәрделәр. Казанга кайттым дип сөенергә дә өлгермәдем, Суслонгерга – урман кисәргә җибәрделәр. Андагы авырлыкны сөйләп аңлатырдай сүзләр таба алмам мин, кызым. Кышкы салкында агач төпләрен кардан-боздан көрәк белән көрәп ачабыз. Кул пычкысы белән кисеп аударабыз агачларны. Трактор аларны, буе белән сөйрәп, эшелонга төяргә илтә. Шул бозлы бүрәнәләрне вагоннарга да кул белән төйибез бит. Бар да тиз кирәк – фронт көтә. Булмый дигән сүз бөтенләй дә юк иде ул чорда. Бозланып каткан киемнәрне көчкә сөйрәп, йокларга салкын клубка кайтып егылабыз».

16 яшендә киткән кыз, Казанга 1948 елда – инде 23 нче яше белән барганда гына кайта. 22 нче заводка эшкә урнашып, Нәҗип атлы егет белән гаилә кора. Беренче кызлары туугa, Нәҗипне армиягә алалар. «Чынлап ярата алмадым мин аны, – ди Зөһрә апа. – Армиядән сагынып көтеп алырмын дип өметләнгән идем, алай булмады, хисләрем кабынмады. Шулай да аның белән гомер иттек, өч балабыз туды». Зөһрә әби балалары хакына хисләрен эчкә бикли. Бар көчен гаиләсенә сарыф итә. Әмма гомере буе «яратам» сүзен чынлап та яраткан кешесенә әйтәсе килеп яши. «Иремә карата олы хисләр кичереп яшәмәвем кызларыма да тәэсир иткәндер. Бик тәртипле, уңган булсалар да, бүген бер генә кызым гаиләле. Калган ике кызым белән завод биргән өч бүлмәле фатирда бергә яшибез. Горькийда Вафин абый белән Гыйбадуллин абыйлар бар иде. Исемнәрен гомер белмәдем шуларның. Шулар: «Э-эх, кызлар! Яшьлегегез әрәм була...» – диләр иде. Шул сүзләрнең асылын хәзер аңладым. Туган Җир, Туган Тел, Милли Моң, Мәхәббәт – шуларның берсе генә булмаса да, кешенең рухы бөтен була алмый икән. Хәзер авылга кайтам да, аптырап калам: сугышсыз-нисез җимерелгән авыл. Дүрт ферманың берсе генә дә юк бит. Шул туган авыл исән булсын өчен тәмуг газаплары кичтек түгелме соң без? Әйтәм бит, үлсәң дә, туган туфракта үләсе килә икән».

Зөһрәбану апа яныннан өйгә кайту юлым кыска гына булса да, әллә никадәр уй йомгагым сүтелде. Хәзерге заман кешеләренең күпләренә хас битарафлыкның әсәре дә юк иде бу гап-гади татар апасында.

Нәҗибә САФИНА.
Казан.

Яшьлек таңында кавышып, картайганчы тату-матур яшәгән гаиләләр була. Алар – балаларга үрнәк, туганнар өчен – шатлык, күршеләр өчен таяныч.

Мәдинә апа белән Габделсамат абый Насыйбуллиннар гаиләсе дә шундый үрнәк гаиләләрнең берсе. Алар 57 ел бергә гомер итәләр.

Габделсамат абый С. Горбунов исемендәге Казан авиация берләшмәсендә эшләде. Ә Мәдинә апа исә гомере буена балаларга белем бирде. Нәселләре белән укытучылар алар. Мәдинә апа Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлагач, Мордовия Республикасына эшкә билгеләнә. Аннары Казанга кайтып, 112 нче, 115 нче мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укыта.

Габделсамат абыйның әти-әнисе бик динле була. Шуларның хәерфатихасы аларга тормышта әледәнәле ярдәм итеп тора. Венгриядә хезмәт иткәндә Габделсамат абый аздан гына үлемнән кала. Хәрби укулар вакытында пуля колак яфрагына орынып үтеп китә. «Әтием Хәлиулла белән әнием Хотбикамалның догалары гына алып калгандыр», – ди ул бу хәл турында. Дин тыелган заманнарда Хәлиулла абый намазын базга төшеп укый торган була. Габделсамат абыйлар ун бала үсәләр. Әле хәзер дә бәйрәм саен төп йортка җыелышып, туганлык җепләрен өзми яшиләр. Габделсамат абый бик матур итеп Коръән укый. «Матур-тату яшәүнең сере – хөрмәт. Без бер-беребезнең күңел халәтен аңлап, бер-беребезнең күңелен кителүдән саклап яши белдек. Ул – мине, мин аны юк-барга борчымадык. Үзем гомеремдә эчмәдем, тартмадым. Улларымны да шулай тәрбияләргә тырыштым. Татулыкның тагын бер сере – сабырлык. Сабыр булып кала белсәң, бәхетең түгәрәк булыр», – ди Габделсамат абый, бәхетле яшәүнең серен сорагач.

Алар яшәгән йорт каршында гына пар каен үсә. Габделсамат абый белән Мәдинә апа шул каеннарга карап торырга ярата. Үзләре белән бергә картаеп барган шушы каеннар кебек, алар да җиленә дә, давылына да бергә түзделәр. Давыллар аларны сындырмады, чыныктырды гына.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Казан.

«Сөйкемле, әдәпле, тәртипле, горур, акыллы, җитез». Менә шундый матур сүзләрне әйтүче һәм безне дә әйтергә өйрәтүче кешебез бар безнең Пермь шәһәрендә. Ул – «Чулпан» балалар бакчасы мөдире Фәүзия Сөнгат кызы.

Без, тәрбиячеләр, «Сөембикә» журналын инде ничә еллар алып укыйбыз. Сезнең белән бергә сөенәбез, шатланабыз, борчылабыз. Моңарчы газета-журналларга бер дә хат язганыбыз юк иде. Бу хатны язуыбызның исә сәбәбе зур. Быел Фәүзия апабызга 70 яшь тулды.

Фәүзия Сөнгат кызы Пермь шәһәренә 1967 елны Татарстаннан – Әлмәт районының Урсалабаш авылыннан килеп урнаша. Ул инде 43 ел балалар бакчасында, шуның 32 елын җитәкче булып эшли. Өлкәбездә татар балалар бакчасы күп, ләкин Пермь шәһәрендә ул берәү генә – без эшләгәне генә. Иртә яздан алып, кар төшкәнче аллы-гөлле чәчәктә утыра ул. Әле бездә чикләвек куаклары да үсә. Ул чикләвекләрне Фәүзия апа Урсалабаш тавыннан алып килеп утырткан.

«Милли татар бакчасы ачып, татар төркемнәренә балалар җыеп, тәрбиячеләр эзләп, без татар бит, телебезне белергә кирәк, дип чабачаба, гомерләр дә үтеп киткән», – дип әйтеп куя кайчак Фәүзия апа. Җай чыкты исә үзенең туган авылын сөйли ул. Җиләкле, имәнле, каенлы, чикләвекле, чияле тауны сагына. «Иртән чык кипкәнче олы чиләкне тутырып җиләк җыясың да, таудан туп-туры елгага шуып төшәсең. Үзе сап-сай гына елга инде ул, ә үзе шундый да газиз. Безнең авыл елгасы ла ул! Балыклары да бар – үзебезнең балыклар!» Әнә шулай итеп Фәүзия апа безне үзенең туган авылы Урсалабашка «алып китә».

Муса Җәлилнең шигырьләрен яттан сөйләргә ярата ул. Бакчабыздагы алан да «Муса Җәлил аланы» дип атала. Июль аенда шушы аланда печән чабу өмәсе уздырабыз, кунаклар чакырабыз. Пермьдә Татарстаннан килгән гаиләләр яши, менә шулар инде ул безнең яраткан кунакларыбыз. Күмер самоварлары куеп, үзебез чәкчәкләр, коймаклар пешереп, ел саен Сабан туе үткәрәбез. Болар бар да Фәүзия апаның тырышлыгы. Ул үзе үскән авылның шул чорга хас мохитен, рәхәтлеген бүтәннәр дә тойсын дип тырыша. Кая гына барса да, берсеннән-берсе матур чәчәкләр алып кайта ул. Шуны балалар белән бергәләшеп утыртабыз. Безнең әле «Татар йорты» дип аталган музеебыз да бар. Фәүзия апабыз чәчәк-куаклар үстерергә, аларны дөрес итеп кисәргә, печән чабарга, йон эрләргә өйрәтә. «Кызлар, эштән курыкмагыз, кеше өчен эшләсәң дә, үзең өчен өйрәнәсең», – дип әйтергә ярата ул. Бакчабызда Индус Таһиров, Римма Ратникова, Тәлгать Таҗетдин кебек шәхесләрнең кунак булганы бар. Мондый кешеләрнең килүе безнең өчен зур сөенеч һәм горурлык. Менә шулай итеп, руслашып беткән татар әтиәниләрне табып, аларның балаларын бөтен шәһәр буйлап җыеп, һәр ике буынны аз булса да татарча өйрәтергә тырышып яшибез. Фәүзия Сөнгат кызы Пермь өлкәсендәге татар авылларына да бара. 1995 елдан 2002 елга кадәр татар-башкорт иҗтимагый үзәгенең җитәкчесе булып эшләде. Ә хәзер инде «Ак калфак» оешмасын күтәрергә тырыша. Без, «Чулпан» балалар бакчасы хезмәткәрләре, Фәүзия Сөнгат кызын узган юбилее белән чын күңелебездән котлыйбыз. Исән-сау булып, безгә үрнәк булып, тагын бик күп еллар бергә эшләргә язсын иде.

«Чулпан» балалар бакчасы коллективы.
Пермь шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



























Форумнан фото- һәм видеорепортажны сайтыбыздан карый аласыз.

ЭШЛИСЕ ЭШЛӘР КҮП ӘЛЕ!

Мәдинә АВЗАЛОВА

АВГУСТ УРТАЛАРЫНДА «ТАТАРСТАННЫҢ ЭШЛЕКЛЕ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ» III ФОРУМЫ БУЛЫП УЗДЫ.

Былтыр Казанга — I Халыкара эшлекле хатын-кызлар конгрессына дөньяның 16 иленнән һәм Россиянең 14 регионыннан 400 дән артык вәкил җыелган иде.

Форум башланырга санаулы минутлар калып бара. Татарстанның горурлыгы булган «Казан» Халыкара ат спорты комплексының павильоны халык белән шыгрым тулы. «Республиканың икътисадый һәм социаль-мәдәни үсешендә хатын-кызның роле» дигән темага сөйләшүгә җыелган 200 ләп хатын-кыз арасында – эшмәкәрләр, депутатлар, төрле компанияләрнең җитәкчеләре һәм менеджерлары, дәүләт органнары, фирмалар, фондлар һәм иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре... Шул эшлекле ханымнар арасында мин дә эшем кешесе булып йөрим. Анда-санда танышлар да күзгә чалынып китә. Күп яздык без алар турында. Бизнесларын өчпочмак, пәрәмәч пешерүдән, урам чатында туңдырма сатудан башлаган эшмәкәрләребез хәзер әнә шәп рестораннар, зур-зур кибетләр тота. Ә кайсылары хәйрия эшләре белән бөтен илгә танылды. «Бүгенге татар сәнгате хатын-кыз кулы белән» дип аталган күргәзмә зәркән әйберләре, баш киемнәре, керамика һәм фарфордан бизәп эшләнгән савыт-сабалары, итекчүәкләре, шәмаилләре белән хәйран калдырды. «Сөембикә» журналы таныткан оста куллы туташханымнар эшләреннән тупланган иде ул.

Иң авыр чорда да, адым саен киртә булган заманда да һаман үргә үрләр көче каян табыла диген?! Хатын-кыз әнә шулай гомер буе серле һәм буй җитмәс булып кала бирә. Кешелекнең гүзәл яртысы белән генә нәселнең дәвам итүенә, гореф-гадәтләрнең, буыннар арасында элемтәләрнең саклануына берәү дә шик белдермәстер, дип уйлыйм. Хатын-кыз үзен шәп җитәкче буларак күрсәтмәгән бер генә өлкә дә юктыр ул бүген.

Эшлекле хатын-кыз нинди була?! Әлбәттә, ул – югары белемле, хәтта ике югары белемле. Әлбәттә, аның үз бизнесы бар. Әлбәттә, ул – хакимияттә җитәкче урыннар били. Өстәвенә, ул – иң әйбәт әни, кайгыртучан хатын да... Мәгълүматлардан күренгәнчә, Татарстанда яшәүче халыкның 46,2 процентын – ирләр, 53,8 процентын хатын-кызлар тәшкил итә. Без әле гайрәт чәчеп торган сөекле ирләребезгә караганда белемлерәк тә икән.

ТАССР Югары Советы Президиумы экс-секретаре Дания Дәүләтшинаның Валентина Терешкова белән берлектә башлап җибәргән хатын-кызлар хәрәкәте дәвамлы, гомерле булып чыкты.

Хәер, элеккеге заманнарда да хатын-кыз сынатмаган. Бер дә гомерен казан төбендә аш пешкәнен көтеп, бала чүпрәге юып кына уздырмаган. Мисал дисәк, үткәнебезгә, тарихыбызга бер күз төшереп алу да бик җитә. Әйтик, татар хатын-кызлары ирләр белән бер хокукта булмасалар да, хуҗалыкны бик шәп тотканнар, алыш-биреш алып барганнар, хәйрия эшләрен дә иң беренче булып нәкъ менә алар башлап җибәргән. Казан ханлыгы тарихыннан онытылмас шәхесләр – Нурсолтан белән Сөембикәне генә күз алдына китерик. Ул заман хатын-кыз белән ирләр арасында тигезлек хөкем сөргән чор буларак тасвирлана. Мөселман хатын-кызлары укыганнар да, укытканнар да, гыйльми дәрәҗә алуга да ирешкәннәр. Һәм иң кызыктыргыч ягы – хатын-кыз эшләп тапканын бары үз мәнфәгатьләренә тотса, ир-ат гаиләсенә кайтарып биргән. Шәп бит!

Әйтсәң дә юк, хатын-кыз тормыш кыенлыкларына күбрәк ярашкан. Бала-чага, гаилә турында кайгырту безнең өчен табигый ул. Авыр бер йөк буларак кабул ителми, дип әйтсәң килә. Өйрәнгән без моңа. Социологлар раславынча, эшмәкәр хатын-кыз криминаль структуралар басымына азрак эләгә, ул исеменә тап төшермәскә, эшен балалары хакына саклап калырга тырыша.

PRESSA.RU

«Без республиканың социаль, икътисадый, мәгариф һәм мәдәни проектларын тормышка ашыруда актив катнашырга тиеш. Безнең көч – бердәмлектә!» – диде форумны ачып җибәреп, туризм буенча Татарстан дәүләт комитеты рәисе урынбасары, «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» региональ иҗтимагый оешмасы президенты Лиана Сәетова.

Безнең көч бердәмлектә шул. Уңышларыбыз да бергә булуга, кеше хәсрәтенә, ил язмышына битараф булмаган шәхесләрне туплауга бәйле.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова билгеләп үткәнчә, хатын-кыз ул – чыннан да, социаль радар. Башкача әйтсәк, бөтен проблемаларны йөрәге, күңеле аша уздыру сәләтенә, алай гына да түгел, шуларны, булдыра аламы-юкмы, хәл итүгә алыну сәләтенә ия зат. Арттырып әйтүем түгел, без шундый ич!

Хатын-кызның иң кыен хәлдән дә чыгу юлын таба алуы, бетмәс-төкәнмәс сабырлыгы, стрессларны җиңелрәк кичерүе хакында «Социаль интеграциядә Татарстан хатын-кызларының эшмәкәрлек инициативасын хуплау»-га багышланган сөйләшүдә катнашкан форум кунакларыннан да үтемлерәк итеп, берәү дә әйтә алмас, шөт.



Асия Тимирясова, Икътисад, идарә һәм хокук институты ректоры: «БЕЛЕМ ҺӘМ ТӘҖРИБӘ ҖИТМИ».

– Көтелмәгән авырлык килеп туганда хатын-кызда булдыклылык һәм тормышчанлык сыйфатлары көчлерәк чагыла. Ул мондый вакытта тагын да кыюрак, тагын да үткенрәк. Бүген эшмәкәр хатын-кызлар ил бизнесының 30 процентын тәшкил итә. Гүзәл затларыбыз үзләрен күбрәк мәгариф, сәламәтлек саклау, хезмәт күрсәтү, туклану һәм сәүдә өлкәсендә сынап карый. Хатын-кыз ул барын да булдыра дисәк тә, алар еш кына җитди проблемаларга да юлыга. Дөресен әйткәндә, аны үз эшен башлап җибәрүдә кинәт бөлү, финанс бурычлары куркыта. Чөнки эшне уңышлы алып бару өчен тәҗрибә дә, белем дә кирәк бит. «Хатын-кыз һәм бизнес» сораштыруларында катнашучыларның 19 проценты, мәсәлән, әлеге дә баягы тәҗрибә җитмәүгә, 15 проценты – уңышлы эшмәкәрнең эш тәҗрибәсе киң таратылмауга, 11 проценты – белем җитмәүгә, ә 10 проценты исә технологик базаның фәкыйрьлегенә зарланган. Димәк, аларга һәрьяклап булышырга, төгәлрәге, Санкт-Петербург программасы мисалында «Татарстан Республикасында эшмәкәр хатын-кызларга ярдәм күрсәтү» махсус программасы булдырырга; Татарстандагы эшмәкәр хатын-кызларның уңышлы проектларын бастырып чыгарырга; эшмәкәр әниләр өчен яңа проектлар уйлап табарга; «Эшмәкәр әни» социаль проекты тәҗрибәсеннән файдаланырга кирәк. 2013–2014 елларда шул проект кысаларында «Хатын-кыз өчен шәхси эшмәкәрлек нигезләре» программасы буенча Мәскәү, Екатеринбург, Самара, Краснодар һәм Новосибирск шәһәрләрендә бушлай укытулар оештырылган иде. Укуларда 450 ләп кеше катнашты. Быел исә ул Санкт-Петербург һәм Ростов-Дон шәһәрләрендә дә узачак. Кызганычка каршы, бу исемлеккә Казан кертелмәгән. Ә менә курсларга мәктәпкәчә яшьтәге баласы булган һәм күп балалы әниләр языла ала. Уку нәтиҗәләре буенча бизнес-план бәйгеләре үткәреләчәк. Җиңүчегә үз эшен башлап җибәрү өчен 200 мең сум грант тапшырылачак.

Минемчә, эшмәкәр хатын-кызга ярдәм күрсәтү өчен һәм федераль, һәм региональ дәрәҗәдә максатлы, эзлекле сәясәт кирәк.



Мария Горшунова, Рестораторлар һәм отельерлар ассоциациясе вице-президенты: «ИГЕЛЕК БЕЛӘН ЯНӘШӘ...»

– Бездә эшмәкәрләрне ни өчендер яратып бетермиләр. Бизнесмен икәнсең, димәк, син – кеше хезмәтеннән файдаланучы, сине ни өчендер күрә алмыйлар. Бу сизелеп тора. Бизнеска тискәре мөнәсәбәт аягында нык басып торган урта хәлле катлауның булмавы белән аңлатыла. Ә бит күп кенә кызыклы, файдалы социаль проектларны шул бизнесменнар гамәлгә ашыра да. Минем эшмәкәрлек стажым 20 еллап. Эшләп киткәч тә, хәер, хәзер дә төрлесен күрергә туры килде. Шуңа мин бизнеска кереп кенә киткән хатын-кызларга кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә торам. Безнең сафка кемнәр килүе минем өчен барыбер түгел.

Мин үзем эшмәкәр генә түгел, балалар йортларының иганәчеләр шурасы әгъзасы да. Без инвалид балалар янында да еш булабыз. Талантлы балаларга да матди ярдәм күрсәтәбез. «Нечкәбил» бәйгесенең иганәчесе дә булып торабыз. Хәйрия эшләреннән бер дә читтә калмыйбыз, диясе килә.

Эшмәкәр хатын-кызның һәр вазгыятькә үз карашы, үз бәясе аның. Минемчә, бизнес дигәнең игелек белән янәшә барырга тиеш. Шул чагында гына эшеңнең гел уңышлы барачагына ышана аласың. Шәхсән мин үзем шулай уйлыйм.



Елена Вазилова, Спа-салон җитәкчесе: «ТАИЛАНД УЛ — КАЗАНДА...»

– О-о, ул эшкә керешкән чаклар... Исемә төшерә башласам, ничек алынганмын икән дип үз-үземә шаккатып торам. Әйе, бер дә җиңел булмады. Булышырга торучыларына караганда, киртә куярга торучылары күбрәк булды. Тик мин бик үҗәт кеше. Башлаган эшне

ярты юлда калдырганым юк. Бу юлы да шулай булды. Йә Аллам, барып чыкмаса, мин берни дә югалтмыйм ич, дим. Барысы моннан ике еллар чамасы элек, Таиландка йөргәндә башланды. Барам, анда яшәүче халыкның Ходайдан бирелгән мөмкинлекләрен күреп кайтам да, иптәшләремә сөйлим: «Их-х, дим, – Казанда да ачасы иде бер салон, чакыртасы иде аларның мастерларын!» Хыялланам, кыскасы. Бу серле илнең бер генә кисәкчеген булса да Казанга алып кайту уе минем күңелгә тәмам кереп утырды. Башта без салон өчен урын эзләдек. Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына барып, телгебезне әйткәч: «Ни өчен үзебезнекеләрне укытып кайтармыйсыз? Нигә аннан белгечләр чакыртасыз?» – дип үзәккә үттеләр. Алай буламы инде? Бу халык бөтенләй башка, алар куллары белән тоя бит. Ә безнең булдыра алганча, сыйфатлы хезмәт күрсәтәсебез килә. Ярый әле Мәскәү белән элемтәгә кердек. Алар булышты. Хәзер менә салонның Казанда ике филиалы бар. Тагын берсен Чаллыда ачарга җыенабыз. Үзләре чакырып тора.



Альбина Динмөхәммәтова, «Зәңгәр кош» гаилә клубы җитәкчесе: «АРЕНДАГА ТАШЛАМАЛАР ЮК».

– Безнең өчен иң җитди проблема менә шул. Әгәр дә дәүләт аренда өчен түләнә торган акчаның яртысын гына булса да кире кайтарып барса, күпкә җиңелрәк булыр иде. Без акчаны башка максатларга, әйтик, балаларга кирәк-яраклар алырга тотар идек. Хәзер менә канцтоварлар, кәгазь өше вак-төяккә дә бәя күтәрелде. Безгә балалар әти-әниләре белән килә. Шуның өчен дә ул «Гаилә клубы» дип атала. Димәк, алар өчен дә тиешле шартлар тудырылган булырга тиеш. Әти-әниләр эшебездән канәгать анысы. Эш гел шома гына бармый инде ул. Проблемаларсыз булмый. Тик без аларны хәл итәргә тырышабыз. Туктап калырга исәбебез юк.

Лицензиягә дә хәзер яңа таләпләр. Эшебезне җиңеләйтмиләр, киресенчә, катлауландыралар гына. Кече һәм урта бизнеска дәүләт ярдәме турында ишетеп беләбез. Әмма ул әле безгә килеп җитмәде. Безгә ташламалы кредитлар да бирелми. Мин, ике бала анасы булуыма да карамастан, эш өчен кирәкле кредитны гади бер кеше сыйфатында алам. Чөнки банк безгә түли алмый торган оешма буларак карый.

Татарстан Икътисад министрлыгы, авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләүче эшмәкәрләргә ярдәм күрсәтә ул. Ә менә хезмәт күрсәтү өлкәсе әлегә игътибар үзәгеннән читтә кала бирә. Югыйсә без дә бик мөһим эш башкарабыз: җәмгыятькә лаеклы нәни гражданнар тәрбиялибез бит...

Аңлашыла ки, сораулар күп. Тәвәккәлләп эш башлап җибәргән хатын-кызга дәүләт ярдәме генә чын мәгънәсендә терәк-таяныч була ала. Әле генә безгә шул турыда сөйләделәр ләбаса.



КФУның «УНИКС» мәдәни-спорт комплексында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм Казан Федераль университеты белән берлектә, Татарстан Республикасының Президент вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов катнашында булып узган «Эшмәкәрлек фабрикасы» тамашасына йомгак ясалды.

«Бу – университет, Икътисад министрлыгы, һәм иң мөһиме, остазларыбыз – бизнесменнар, эшмәкәрләр белән берлектә башкарылган зур эш», – диде Рөстәм Миңнеханов оештыручыларны һәм анда катнашучыларны котлап. Ул билгеләп үткәнчә, эшмәкәрлеккә дә аерым бер күнекмә, тәҗрибә тупламыйча керешеп булмый. Бу проектта катнашучылар, бәлкем, алга таба эшмәкәр булып китмәсләр дә. Аның каруы, алар бәйге барышында зур тәҗрибә тупладылар. «Ректор миңа студентларның күбесенең дәүләт структурасында эшлисе, чиновник буласы килә, диде. Ләкин бу өлкәдә уңышка ирешү өчен икътисад, юриспруденция, дәүләт төзелеше һәм башка шундый өлкәләрне яхшы белергә кирәк. Киләчәктә эшмәкәргә боларның барысы белән дә очрашырга туры киләчәк бит», – дип белдерде республика башлыгы.

Кече һәм урта эшмәкәрлек үсеше берничә мөһим факторга бәйле: әйтик, кирәгенчә финанслау, кирәкле инфраструктура оештыру (индустриаль һәм сәнагать мәйданчыгы, техник парклар), тиешле программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру. Ә иң әһәмиятлесе – инициативалы кешеләрнең булуы. Билгеләп үтелгәнчә, бизнес эшчәнлеге нигезләрен мәктәп программасына кертер вакыт та җитте. «Балада эшмәкәрлек белән кызыксынуны мәктәп эскәмиясеннән үк уятырга кирәк», – диде республика лидеры.

Татарстан Республикасы Икътисад министры Артем Здунов әйткәнчә, безнең республика – ул гади эшче өчен дә, шул эшчеләргә эш урыннары булдыручы эшмәкәрләр өчен дә чиксез мөмкинлекләр мәйданы.

«Эшмәкәрлек фабрикасы» гамәлгә кертелүенең беренче көннәреннән үк зур кызыксыну уятты. Проектта катнашу өчен 839 кыз һәм егет гариза бирде. Шуларның 135 е сайлап алынды. Ә финалга 50 кеше чыкты. Алар, махсус курслар үткәннән соң, өч ай дәвамында ТНВ һәм Word Business Channel телевизион каналларының күп миллионлы аудиториясе каршында үзләренең бизнес-проектларын тәкъдим иттеләр, эшләрен яңа гына башлаган эшмәкәрләр сыйфатында көч алыштылар. Аларга остазлар һәм экспертлар ярдәм итеп торды.

Өч айда Татарстанның яшь эшмәкәрләре 11 яңа бизнес-проект эшләде, 84 эш урыны булдырды. Нәтиҗәдә, 7 миллион сумнан артык керем алынды.

Җиңүче дип табылган командага Кубок һәм тамаша барышында барлыкка килгән бизнесны үстерүгә 1 миллион сум акча тапшырылды.

Инсар СӘГЫЙТОВ,
Татарстан Республикасы Икътисад
министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе.

PRESSA.RU



Фотолар интернеттан алынды

■ Миңа 41 яшь. Узган ел БДИ тапшырдым. Аңарчы ике ел кичке мәктәптә укыган идем. Улым туды, көн саен эшкә йөрергә кирәк, өстәвенә, йортыбызны яңарта башладык. Шулай да имтиханны яхшы гына ерып чыктым. Имтиханны тапшыра алмыйбыз, дип елаучыларны аңламыйм. Еламагыз, тормышта БДИдан да катлаулырак сынаулар бар.

■ Минемчә, БДИ рәвешендәге катгый сынау төгәл фәннәрдән, мәсәлән, физика, математика, химия, биологиядән генә уздырылырга тиеш. Гуманитар фәннәрне БДИ кысаларына гына куып кертү дөрес түгел.

■ Илдә БДИ кертеп бик дөрес эшләделәр, тик аны тиешле дәрәҗәдә оештырып кына бетерә алмадылар. Укытучылар һаман да БДИ турында бернәрсә белми, алар өчен иң мөһиме – план үтәү. Имтихан тапшыра алмаган укучыны начар укыды, диләр. Ә бәлки, план артыннан гына куган укытучы шулай «яхшы» белем биргәндер? Нинди генә чаралар кертеп карасалар да, имтихан барышында күчерүләрне һаман туктата алмыйлар. Тиешенчә эшләнелеп бетсә, БДИ бер дигән имтихан булыр иде.

Фикерләр http://www.pro100ege.ru сайтыннан алынды.

БДИ дигән СЫНАУ



Фәнзилә МОСТАФИНА

БЕЛЕМ БӘЙРӘМЕНДӘ, УКЫТУЧЫЛАРЫМНЫ КОТЛАРГА ДИП, МӘКТӘБЕМӘ КАЙТТЫМ. УНЫНЧЫ СЫЙНЫФЛАР БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘБЕЗ. «БДИДАН КУРКАСЫЗМЫ?» – ДИМ.

Укуның беренче көнендә, күңел һаман җәйдә яшәгәндә, тирә-юньдә бәйрәм рухы хөкем сөргәндә кем шундый сорау бирә инде?! «Курыкмыйбы-ыз!» – диләр. Ә без курка идек...

Чишмә башы

Без – СССР таркалгач туган буын, үзебезне, уенынчынын бергә кушып, «тәҗрибә куяннары» дип атап йөртәбез. Безгә кадәр укучылар 3 нче сыйныфтан 5 кә сикерә иде, без сикермәдек – 4 не дә укыдык. Без 9 нчы сыйныфка җиткәндә профильле укыту дигәннәре барлыкка килде, программага укытучылар моңарчы ишетеп тә белмәгән фәннәр кертелде. Бердәм дәүләт имтиханын зур кашык белән авыз тутырып «ашый» башлаучылар да без булдык.

2001 елда БДИ тәҗрибә рәвешендә Россиянең биш субъектында – Чуашстан, Мари Иле, Якутия Республикаларында, Самара һәм Ростов өлкәләрендә үткәрелде. Беренче нәтиҗәләр буенча имтиханнан канәгатьсезлек белдерүчеләр шактый булса да, тәҗрибәне дәвам иттеләр. 2002 елда – Россиянең 16, 2003 тә – 47, 2004 тә – 65, 2006 да 79 төбәге үзендә БДИ уздырып карады. Бу әле яңалык иде, шуңа күрә хилафлыкларга күз йомылды, укучыларга сайлау мөмкинлеге бирелде, «икеле»ләр гафу ителеп, аттестатка «өчле» булып төште, югары уку йортларына кергәндә БДИ баллары төп рольне уйнамады. 2008 елда Россиянең бөтен төбәкләре БДИ буенча үз программаларын әзерләде. Бәлки, БДИны бетерерләр әле дип йөргәннәрнең өметләре киселде – 2009 елдан имтихан бердәм һәм мәҗбүри рәвеш алды.

Моңарчы «әллә безгә кала әле ул БДИ, әллә юк», дип, пыскып янган өмет сигезенче сыйныфларда ук сүнде кебек. Оптимистраклар, «менә бетә, менә бетә» дип, 9 нчы сыйныфка кадәр көтте. Аннары әзерләнә башладык. Белемне арттырудан бигрәк, психологик якны ныгытырга кирәк иде.

БДИ аркасында – элмәккә?

Юк, куркуыбыз имтиханны бирә алмабыз дип уйлаудан түгел иде. Һәр яңалыкның әчкелтем тәме була бит. Кызыксынып кабасың да, нәрсә булыр икән дип, куркакурка гына йотасың. Без дә БДИга әнә шулай эчке бер кызыксыну һәм борчылу белән әзерләндек, имтиханга шулай кердек һәм... биреп тә чыктык. Хәзерге БДИ биремнәренә күз салгач, имтиханны тапшыру шартларыннан хәбәрдар булып торгач, без тапшырганда җиңел булган икән әле дибез. Ул вакытта имтихан тапшыру пунктларына камералар куелмый, күчергәндә тотылган баланың эш нәтиҗәләре гамәлдән чыгарылмый, БДИ барышында шпаргалка кулланган укучыны күрми калган укытучыларга штраф салынмый иде шул. Безнең вакытта укытучыга хезмәт хакы да укучыларының БДИда ничә балл җыюына карап түләнмәде.

«Курыкмыйбыз», – ди укучылар. Димәк, аларның БДИга иммунитетлары көчле. Иммун системалары нык булмаганнар да бар бит. БДИ бирә алмаудан куркып яки имтихан нәтиҗәләреннән канәгать булмыйча үз-үзләренә кул салучылар да бар бит әле... Быел әнә Олы Кайбыч мәктәбен тәмамлаучы 18 яшьлек Денис Бартязовның элмәккә менүе бөтен республиканы тетрәндерде. Тырышып укый Денис, юридик факультетка керергә хыялланa. Математика белән рус теленнән БДИны яхшы гына бирә. 8 июньдә җәмгыять белеменнән имтихан тапшырырга дип чыгып китә. Тик имтиханнан кәефсезләнеп кайта. Ә икенче көнне әнисе сарайда улының үле гәүдәсенә тап була...

Мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр, чыгарылыш сыйныф укучыларының үз-үзләренә кул салу очракларыннан соң: «Монда БДИны гына гаепләмәгез», – дигән белдерү белән чыгалар. Тик укучыларның үз-үзен тотышы гаеп БДИда дип фаразларга җирлек калдыра шул. Денис Бартязов та, җәмгыять белеменнән чыккач, дусларына: «Наугад» кына эшләдем, имтиханны тапшыра алмадым. Яшисем килми», – дип язган була. Ләкин аның бу сүзләрен җитди итеп кабул итмиләр. Их, Денисның уенда нәрсә барын белсәләрме...

Яңа заман мәгариф системасы яңалыкларының күбесен нәкъ менә бездә сынадылар.

«Икеле»лек итеп эшләмәгән Денис җәмгыять белеменнән имтихан биремнәрен, 48 балл җыйган. Бу хәбәрне үзе генә белми калды инде. Нәрсә мәҗбүр итте икән егетне бу адымга барырга: тиешле баллны җыя алмам дип куркумы, имтихан барышында берәр гаделсезлек белән очрашуымы, әнисенең һәм укытучыларының өметен аклый алмам дип борчылумы? Монысын Денис үзе һәм Аллаһы Тәгалә генә белә инде...

БДИ-2015.

■ **Быел Татарстанда 18156 чыгарылыш сыйныф укучысы БДИ биргән.** Йөз балл җыючылар узган ел 122 булса, быел – 105. Ә 138 укучы (кичке мәктәпне тәмамлаучыларны да кушып) аттестатсыз калган. Үзләре сайлап ала торган фәннәрдән укучылар җәмгыять белеме, физика, биология һәм химиягә өстенлек биргән.

■ **Узган елгы нәтиҗәләр белән чагыштырганда кайбер фәннәрдән уртача баллның артуы күзәтелә.** Мәсәлән, быел укучылар физикадан – 6,92, немец теленнән – 11,32, рус әдәбиятыннан – 5,04, географиядән 2,63 баллга күбрәк җыйган. Ә менә информатикадан (1,23 баллга) һәм француз теленнән (4,2 баллга) уртача күрсәткечнең кимүе күзәтелә.

■ **Быелгы БДИ нәтиҗәләре буенча Татарстанда административ хокук бозу турында 18 протокол төзелгән.** Шуның 7 се – имтихан тапшыручыларга, берсе шәфкать туташына һәм 10 ысы оештыручыларга карата. Имтихан барышында иң күп тәртип бозу очраклары Әлки, Буа, Чүпрәле, Түбән Кама һәм Питрәч районнарында теркәлгән.

■ **2015 елдагы БДИга йомгак ясау чыгышында ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов:** «Россиянең башка төбәкләре белән чагыштырганда Татарстан укучыларының нәтиҗәләре начар булмаса да, министр буларак мин алардан канәгать түгел», – дип белдерде.

PRESSA.RU

Психологик ярдәм кирәк

Белгечләр фикеренчә, БДИ тапшырганда, укучыларның 80 проценты депрессиягә бирелә икән. Бала даими рәвештә басым астында яшәргә мәҗбүр – ата-аналар: «Биреп чыга алырсыңмы икән инде?», укытучылар: «Тырышмыйсыз, укымыйсыз, имтиханнарны ничек бирергә җыенасыз?», ә БДИны кабул итүчеләр: «Эшләрегезне тизрәк тапшырыгыз, ярты сәгать кенә вакытыгыз калды», – дип, укучыны даими рәвештә «кыса». Ел әйләнәсе шушындый шартларда яшәргә мәҗбүр бала.

Ата-аналар балага психологик ярдәм күрсәтүгә әзер булырга тиеш.

Шәһәр һәм район мәктәпләрендә баланы имтиханга әзерләүдә психологлар да катнаша. Тик менә әти-әниләр белән эшләү оештырылып бетә алмый әле. Югыйсә сынау алдында торган балага беренче чиратта якын кешеләренең ярдәме кирәк бит. Мәгариф белгечләре БДИны камилләштерү юнәлешендә эшли, тик шул ук вакытта имтиханнарның бала психикасына йогынтысын да исәпкә алып, ул юнәлештә дә эш алып бара башлаыннар иде.

Камилләштерү дигәннән, Рособрнадзор җитәкчесе Сергей Кравцов белдергәнчә, өлгерешләре начаррак булган укучыларны имтиханга әзерләү буенча зур программага старт бирелгән. Тиешле методик кулланмалар да әзерләнгән иде. Укуда калыша торганнарга шул яңа төзелгән әсбаплар нигезендә белем бирелә башлаячак. Укучыларны да, укытучыларны да (аларга да өстәмә йөкләмә дигән сүз бит!) азаплаганчы, БДИны югары уку йортларына керүчеләр өчен генә мәҗбүри итеп калдыру дөресрәк булмасмы икән? Вузга керүчеләр өчен имтихан тапшыруның кирәклеге бәхәссез, ә техникум-көллиятләргә китәргә теләүчеләргә ул кирәкме соң? Менә хәзер 4 нче сыйныфка да БДИ кертергә җыеналар. Укучыларны кечкенәдән үк чыгарылыш имтиханына әзерләү өчен дип аңлаталар моны. Ярый да шулай булса, сабый психикасын какшатуга кайтып калмаса...

Киңәш



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог:
– Баланың БДИны әйбәт бирүе күп очракта ата-анадан тора. Бар шундый кешеләр: алар балаларын имтиханга ярышка әзерләгән кебек әзерли. Тик бу очракта «иң мөһиме – катнашу» дигән тынычландыру сүзләре яңгырамый. Иң югары балл җый, нәтиҗәләрең күрше кызыныкыннан яки бергә эшләүче коллеганың улыныкыннан яхшырак булсын – менә нинди максат куя ата-аналар. Болай эшләү дөрес түгел. Баллар артыннан куып, баланы югалтырга да мөмкин. Бәлки, нәтиҗә сез теләгәнчә дә булмас, тик аның да уңай ягын гына эзләгез. Балага олы тормышка яраклашырга ярдәм итәчәк ул. Аның белән имтихан нәтиҗәләре турында сөйләшергә, үзеңне ничек хис итәсең, дип сорашырга кирәк. «Нәтиҗә нинди булуга карамастан, мин сине яратам, сиңа ышанам», – дип кабатлап торырга онытмагыз.



■ 1 сентябрьдә 1100 укучы һәм аларның әти-әниләре Казандагы өр-яңа 179 нчы мәктәпкә җыелдылар. Белем бәйрәменә багышланган тантанага ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов та килде, иң соңгы заманча стандартлар буенча төзелгән мәктәпне ачабыз дип белдерде. Татарстан лидеры уку-укыту җиһазлары өчен сертификат бүләк итте. Яңа мәктәп 1375 укучыга исәпләнгән һәм 28 мең квадрат метр мәйдан били, ягъни гадәти мәктәптән 3 тапкыр зуррак. Физика-математика, социаль-икътисад, химия-биология юнәлешендәге мәктәптә медицина профиле буенча аерым класс ачыла. Аны тәмамлаучылар медицина университетына укырга кергәндә өстенлекләрдән файдаланачак.

■ Иннополиста халыкара мәктәп һәм 225 урынга исәпләнгән балалар бакчасы ачылды. Бүген шәһәрдә 100 гә якын бала бар, берничә ел эчендә аларның саны бермә-бер артыр дип көтелә. Балалар бакчасы һәм мәктәп Британия белем бирү системасы буенча эшләячәк, балаларга кечкенәдән инглиз телен өйрәтү күздә тотыла. Якын арада Иннополиста 450 урынга исәпләнгән тагын бер мәктәп һәм бакча ачу ниятләнелә.

■ Казанда 4 мәктәп базасында кытай телен укыту гамәлгә кертелде. Яңа чит телне атнага 3 сәгать укыту каралган, дәресләрне вуз тәмамлап, Кытайда стажировка узган белгечләр алып барачак.

■ Быел башкаланың 19 мәктәбе капиталь төзекләндерелде. Әлеге эшкә 550 миллион сум бүлеп бирелгән. 30 елдан элегрәк төзелгән белем бирү йортларын төзекләндерү буенча Президент программасы бишенче елын эшли. Быел программа балалар бакчаларын да колачлады – ун бакча капиталь төзекләндерелде.

■ Башкаланың 9 мәктәбе – Россиянең 500 иң яхшы белем бирү йортлары исемлегендә. Быел Казан мәктәпләрендә белем алучы 57 укучы Россия күләмендәге олимпиадаларда җиңүче һәм призер булган.

■ «Мәктәп картасы» республика проектына старт бирелде. Мәктәп ашханәләрендә иртәнге һәм төшке аш өчен акчалата түгел, пластик карталар ярдәмендә түлиләр. Транспортта йөрергә кучкән акчаны да, уку йортына электрон үткәрү кәгазен дә әнә шул «электрон янчык» – «Мәктәп картасы» үзенә сыйдырган. Бу уникаль проект буенча ата-аналар баланың кайда икәнен, нәрсә ашаганын, акчасын нәрсәгә тотканын күзәтеп бара ала.

«АЕКЛЫК НОКТАСЫ»



Бу программа буенча бер ел дәваланганнан соң эчкече әниләр инде беркайчан да аракыга борылып карамаячак. Белгечләр шулай ди.

Ниһаять, ниһаять... без моны бик көткән идек.

Татарстанда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина, Татарстан Сәламәтлек саклау министры урынбасары Сергей Осипов, республиканың балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе рәисе Илсөяр Гарифуллина катнашында журналистлар белән уздырылган матбугат конференциясендә күптән ишетәсе килгән сүзләр әйтелде.

Бездә 1 сентябрьдән социаль ятимлекне кисәтүгә юнәлдерелгән проект гамәлгә кертелә башлады. «Аеклык ноктасы» дип аталган әлеге медик-социаль программа, нигездә, алкоголик әниләрне дәвалауга йөз тота. Бу Татарстан өчен генә түгел, Россия өчен дә гаять дәрәҗәдә мөһим булган актуаль чара.

Татарстанда 12 меңнән артык ятим бар. Шуларның 23-25 проценты гына әти-әнисе вафат булу сәбәпле ятим санала. Ә калганы – 80 процентка якыны – әти-әниле килеш ятимнәр. Сәбәбе – әлеге дә баягы эчкечелек. Аңлашыла ки, бу программа тикмәгә кабул ителмәгән. Безне, беренче чиратта, балалар язмышы борчый. Бүгенге көндә 3,5 мең балага социаль куркыныч яный.

Министр урынбасары Сергей Осипов әйтүенчә, Татарстанда соңгы ике елда, кризис булуга да карамастан, алкоголизм артмый да, кимеми дә дигәндәй, шул бер дәрәҗәдә кала бирә. «Гаиләдә ир эчсә, бер бәла, хатын эчсә, бусы инде фаҗига, – диде министр урынбасары. – Шуңа без әниләрне балаларына кайтарырга тиеш. Бу проект махсус алар өчен эшләнде. Тик теләк кенә белдерсеннәр, дәвалансыннар гына...» Хәзер программаны тормышка ашыруның беренче этабы бара: дәваланырга теләүче әниләр сайлана (нигездә күп балалы әниләр). Аннары дәвалау чоры башлана: ул алты айга сузылачак, һәм шул вакыт эчендә пациент ай саен бер укол алачак. Һәр пациентны дәвалау өчен йөз меңнәрчә сум акча тотылачак. Гомумән, пациент ел дәвамында, дару белән дәваланудан тыш, психиатрлар белән элемтәдә торачак. Шуның белән беррәттән, тернәкләнү чорын да узачак. Эшкә урнаштыру, бала белән мөнәсәбәтләрне көйләү, ягъни адаптация чоры белгечләрнең җитди күзәтүе астында булачак. Бүгенге көндә 45 хатын-кыз сайлап алынды инде. Бу максатка республика бюджетыннан 5,4 миллион сум акча бүлеп бирелде.

Әкренләп генофондыбызны кыраҗимерә барган бу фаҗигадән дә арыну юллары табылып килә сыман. Әлеге программа безне бик күп күңелсезлекләрдән, хәсрәт-борчулардан аралап, йөзләрчә, меңнәрчә гаиләләрне таратудан саклап калыр, дип ышанасы килә.

Бик ышанасы килә, чөнки әлеге гаять дәрәҗәдә катлаулы һәм җаваплы бу эш иң элек эчкече әниләрне айныту, чын мәгънәсендә, гаиләләренә, балаларына кайтару максатында уйлап табылган. Шуның өчен эшләнгән. Республикада 29 меңнән артык алкоголик яши икән. Бу әле үзләренең шушы яман чир белән авыруларын танып, наркология диспансерына дәваланырга килүчеләре генә. Ә күпмесе килми, «мин алкоголик түгел», дип, эчүен, гаиләдәгеләренә якты көн күрсәтмичә яшәвен дәвам итә. Иренә кушылып хатыны да эчкән очраклар азмы тагын? Салгаларга ярата торган хатыннарны күп очракта ирләре ташлап китә. Бала дип тә, ул ничек яшәр дип тә тормый. Эчкән хатын-кыз иренә кирәкми ул, ә менә балалары өчен ул һәрвакыт әни, яраткан әни!

Моңа мин әллә никадәр мисаллар китерә алам. Казанга якын гына урнашкан балалар йортларының берсенә баргач, тәрбияче мине: «Килгәненә ике ай гына әле», – дип, 10-12 яшьләр тирәсендәге бер кыз белән таныштырды. Сөйләштерә башладым. Ничек килеп эләгүе хакында кызыксындым. «Әнием авырып китте, – диде бала, – хастаханәдә ул хәзер, ә әтием безне күптән ташлап китте». Һәм өстәп куйды: «Әниемне бик яратам. Ул да мине ярата, терелгәч, моннан алырга сүз бирде».

«Әй, – дип кул селти тәрбияче, – Катенька әйткәнчә генә булса икән ул... Барып чыккан алкоголик аның әнисе. Күрәсезме, нинди алар?! Беркайчан да әниләрен яманламыйлар. Хәтта исерек дип тә әйтмиләр. Айнымас аның әнисе. Ана хокукыннан да мәхрүм иттеләр. Бала җәл. Көн саен тәрәзәгә капланып, килүен көтә. Бертуктаусыз шуны сөйли. Наркология диспансерына озатканнар дип ишеттек. Терелмәс, файдасы булмас... Булырга ошамаган».

Алкоголизмнан терәүне дә ирексезләп дәвалап булмый. Үзе теләсә генә. Ә моның өчен психиатрлар ярдәме кирәк.

Хатын-кыз – көчле ул, бернинди авырлыкларга да бирешми, дибез. Ә менә, наркологлар әйтүенчә, эчә башлаган хатынны туктатуы бик авыр, ә кайчак хәтта мөмкин булмаган эш икән. Бөтен өмет әлеге программаның нәтиҗәле эшләп китүендә хәзер...

Мәдинә КАШАПОВА

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

БАЛА КҮҢЕЛЕ – ДАЛАДАМЫ?..



Ләйсән ХӘЕРОВА. Әлмәт.

«Сөембикә» журналын әни белән икәүләп укырга яратабыз без. Шулай рәхәт бит: язмалар буенча фикер алышасың, сөйләшәсең... Бу юлы ул сезнең басмада яшьләр тарафыннан язылган мәкаләләрнең бик аз булуына игътибар итте. Бәхәсләшеп киттек. «Кияүгә чыккан, инде әни булган, әби яшенә җиткән хатын-кызларга без, яшьләр, нәрсә әйтә алабыз соң?» – дим. Шулай дидем диюен дә... Әмма үзем исә эчемнән шунда ук уйлап куйдым: «Әниләргә әйтер сүзебез бар бит безнең!»

Сер түгел, әти-әниләр һәм балалар арасында аңлаша алмау «эмпатия» булмау аркасында килеп чыга. Нәрсәне аңлата соң бу чит сүз? Шәхеснең үзен икенче кеше урынына куеп карый алуын эмпатия, диләр. Моны эшләмәү, эшләргә теләмәү, үзебезнең фикердә генә бикләнеп яту исә гаиләдә генә түгел, гомумән, тормышта да комачауларга мөмкин. Шушыннан чыгып, минем әниләргә яшүсмерләрнең берничә серен ачасым килә. Балаларын аңламаучы әниләргә дә, әниләре белән уртак тел таба алмаган кызларга-малайларга да бу язма булышыр дип өметләнәм.

Ике арада нинди проблемалар туарга мөмкин соң? Әйдә, аларның кайберләрен күздән кичерәбез.

«Үзем беләм!» очрагы

«Инде буй җитсәм дә, мин синң сабыймын...» Барыбыз яратып җырлаган җырның шушы юллары искә төште әле. Әниләр безне өйрәтә тора, без киресен эшли торабыз... Дөресен әйтик, булгалый бит шулай, әйеме? Кайчакта, үч итеп, бөтен эшне бозып ташлыйбыз! Әниләр мондый чакта: «Син әллә юри, башка эш кушмасыннар, дип, киресен эшлисең инде?» – дип аптырый. Нигә болай килеп чыга соң? Әйдәгез, җавабын эзләп карыйк. Без – яшүсмерләр, әле шәхес булып формалашып кына киләбез. Дөньяга яңа туган песи баласыннан әллә ни аермабыз юк: үз фикерләребезне, үз кагыйдәләребезне булдырабыз гына.

Үз шәхесеңне формалаштыру тәм-том пешерүгә бик тә охшаган кебек тоела миңа. Менә син үлчәп кенә аңа үзсүзлелек өстисең, өч аш кашыгы кирелек, ике стакан мәхәббәт, өч капчык матурлык (монда тырышасың инде!)... Башка ингредиентларны кушып җибәрәсең...

Ә хәзер, хөрмәтле әниләр, шундый күренешне күз алдыгызга китерегез: менә сез гөбәдия пешерәсез, ди. И-и, салдыгыз дөгесен, хуш исле җимешен, мендәрдәй йомшак камыр куйдыгыз!.. Һәм шул вакыт кухняга кайнанагыз керә дә: «Дөгең катырак булган, җимешең иске, камырың кабармаган», – дип, сез яратып, тырышып, тәмле булсын дип пешергән гөбәдияне яманлый башлый. Рәнҗетә бит, әйеме?..

Яшүсмерләр белән дә шушы хәл. Без бөтен эшне аңларга, үзләштерергә тырышабыз һәм үзебез белгәнчә эшлибез. Ә «дөрес түгел» дигән бер сүз бөтен теләкне качыра да бетерә. Чынлыкта, эшкә өйрәнүнең иң яхшы ысулы – хаталана-хаталана өйрәнү.

«Байга кияүгә чык һәм башкалар» очрагы

Әти-әниләрнең безгә баглаган өметләре турында сөйләшик әле. Бер дус кызымны әти-әнисе музыка мәктәбенә йөртте. Флейтасын урталай сындырырлык дәрәҗәгә җитеп: «Туйдым!» – дип елый иде ул... Икенче дустымны әти-әнисе, аның теләгән сорап та тормыйча, гуманитар сыйныфтан «физмат»ка күчерде... Өченчесе, тавышы бик матур булса да, сәхнә турында озак вакытлар хыялланса да, әнисе кушканга медуниверситетка укырга керде... Тфүтфү, мин үзем алар белән чагыштырганда иректе кош кебек, әнием минем һәрбер эшемне хуплап тора, хыялларымны чынга ашыруда ирек бирә. Әйе, әти-әниләрнең безне һәрьяклап үсеш алган шәхес итеп күрәселәре килә. Кайберәүләре моның өчен бигрәк тә кискен чаралар куллана...

Кемнәрдер, йөрәк мае – балаларына «кагыйдәләр читлеге» төзи. Янәсе, әйткән сүзне тыңласа, ул хак юлдан читкә тайпылмас. Әйе, дөрес, «кагыйдәләр читлеге» тәрбия төрләренең берсе. Ләкин ул кагыйдәләр дөрес булып, баланың үз фикере формалашуына китерергә тиеш. Ә әйтимме сезгә балаларның нинди кагыйдәләрне яратмаганын?

«Гуманитарийлар – хәерче бюджетниклар!», «Бай кияү эзлә, балда йөзәрсең!», «Малайларга – физика!», «Акчалы эш сайла!», «Дусларың урынлы булсын!», «Миңа «бишле» алып кайткан бул!», «Тик беренче урыннар гына!», «Синнән берәр файда булырмы икән?!»... Болары – безгә иң ошамаганнары. Әле бик күп алар, тик калганнарына түзәргә була.

Тагын кайнанагызны искә алыйк. Менә ул яныгызга килә дә: «Ун бала табып үстерергә теләгән идем... Без авыр чорга туры килдек, ә сез хәзер рәхәттә яшисез! Әйдә, килен, хатынкызның эше шул! Ун күп дисәң, бер биш оньк та җитә миңа!» – ди. Бер мәлгә телсез калыр идегез, шок булыр идеме? Ә безгә, үз хыялларыбызны читкә куеп, сезнең – әти-әниләрнең өметләрен, яшьлек хыялларын чынга ашыру җиңел дисезме?

«Син мине яратмыйсың!» очрагы

Бу сүзләрне әниләр дә, малайлар һәм кызлар да еш әйтә. Кайнап торган көндәлек тормышта «ярата»га урын да юк шикелле. Дөресрәге, әлеге сүз дистәләгән бүтән сүзләр белән алыштырыла: «Башыңа киденме?», «Кайчан кайтасың?», «Булышыйммы?», «Тыныч йокы», «Чәй куям?»... Һәм тагын бик күп, бик күп шуның кебек сүзләр.

Яшүсмерләр исә, гадәттә, боларына да саран була. Чөнки бу чор сез

Яшүсмерләргә киңәш:
Йорт эшләренә, аш-суга караган сорауларда әни кеше – иң яхшы «википедия». Монда аның «өйрәтүе» хәзинәгә тиң. Мин моны сезгә үзсүзләнеп, әни сүзенә колак салмыйча, «үзем беләм» дип бәлеш яндырган кеше буларак әйтәм. (Ә бәлешем шундый тәмле булырга охшаган иде!..)

Әниләргә киңәш:
Юк, «дөрес түгел» дигән сүзне бөтенләй әйтмәгез димим. Әйтергә кирәк. Кыска итәк киеп кичке сәгать унда урамга чыгып барган кызыгызны туктатмыйча, тыныч кына артыннан карап кала алмыйсыз бит инде, әйеме? Мондый очракта баланың үз бүлмәсендә бер-ике әйберне чәлпәрәмә китерүе күпкә куркынычсызрак... Ләкин «дөрес түгел» дигәндә ни өчен дөрес түгеллеген дә аңлатып бирсәгез иде сез. Мин үзем, мәсәлән, һаман бер әйберне аңламыйм: нигә юылган тәлинкәләр киштәдә бөтенесе бер якка карап торырга тиеш алар?

Яшүсмерләргә киңәш:
Кайчакта әти-әниләр, чыннан да, яхшырак белә. Икегез ике бүлмәдә үпкәләшеп утырганчы, һөнәр сайлау кебек проблемаларны бергә чишү дөресрәк. Компромисс эзләгез: башта әти-әни теләгән тыңлап, медицина университетын тәмамлагыз, аннары үз хыялларыгызны чынга ашырыгыз. Онытмагыз: әти-әниләр сезгә бары тик яхшылык кына тели.

Әниләргә киңәш:
Әгәр дә балагыз спорт секциясеннән (музыка яки рәсем мәктәбеннән), химия фәне буенча репетитордан «мин-ардым-минем-яшисе-килми» кыяфәте белән кайта икән, моңа, зинһар, игътибар итегез! Әдәбиятсәнгатькә тартылган күңелдән берничек тә физик ясый алмассыз. Ышанмыйсызмы? «Физика» дәреслеген күтәреп карагыз әле: аның астында Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»е яшеренеп ятамы?

PRESSA.RU

үстергән кошчыкның оясыннан башын чыгарып каравы: киң, олы дөньяны күргәч, үзең утырган ояның бер мәлгә кадере югала. Ләкин, хөрмәтле әниләр, без сезне яратмыйбыз дип уйлый күрмәгез! Тинейджерлар, нинди генә күңелсезлеккә тарысалар да, иң беренче итеп бу серне әнигә сөйлиләр бит. Ә сөйләмиләр икән, димәк, аларның сезне борчыйсы килми.

Тагын бер сер ачыйммы? Хәер, барыбер ачам. Өйгә кайту белән, кайчак исәнләшмичә дә үз бүлмәбезгә кереп югалуыбызның сәбәбен беләсегез киләме? Беренчедән, кәефнең төшенке булуы. Андый чакта нигәдер сүзләрне уйламыйчарак әйтәсең бит. Кирәкмәгән тавыш чыгармас өчен без ялгыз калырга тырышабыз да инде... Икенчедән, нинди дә булса проблемага юлыгып, аны чишү турында уйлануыбыз бу. Мондый вакытта әнинең нинди хисләр кичерүе онытыла инде – без гаепле...

Мин дә әниемә гел-гел «яратам» дип әйтмим. Еш кабатлаганда бу сүзнең мәгънәсе югала кебек тоела. Кайчак әни: «Сөйләшәсең килми бугай», – дип трубкасын куйганда, тамакка утырган төер, күзгә тыгылган яшьләр аркасында сөйләшә алмавымны белми кала.

Ә менә кайбер яшүсмерләр, киресенчә, әни игътибары өчен көрәшә. Укытучы балалары, мәсәлән. Күп укытучылар: «Сезнең белән

! Яшүсмерләргә киңәш:
Әниеңә, минем кебек, язма аша булса да «яратам» дип әйт. Сине еллар буе нәфис гөлдәй карап үстергән әниләр өчен бу сүз бик мөһим.

! Әниләргә киңәш:
Белегез – сездән якынрак кешебез юк безнең!

көне буена арып бетәм, үземнекеләргә елмаерлык та хәлем калмый!» – диләр. Чыннан да, шулайдыр. Кешенекеләр белән сабыр булып, үз балаңа көне буе җыелган ачу гына эләгәдер, мөгаен...

Рәхмәт сүзе

Кайбер мөһим проблемаларга күз салдык шикелле. Бөтенесен берьюлы сөйләшеп бетереп булмас. Алар күп, әлбәттә, аннан – һәрбер гаиләнең үз сере, никадәр кеше – шуның кадәр мөнәсәбәт. Тагын нәрсә әйтәсе килә?

Рәхмәт, әниләр! Үзегез уттай янып, кайгырып яшисез, ләкин безгә яктылык, җылылык бирәсез. Сезнең яктылык бөтен гаиләне җылыта, гүзәллегегез йортларга ямь кертә. Сез җирдәге фәрештәләребез...

Һәркем өчен үз әнисе – иң газизе, иң матуры. Бөтен әниләр изге җанлы, шәфкатьле булса да. Ә шулай да минем әни – иң яхшысы!..

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Айсылу НӘГЫЙМОВА, психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы:

Авторыбыз өлкәннәр өчен дә, яшүсмерләр, яшьләр өчен дә бик әһәмиятле теманы күтәреп чыккан – буыннар каршылыгы. Чыннан да, бер-берсен бик яраткан бала белән әти-әни арасында еш кына аңлашылмаучылык килеп чыгып тора. Ә бит әти-әни баласына гел изгелек кенә тели... Бала да әти-әнисенә карата бик яхшы мөнәсәбәттә... Ни өчен соң мөнәсәбәтләр киеренке, ә аерым очракларда хәтта сугыш кырын хәтерләтә? Моның тамырлары күп һәм тирәндә булырга мөмкин, әмма төп сәбәпләрнең берсе – ике буын кешеләренең бер-берсен аңламавы.

Җәмгыять, икътисад бүген бик тиз үсеш чорын кичерә, бу, үз чиратында, техника, технологияләрнең кискен үсеше белән генә түгел, ә бәлки, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең дә тамырдан үзгәрүе белән билгеләнә. Төрле буын вәкилләренә бер-берсен аңлау авырлаша бара – җәмгыятьтә өстенлек итүче кыйммәтләр башка, яшәү рәвеше үзгә... Яшәү темпы бик югары – бу исә аеруча яшь буынга өстәмә таләпләр тудыра: яхшы белем алырга, карьера ясарга, матди проблемаларны җиңәргә, фатир, автомобиль турында әйткән дә юк инде... Һәм иң әһәмиятлесе (!) – боларның барысын да бүген һәм хәзер эшләргә кирәк! Шундый вакытта яшь кешегә «узган заман кешеләренең» акыл биреп, өйрәтеп торулары урынсыз тоела, ул бит әти-әнисеннән аермалы буларак бүгенге көн белән яши, аңа киләчәк перспективалар да аңлаешлырак сыман...

Моннан тыш, миңа, психолог буларак, еш кына аралашуда проблемалары булган гаиләләр белән очрашырга туры килә: бер түбә астында яшәп тә фатирдашлар сыман көн күрүчеләр күпме?! Бала үстерүне кайбер ата-аналар аның тамагын туйдыру, өстен бөтен итү дип кенә күзаллый. Ә бит тәрбия ул – иң беренче чиратта җанны, рухны тәрбияләү. Бала белән серләрегезне бүлешергә, аңа карата ихлас булырга омтылмасагыз, үсеп җиткәч, улыгыз яки кызыгыз сезнең белән рухи бәйлелек тоймас, авыр вакытта сезгә килеп егылмас – ярдәмне башкалардан эзләр. Шулай ук сезнең проблемаларга да «сукыр», «саңгырау» калыр... Әти-әни булуның иң зур куанычы һәм иң зур бәхете дә балаларында үзеңә теләктәш, дус, чын мәгънәсендә якын кеше тәрбияләүдәдер.

Ниһаять, тагын бер сәбәп – эмоциональ фәкыйрьлек. Без хәтта иң якын кешеләребезгә дә хисләребезне белдерергә уңайсызланабыз: «болай да билгеле бит инде», «гел-гел әйтеп торсаң тәме бетә», имеш! Ә бит баланың эмоциональ, рухи сәламәтлегенең нигезендә гаиләдә булган җылы мөнәсәбәтләр, ата-ана мәхәббәте ята. Яратылып үскән бала үзе дә мәхәббәт чыганагы була, ул аны әти-әнисенә кайтара, ә инде үсеп җиткәч, үз гаиләсенә, сөйгән ярына, балаларына бирә.

ҖӘМГЫЯТЬ

Ялтада Россия Президенты Владимир Путин Кырым Республикасы иҗтимагый оешмалары вәкилләре белән очрашты. Очрашуда ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Очрашу барышында Владимир Путин Татарстанны төрле конфессияләр һәм төрле милләт вәкилләренең тынычлыкта яшәгән Россия төбәге буларак мисал итеп күрсәтте. Рөстәм Миңнеханов Татарстанның милли телләр өйрәтүдәге тәҗрибәсен өйрәнергә тәкъдим итте.



Казан Кремлендә ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов һәм аның хатыны Гөлсинә ханым исеменнән республиканың барлык шәһәр һәм районнарыннан иң яхшы гаиләләрен хөрмәтләү тантанасы узды. 50 елдан артык бергә гомер кичергән парлар, күп балалы, тәрбиягә бала алган гаиләләр, Бөек Ватан сугышы ветераны, спортчылар, табиблар, педагоглар, хәрбиләр, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре гаиләләре, кыскасы, төрле милләт вәкилләреннән булган 50 ләп гаилә бәйрәмнең түрендә булды. «Гаилә ул — дәүләтебез, республикабызның нигезе, традицияләребез һәм мәдәниятләребезне саклау асылы. Сез яшьләребезгә үрнәк булып торырлык гаиләләр», — дип сәламләде аларны Рөстәм Нургалиевич. Гаилә ныклыгын саклауны үзәккә куеп, аерылышу процессын катлауландыра торган инициатива белән дә чыкты ул.

МӘДӘНИЯТ



Туфан Миңнуллинның 80 еллык юбилее уңаеннан, заманыбызның мәшһүр шәхесен искә алу чаралары узды. Мәскәүдә Татар мәдәни үзәгендә Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган кичә булды, Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында мәрхүмнең кабере яд ителде, Кама Тамагы районында аның истәлегенә бюст ачылды, Олы Мәрәтхуҗа клубында Г. Камал театры артистлары «Мулла» спектаклен күрсәтте.

Россия башкаласында Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре тәмамланды. Мәскәү Ветераннар советында Муса Җәлил истәлегенә багышланган тематик очрашулар узды. ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов шагыйрь Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салды. Мәскәү халыкара музыка йортында Татарстан сәнгать осталары концертын Татарстан лидеры Рөстәм Миңнеханов белән бергә Мәскәү мэры Сергей Собянин да тамаша кылды.

Казанда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында XI Халыкара мөселман киносы фестивале уздырыла. Быел фестивальгә дөньяның 52 иленнән 735 гариза кабул ителгән, 25 илдән 51 фильм кертелгән. Фестиваль Төркия режиссеры Хәсән Кырачның «Слияние сердец» фильмы белән ачылып, Ренат Әюповның Г. Әпсәләмов романы буенча төшерелгән «Ак чәчәкләр» фильмы белән ябылачак.

КОТЛЫЙБЫЗ



Татарстан Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов Су спорты төрләренең XVI Дөнья чемпионатында катнашкан республика спортчылары белән очрашты һәм чемпионатның уңышлы тәмамлануы белән котлады. FINA президенты Хулио Маглионе аны Халыкара йөзү федерациясе тарихында иң яхшы чемпионат дип белдерүен искәртте. Очрашу барышында синхрон йөзү буенча Дөнья чемпионы булган Лилия Низамовага, шулай ук аның тренеры Нинель Кожедубка Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте белдерелде.

СПОРТ

Казанда Гимнастика үзәгендә нәфис гимнастика буенча Дөнья кубогы һәм «Йолдыз» халыкара турниры узды. Ул 30 илдән 180 спортчыны үзенә җыйды. Монда шәхси ярышлар һәм төркемле чыгышлар үткәрелде. Нәфис гимнастика буенча дөньякүләм йолдызлар – өч тапкыр Европа һәм Дөнья чемпионы Яна Кудрявцева белән ике тапкыр Европа һәм Дөнья чемпионы Маргарита Мамун Россия данын яклап чыгыш ясады.

МӘГАРИФ

Пенсионерлар арасында компьютер белеме буенча V Бөтенроссия чемпионаты Казанда узу гаҗәп тә түгел. Татарстанда күп өлкәдә электрон хезмәтләр күрсәтелә. Республикада пенсионерларның 70% ы махсус программа буенча компьютерда эшләргә өйрәнгән. Чемпионат барышында Татарстан команда зачетында беренче булды. Ярышта Россиянең 71 субъекты, шулай ук Абхазия, Беларусь, Бельгия, Польша, Словения һәм Финляндия вәкилләре катнашты. Чемпионатта катнашучыларның иң өлкәннәре Ямал-Ненец автономияле округыннан 79 яшьлек Раиса Палкина һәм Кабарда Балкариядән 76 яшьлек Мусарбий Дацирхоев иде. Татарстан данын Казаннан Сергей Мезенцев һәм Чаллыдан Зоя Гаус якладылар.

PRESSA.RU

– ИСӘНМЕСЕЗ?! ХӘЕРЛЕ КӨН! ЭШЛӘРЕГЕЗ НИЧЕК? ГАП-ГАДИ СҮЗЛӘР, ГАП-ГАДИ ХӘЛ БЕЛЕШҮ, БЕР КАРАСАҢ. ӘММА СИҢА БОЛАЙ ДИП ТУГАН ТЕЛЕҢДӘ БАШКА МИЛЛӘТ КЕШЕСЕ ЭНДӘШСӘ?





Гөлнур
ХӘСӘНШИНА

МАДАМ САДОВИНОВА

– Санкт-Петербургтан килгән бер студентым бар иде. Александр Иванов. «Дусларым арасында татарлар шактый», – дип дәрестә еш әйтә иде ул. Кайткач, әлбәттә, дусларына татарча дәшкән. «Ничек, Парижга барып татарча өйрәнеп кайттыңмы?!» – дип барысы да шаккатты», – дип язды ул миңа соңыннан.

...Француз теленә ул кечкенәдән гашыйк. Ни өчен, дип сорасаң, җавап та бирә алмас иде, мөгаен. Мәктәп елларында өстәлендә гел француз язучылары – Виктор Гюго, Стендаль, Оноре де Бальзак, Жорж Санд әсәрләре була. Ә хыялында – Эйфель манарасы, Елисей кырлары, Монмартр, Лувр... Калмык егете белән татар кызыннан туган Ләйләнең күңеле Европаның үзәге булган Франциягә, Парижга нигә тартылуының сәбәбен аңлап та, аңлатып та булмый. Гап-гади Казан кызы ул. Сыйныфташларыннан әтисе калмык булуы белән генә аерылып торган дисәм... Анисын да бик якын дус кызлары гына белгән. Лиджа ага Садовинов Татарстанга

сугыш елларында килеп эләгә. Татар кызы Гөлҗиһан белән алар госпитальдә таныша. Гәүдәсенең сул ягында исәпсез ярчык йөрткән ирне инде фронтка кире җибәрмиләр. Ул Казанда яшәп кала. Ике улын һәм бер кызын да татар дип яздыра. Әтисе гражданнар сугышында үлгән, әнисен иртә югалткан ятим егетнең Калмыкиядә беркеме дә булмый. «Калмыкча белмәгәч, шул туфракта үсмәгәч, ничек калмык була аласыз?» – ди ул.

Мәктәпне алтын медальгә тәмамлый Ләйлә. Укырга кая керәсе күптән билгеле – Казан дәүләт педагогика институтының чит телләр бүлеге. Яратып укый! V курска җиткәч, аны француз теле буенча Бөтенроссия конкурсында катнашырга җибәрәләр. Беренче урынны алып кайта! Илле алты уку йорты арасында!

Аннан... аннан соңгы егерме биш ел бертөслерәк үтә дисәң дә була. Кафедрада студентларга француз теле укыта. Өлкән укытучы вазыйфасына күтәрелә. «Аяккулым бәйләүле иде. Әни авырый... Башта әтине югалттык, аннан абыйны. Әнинең бу кадәр хәсрәткә йөрәге түзмәде. Аны ялгыз калдырмас өчен күп вакыт яртышар көн генә эшләргә мәҗбүр идем», – ди ул. 1985 елны институт аны Франциянең Ла-Рошель шәһәренә, рус теле буенча ассистент итеп җибәрә. Әмма ул ике ел бик тиз уза һәм барысы да кабат элеккеге эзгә төшә...

Туксанынчы еллар. Хезмәт хакы аз, тормыш авыр. «Транс-Тур» агентлыгы җәйге ял вакытында тәрҗемәче итеп эшләп алырга чакыргач, шуңа да бик теләп ризалаша Ләйлә. Бер ай булса да башка дөньяда яшәп алу бит ул! Кинәнгәнче французча сөйләшү, аралашу дигән сүз.

Круизга чыккан француз туристларына «мадам Ләйлә» Мәскәүне дә, Санкт-Петербургны да яраттыра. Ә кичен теплоходта чит ил кунакларына кичә оештыралар. Ул шигырьләр укый. Кичә тәмамлангач, Ләйлә янына бер ир кеше килә. «Гафу итегез, сез укыган бу матур шигырьләрнең кемнеке икәнен танымадым», – ди. «Юк, танымаган өчен кыенсынмагыз, авторы француз түгел, мин аларны үзем яздым», – ди ул. «Булмас?!» – ди яңа танышы гаҗәпләнеп.

Француз журналистлары профсоюзы органы булган «Рэвю Эндепандант» («Revue Independante») журналның президенты, элеккеге редакторы белән алар шулай очраклы гына танышалар.

– Шигырьләрегезне безгә туплап җибәрегез әле!

Ләйләнең: «Мин бит үзем өчен генә язам...» – диюен ул ишетергә дә теләми. «Тыңлаучыга күбрәк күренә!» – дип, аны шунда ук туктата. Җибәрә шигырьләрен Ләйлә, бастырып чыгаралар. Казанның меңьеллыгы якынлашкан көннәрдә Париждан аны тагын эзләп табалар. «Сез яшәгән каланың зур бәйрәме турында ишеттек. Языгыз әле безгә, француз журналистлары да Казан шәһәре турында белсен», – диләр. Яза, билгеле. Бер ел да узмый, Франциядән янә шалтырату: «Без сезне егерменче гасыр француз хатын-кыз шагыйрәләре антологиясенә кертмәкче булабыз. Өч шигырь һәм үзегез хакында мәгълүмат җибәрегез безгә». «Маргарит Юрсенар, Натали Саррот кебек шагыйрәләр белән беррәттәнме?» – дип аптырап кала ул. «Сезнең иҗатыгыз – татар кызының француз телендә язуы безгә шулай ук кызык», – диләр аңа. (Л. Садовинованың шигырьләре антологиянең дүртенче томына урнаштырылган.)

Шигырьләре салган юлдан кабат Франциягә барып чыгулар инде күпкә җиңелрәк була. 2006 елда Ләйлә ханымга Парижның Шәрык телләре һәм цивилизацияләре милли институтында – INALGOда эш тәкъдим итәләр. Дөньяның туксан алты теле өйрәтелә бу уку йортында. Һәм шул исәптән, татар теле дә!

Ул – институтта өч тел буенча дәрес бирә алучы сирәк белгечләрнең берсе.

– Сәгатьләребез күп түгел, билгеле: атнага ике сәгать тел, бер сәгать цивилизация өйрәнәбез. Кечкенә генә сюжетлар алабыз: гаиләм, эш көнем, шәһәрем... Татарстан тарихы, татар әдәбияты белән танышабыз. Беренче чиратта, Габдулла Тукай белән инде, әлбәттә. Аның «Туган тел» шигырен өйрәнәбез. (Мин аны французчага да тәрҗемә иттем, институт газетасында бастырдылар.) Бик талантлы бер студентым бар. Арно – филолог, ул хәзер Париждагы бер нәшриятта эшләячәк. Тукайны оригиналдан тәрҗемә итәргә тели! Сүзлекләр ярдәмендә бу эшне башкарып чыгармын, дип өметләнә. «Кулымнан килгән кадәр булышырмын. Тукайны тәрҗемә итү җиңел түгел, җаваплылыгы да бик зур», – дим аңа. Шагыйрьнең шигырьләре дә, шәхесе дә бик ошады, кызыклы тоелды Арнога. Институт газетасына студентлар өчен Тукай турында махсус язма да әзерләде. Үзе француз, әмма рус тамырлары да бар. «Татарча сүзләрең бик дөрес килеп чыга, татар тамырларың да юкмы икән синең?» – дип көләм. Рус департаменты оештырган бер кичәдә Тукай шигырен татарча сөйләгән иде. Укытучылар (ә алар бит барысы да филологлар, лингвистлар): «Сүзләрне ничек оригиналга якын итеп әйтте?! Без хәтта телне, аның матурлыгын, байлыгын тойдык», – диделәр. Французларга татар теле чагыштырмача җиңел тоела. «Ң», «Ү», «Ө»гә охшаган авазлар аларда да бар.

Студентларым минем дәрескә Казан, Татарстан турында бөтенләй белмичә, ишетмичә керә дип әйтә алмыйм. Аңарчы алар тарих укыйлар, беркадәр танышалар. Әмма татар телен Казаннан килгән татар кешесе укыту алар өчен бик зур роль уйный. Дәресне һәрвакыт татарча башлыйм: «Исәнмесез? Хәерле көн! Хәлләрегез ничек?» – дим. Шәкертләрем арасында кайсы гына милләт баласы юк?! Тугыз ел эчендә күпме студент узды инде кул астыннан, бүген алар кайларда гына эшләмиләр?! «Кайда гына яшәсәгез дә, татарча өч-дүрт җөмләне сез һәрвакыт хәтерләргә тиешсез, – дим мин аларга. – Исәнмесез?! Хәерле көн (иртә, кич)! Эшләрегез ничек? Минем исемем... Мин Парижда яшим». Мин беләм, кирәге чыкса, алар телне ныклабрак та өйрәнә алалар, чөнки нигез инде бар.

Мадам Садовинованы да, ул бик яратып өйрәткән татар телен дә элеккеге студентлары онытмый. Хатлар

PRESSA.RU

язып торалар һәм алар һәрвакыт татарча башлана. Әле менә тагын бер хат килгән: «Исәнмесез! Мин Варшавада яшим...» – дип башлана ул.

Ә Милена исемле бер студентыннан Ләйлә ханымга... Илһам Шакиров җырлары язылган диск килеп төшкән! Кайлардан тапкан?! «Бик сәләтле кыз. Венгр телен өйрәнә», – ди ул аның хакында.

Ләйлә ханым башта татар һәм рус телләрен генә укыткан. Аннан институт җитәкчелеге: «Студентлар: «Мадам Садовинова француз телен дә французларның үзләреннән яхшырак белә, дип әйтә», – дип, аңа француз теле дәресләрен дә биргәннәр. Исеме антологиягә кергән булуы да үз ролен уйнамый калмаган.

– Яшьләр белән эшләү шулкадәр ошый миңа! – ди ул. – Алар янында үзем дә яшәрәм. Яшермим, студентлар белән уртак тел таба беләм, яраталар алар мине. Тел генә өйрәтмим бит мин аларга. Игелек, яхшылык, бер-береңә ихтирам, хөрмәт кебек тормыш кыйммәтләрен дә күңелләренә салырга телим. «Татарстанда әллә никадәр милләт бар, бер-беребезне аңлап, дус-тату яшибез», – дим. Франциядә соңгы

Һәрберсенең күңел түрендә Татарстан, татар теле дигән кечкенә генә бер почмак бардыр дип уйлыйм.

вакытта бер дә тыныч түгел... Бу уңайдан, сорау арты сорау яудырып кына торалар алар. Милли мәсьәлә ничек хәл ителә, диләр. Татар теленең бездә дәүләт теле булуын, аны мәктәпләрдә укытылуын белеп бик гаҗәпләнәләр. Гадәттә, Россия булгач, анда бөтен җирдә дә русча гына сөйләшәләр дип күз алдына китергән булалар. Тарих та кызыксындыра аларны. «Кырым татарлары белән Казан татарлары бер үк милләтме?» – дип еш сорыйлар. Мондый сөйләшүләр күп вакыт чәй өстәле янында бара. Халкыбызның аш-сулары белән дә таныштырам аларны: өчпочмак, гөбәдия, кыстыбый... Чәкчәкнең нәрсә икәнен, тәмен студентларым да, хезмәттәшләрем дә белә – авыз иттерергә тырышам. (Хәер, ничек белмәсеннәр, чәкчәк турында институт газетасында махсус мәкалә дөнья күрә! – *Г. Х.*) Мин укыткан институт бик күп илләр белән студентлар алмаша. Һәр студенттан үз иле, үз туган теле турында сөйләтәм – шул вакытта без бер-беребез хакында күбрәк беләбез.

...Париж–Казан арасын елга ике тапкыр урый Ләйлә ханым. Кайткан саен китап җыя: альбомнар, сүзлекләр, дәреслекләр... Татарстан тарихы, Казан күренешләре... «Мин үземне Франция белән Татарстан арасында элемтәләр урнаштыручы, күпер салучы илче кебек итеп тә тоям», – ди ул. Ике ил арасында гынамы икән?! Ләйлә Садовинова укыткан институтка студентларның җир шарының бөтен почмакларыннан да җыелуын мин инде алдарак әйткән идем...

БЕЗ –

Беренче Татар яшьләре көннәре үткәрелүгә – 25 ел. Чирек гасыр! Ә бит ул көннәр кичә генә кебек иде...

...1990 ел, 17 июнь. Идел елгасы өстенә Асаф Вәлиев башкаруында «Әссәламегаләйкем» җыры тарала. Яңа көн туа... Моңарчы «Волга» дип йөртелгән яшьләр лагереның «Идел»гә әйләнеп татарча сөйләшә башлаган көне бу. (Без, оештыручылар, үзебез өчен башта ук бер кагыйдә керттек: кем генә сөйләшкәндә рус сүзе кыстырса да, уртак казнага акча кертә. Бер сүз – ун тиен. Ул чакта ун тиеннең кыйммәте бар иде әле!)

Максатлар – зурдан! Без бөтен дөньяга сибелеп яшәгән татар яшьләрен бергә җыярга, аралаштырырга, якынайтырга теләдек. Татарстан – һәммәбезнең уртак Ватаны, ул очрашу менә шушында, Идел ярында булырга тиеш! Һәр көн минутына кадәр бүленгән: очрашулар, дәресләр (бүгенгечә әйтсәк – мастер-класслар). Казанга сәяхәт, Кырлайга, Болгарга... Яшьләргә Казан Сабан туен күрсәтү! (Лагерьның үзендә дә узды Сабантуй. Читтә үскән яшьләрнең милли бәйрәмебездә тәүге тапкыр катнашуы иде ул! Бөтен шартын китердек: кичтән бүләген дә җыйдык, мәйдан уртасында көянтә-чиләк күтәреп тә, авызга йомырка кабып та узыштык; колга башында әтәч тә көтте, көрәштә батыр калучыны тәкә дә...) Кичке уеннар, татарча дискотека (беренче тапкыр!), гел үзебезчә сөйләп торган радио (монысы да – беренче!)... Ерак-ераклардан килүчеләрнең «килдем» дип түгел, «кайттым» дип әйтүләре дә беренче тапкыр «Идел»дә яңгырады. Төркиядә үскән, безнең яшьләрнең күбесеннән аермалы буларак саф татарча сөйләшкән Рушан Бичури да

«ИДЕЛ»ДӘН!

шулай диде. Әйе, әби-бабайлар туфрагына килмиләр, кайталар...

Эстония кызы Илсөяр белән Мамадыш егете Мөҗип шушы көннәрдә – безнең күз алдында таныштылар. (Ә көзен инде туй булды! Аларның олы уллары Искәндәр инде үсеп җитеп, Татар яшьләре көннәрендә катнашырга өлгерде. Гомер тиз уза... Хәер, Мариу шәһәрендә яшәүче, андагы татар оешмасы эшендә актив катнашучы Сабировларның быел көмеш туе бит. Сүз уңаеннан, 25 ел эчендә Татар яшьләре көннәрендә катнашкан яшьләр арасында 45 гаилә төзелгән!)

Хатирәләр бихисап! Изге Болгар җирендә таң каршылауны ничек онытасың... Яр читендә кичтән кабызган учагыбыз янды да янды. Утлы күмерләр өстендә, казанда пешкән корбан ите һәркемгә авыз итәргә җитте. Татар яшьләренең Болгарда яңа көнне каршы алуында зур мәгънә бар иде... Яисә соңгы көнне Камал театры каршында узган концерт-митингка килеп төшүебез: күзләр бездә генә – калфак таккан, аякларына татар читегешле чүәкләр кигән яшьләрне халыкның беренче күрүе. Кызык! Иң мөһиме – матур, килешә! Үзебезчә!

«Идел» лагеренда башланган рухи күтәрелеш, дулкын-дулкын булып, төбәкләргә таралды: Татар яшьләре көннәрендә катнашучылар кайтып, үзләрендәге татар яшьләрен кузгатып җибәрде. Сембердә, Уфада, Самарада, Мәскәүдә, Бакуда, Әстерханда, Төмәндә, Чиләбедә... Берләшү шулай башланды.

Татар яшьләре көннәре бүген дә Россиянең төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче татар яшьләрен берләштерүче төп чара булып тора. Аларның да көннәре минутына кадәр бүленгән: татар теле, тарих, дин, вокал, хореография буенча мастер-класслар, семинар-тренинг, түгәрәк өстәл, диспутлар, дәүләт эшлеклеләре һәм иҗтимагый оешма җитәкчеләре белән очрашулар... Яшьләр шундый ук кыю, тәвәккәл, тынгысыз. Ә без, Татар яшьләре көннәренең беренчесен оештыручылар...

Без һаман бергә! Ләйлә Гаффарова (тәрҗемәче) «Фейсбук»ка бергә төшкән рәсемебезне куярга өлгермәде, аның астында Рушан Бичуриның (Сингапур) язуы пәйда булды: «25 елга сузылган дуслык...» Шуның артыннан ук Рим Гыйльфанов (Чехия, Прага, «Азатлык» радиосы, Татар яшьләре көннәрен оештыруның башында торучыларның берсе): «Барыгызга да сәлам!» – дип язды. Сәгыйть Хәйринең (Төркия, Әнкара, «Төркия авазы» радиосы. Татар яшьләре көннәренең иң беренчесендә лагерьның радиосын ул татарча сөйләткән иде инде!) тапшыру әзерләгән чагы иде бугай – бу язулар астына «лайк» кына куеп чыкты. Вакыты тыгыз, әмма уе белән ул да монда, димәк!) Ара ераклыгын онытып «сөйләшүебезгә» Мәскәүдән Гөлнара Зыятдинова кушылды: «Әле генә Радик (Радик Гыйматдинов, Татарстан Республикасы Президенты киңәшчесе) белән Мәскәүдә узучы Татарстан көннәренең гала-концертында очраштык. Күңелебез белән без дә сезнең янда!» Әйе, без төрлебез төрле якларга таралыштык. (Ирек Гарипов әнә дөньяның бишенче кыйтгасыннан – Австралиядән үк кайтты!) Әмма кайда яшәсәк тә, беребез дә татар теленнән, милләттән аерылмады, кайда гына эшләсәк тә, барыбыз да татар халкына хезмәт итә. Балаларыбыз татар булып үсә.

Ә ул җәйне без үзалдыбызга куйган югары максатлар? Алар чынга ашмады дип әйтә алмыйбыз. Татар яшьләре көннәренең юбилеена җыелдык менә. Без башлаган эш дәвам итә!











PRESSA.RU



КЕШЕ КАЙЧАН МАТУР БУЛА?

Рәзилә ГАЛЛӘМОВА

ЧИБӘР КЫЗЛАР ЯШӘГӘН ТӨБӘКЛӘРНЕҢ БЕРСЕ БУЛГАНГАМЫ, ӘЛЛӘ ИНДЕ МОНДА БИК АКТИВ ҖӘМӘГАТЬЧЕЛӘР ЭШЛӘГӘНГӘМЕ – МАТУРЛЫК БӘЙГЕСЕН БЫЕЛ ДА КИЛГӘН КУНАКЛАРНЫ ШАККАТТЫРЫРЛЫК ИТЕП ҮТКӘРДЕЛӘР БАШКОРТСТАНДА.

Быелтыр ярышларның Бөтенроссия этабында безнең Алинә Гыйззәтуллина җиңеп чыкса, быел «Татар кызы-2015» калфагын берьюлы ике кызыбыз дәгъва итә. Гадәттә, һәрбер төбәкнең данын бер генә кыз яклый ала иде бит. Ә быел Бөтендөнья татар конгрессы рәисе Ринат Закиров җитәкләгән жюри, Башкортстандагы сайлап алу этабының югары дәрәҗәдә үткәрелүен ассызыклап, җиңүче Альбина Хаматова янына тагын бер сылу кызыбызны сайлап алырга рөхсәт итте. Конкурсның төп оештыручысы булган «Берлек» мәдәни-агарту оешмасы әгъзалары бик сөенеп, үз җиңүчесен билгеләде: Алинә Шакирова чыннан да лаек иде шул! Кызлар, бергәләшеп, Чиләбе шәһәрендә үтәчәк финал тамашасына әзерләнә хәзер. Әйе-әйе, бергәләшеп! Чөнки алар арасында бернинди көндәшлек тә юк. Алинәне күргәч: «Икегез дә җиңүче, һәрберегез беренче булырга лаек, ә нинди сыйфатлар белән сез аерыласыз?» – дип сорадым бераз чеметтереп. «Табигать көчләре белән чагыштырсак, Альбина ул – ут, ә мин – су. Аңа гел сокланып карыйм. Үзе чибәр, үзе акыллы, җыр-биюгә дә оста... Альбина бик җитез, тере кыз, тирә-якка очкын чәчеп, гел елмаеп тора. Ә мин тыныч холыклы, йомшак күңелле, һәрчак уйланып, хыялга бирелеп, җиденче кат күктә йөзеп йөрим. Көндәлек тормышның ыгы-зыгысына ияреп, үз асылың, тарихың, милли язмыш турында сирәк уйланасың бит. Ә конкурс миңа тормышта үз урынымны аңларга ярдәм итте. Без бит татар кызлары. Бу горур исемне йөртүебез хакында бер минутка да онытырга ярамый. Хәзер һәрбер кылган эшемне, карарымны бу татар кызы исеменә лаекмы дигән күзлектән бәһалим!»

Яшь булуына карамастан, Алинәнең яулаган үрләре бихисап. Шулай да иң кадерлесе, мөгаен, икенче сыйныфта укыганда «Чакмагыш тургае» конкурсында гран-при яулавы булгандыр. Бүген дә сагынып искә төшерә ул чакны. Тавышы белән барысын да әсир иткән кызчыкка бик зур ваза бүләк итәләр. Бәхетле Алинә кадерле бүләген бер атна кочаклап йоклый... Бу беренче урын зур җиңүләрнең башы була, үз-үзенә ышанычын арттыра, иңнәренә канат куя.

Гади генә кыз булып түгел, үз иленә файдалы кеше булып үсәсе килә Алинәнең. Нәкъ картәтисе кебек. Озак еллар «Игенче» дип исемләнгән Чакмагыш районы газетасының баш мөхәррире булып эшли картәтисе Хәйдәр Фәйзрахман улы Басыйров. «Без бәләкәй чакта аның белән концертка да, музейга да барабыз, базарга да йөрибез, һәм кайда да картәтием белән барысы да туктап исәнләшә, үз хәлләрен сөйләп, киңәшләшеп китә иде. Бәйрәмнәрдә аны котларга әле дә бик күп хөрмәтле кешеләр килә», – дип искә төшерә Алинә. Бүген Хәйдәр Фәйзрахман улына 76 яшь булса да, ул һаман да сафта. Үз якташлары турында китаплар бастыра, архивларда утыра, төрле кызыклы чаралар оештыра. Янәшәсендә – тугры юлдашы Фәһимә апа. Аларның бар дөньясы балкып тора: йортлары, каралты-курасы, бакчалары дисеңме!.. Бала баласы балдан татлы Алинә менә шундый мохиттә сөелеп үскән инде! Үз картәти-картәнисе хакында зур җылылык белән сөйли ул. Бу матур пар – аның яшәү идеалы. «Түгәрәк өстәл янында бар туганнар җыелышып, үз уңышлары турында сөйләгәндә, миннән дә бәхетле кеше юктыр, – ди ул. – Әниемнең абыйсы Айдар Басыйров Чакмагыш музееен җитәкли, ул да туган як тарихын өйрәнүче буларак билгеле кеше.

«Татар кызы» бәйгесе уйларымны тәртипкә китерде кебек.

Әтием Рифат – шәхси эшкуар, әнием Эльза халыкка иминлек хезмәте күрсәтү өлкәсендә эшли. Апам Эльвина белән энем Сабур да тырышлар, булдыклылар. Туган ягым үсешенә зур өлеш кертеп, матур хыялларымны тормышка ашырып яшисем килә минем. Картәтием өйрәткәнчә, Ренат Харис сүзләрен еш искә төшерәм. Ул минем тормыш шигаремә әйләнде инде:

Кеше кайчан матур була? / Кеше матур шул вакыт – / Иле өчен, халкы өчен / Яшәгәндә җан атып...

Тик барысы да без теләгәнчә генә килеп чыкмый шул, дип, Алинә тормышындагы иң зур җиңелүен искә төшерә. Мәктәпне тәмамлаганда аның алдында кайда укырга керергә дигән сорау тормый, бу җавап сигезенче сыйныфтан ук билгеле була. Әлбәттә, Казан! Әлбәттә, университет! Татар мәдәни тормышында кайнап яшисе килә

PRESSA.RU





аның. Бюджет урынына үтәр өчен Алинәгә нибары 2 балл җитми кала. «Укырга кергән бәхетлеләр исемлегендә үземне тапмагач, аяк асларымнан җир шуып киткәндәй булды. Башта утырып еладым, тик күз яшьләре агызып, морадыңа ирешә алмыйсың шул. Ихтыяр көчемне җыйдым да, моның белән дөнья бетмәгән бит дип, Башкорт дәүләт университетының роман-герман филологиясе факультетына документларымны тапшырдым һәм... үттем», – ди Алинә.

Һәр башлаган эшемдә якыннарымның ярдәмен тоеп яшим.

Әле бу вакыйгага фәлсәфи яктан карый ул. Барысы да Ходай кулында. Килеп чыкмаган икән – димәк, язмаган. Бер ишек ябылганда, аның икенчесе, тагын да затлырагы ачыла бит. Уфа университетында уку еллары искиткеч гүзәл вакыйгалары белән истә калган. Беренчедән, Алинә Шакирова инглиз телен камилләштереп, «Work and travel» программасы буенча Америка Кушма Штатларында эшләп кайта. Бәләкәй чакта сатучылы уйнарга ничек яраталар иде, менә монда – Америкада чын-чынлап шундый эш язган икән. Сәгатенә 7 доллар акча алып, өч ай дәвамында уенчыклар сату кибетендә эшли. Зур матур кибетләрдә позитив америкаbаннар белән аралашу аны тагын да чарлый гына. Алда – яңа эшләр, яңа кешеләр, яңа мөмкинлекләр. Кайткач, якыннары янында бер ай да тормыйча, янә чемоданнарын җыеп, Кытайга чыгып китә. Бу юлы озаккарак – ел ярымга. Бәләкәй чактан ук бу илгә барырга хыялланган кыз студентлар белән алмашу программасы буенча кытай телен өйрәнү мөмкинлеген кулыннан ычкындырмый инде. Очрап торган кыенлыклар да, әти-әнисен сагыну да, чит илдә бөтен нәрсәне берьялгызы гына хәл итү дә комачаулый алмый – 18 яшьлек кызга үз проблемаларын инде мөстәкыйль рәвештә чишәргә туры килә. Ә Кытайга мәхәббәтне әтисе уяткан була. Рифат абый үзе бу илгә барып кайткач, тәэссоратлары белән иң беренче үз якыннары белән уртаклаша. Кечкенә Алинәне бу сөйләшүләр, фотографияләр карау шулкадәр дулкынландыра ки, ул үзе дә бу серле ил белән танышып кайтырга карар кыла. Җиңел булмый, әлбәттә. Кытайда укыганда Алинәне модель буларак та эшкә чакыралар: зифа буйлы, зур күзле, игымлы татар кызы беркемне дә битараф калдырмый. Аны күбрәк испан яки һинд кызына охшаталар. Мин татар кызы дигәч, аптырап калалар кытайлар. «Татар» дип аталган халык Кытайның Шен-Жан провинциясендә дә яши бит. «Үз баламны ел ярымга башка илгә җибәрергә батырчылык итмәс идем, – ди бүген Алинә, елмаеп. – Әмма ләкин вакыт барысын да дәвалый. Әни булгач, бәлки, башкача фикер йөртермен...»

Россияне, АКШны һәм Кытайны чагыштырсаң, бу илләр көнкүреш ягыннан гына түгел, ә балалар тәрбияләү тәртибе белән дә аерыла. Америкада балага 18 яшь тулса, ул мөстәкыйль тормыш белән яши башлый, әти-әниләре аларга бик сирәк очракта гына ярдәм итә. Кытай белән Россиядә гаилә мөнәсәбәтләре бик көчле. Тик күршеләребезгә гаиләдә бер генә бала тәрбияләргә рөхсәт булгангамы, анда кызларны бик кадерләп, «өф-өф» итеп кенә үстерәләр: гадәттә, алар өй җыештыра да, ашарга да пешерә белми, күбрәк карьера турында кайгырталар икән.

Карьера дигәннән, Алинәгә университетны тәмамларга бер ел калса да, бүген ул тел өйрәнү курсларында кытай теле укытучысы булып эшли. Башкортстанда Бәйсез дәүләтләр

бердәмлеге илләренең саммиты үткәч, кытай телен өйрәнергә теләүчеләр тагын да артты. Ә бу экзотик телне яхшы сыйфатта өйрәтә алырлык белгечләр, киресенчә, бик аз. Шуңа күрә Алинәгә тәкъдимнәр көн саен килеп тора. Кытай теленнән тыш, ул инглиз, немец, француз телләрендә дә иркен аралаша. Татарчасын да камилләштерергә тырыша. Уфада туып-үскән шәһәр кызы булгач, конкурска килгәндә татарчасы йомшаграк иде. Яңа дуслар табып, төрле милли чараларда катнашып, туган телен шактый шомартты.

Күптән түгел Кытайдан кайтып төште Алинә. Анда тәрҗемәче булып «Идел – Янцзы» яшьләр форумында эшләгән. 1 сентябрьдән инде – мәктәптә, кытай теле укытучысы итеп чакырдылар аны. Педагогика буенча китаплар укый, дәрес планнары төзи. 21 яшьлек яшь укытучының күңелендә мең төрле уйлар: «Балалар аны ничек кабул итәр? Һәр баланың йөрәгенә кирәкле ачкыч таба алырмы ул? Быел университетның да соңгы курсы: бар җирдә дә ничек өлгерергә икән? «Татар кызы»нда да сынатмаска, якыннарның йөзенә кызыллык китермәскә кирәк...»

Шаян кыз киләчәккә планнары турында оялып кына, бераз саклык белән сөйли. Ачылып китәргә ашыкмый, әлегә сер булып калсын, дип куя. Киләчәктә үзеңне кем итеп күз алдыңа китерәсең, дигән соравыма: «Матур гаиләмне булдырасым, күркәм йортыбызда тормыш иптәшем белән тупылдатып өч ул, бер кыз үстерәсем килә. Тик барысы да Ходай кулында», – дип җавап бирде Алинә. Әлегә ул үз яртысын очратмаган, моңа да бик аптырамый, димәк, вакыты җитмәгән. Булдыклы ирнең хәләле булыр өчен кыз балага бар яктан да камиллеккә омтылырга кирәк, дигән фикердә ул. Тән матурлыгы турында гына сүз бармый, билгеле. Үзәктә – күңел, җан, хис, акыл матурлыгы.

Зур күзләрен ачып, озын керфекләрен сирпеп уянып, һәр таңда «мин булдырам» дип яңа көнгә аяк баскан Алинәнең бар ниятләре дә тормышка ашар дип ышанасы килә.

Фото: Эрик Асаев



Зәлия АХУНОВА – Башкортстан Республикасы «Татар кызы» бәйгесенең оештыру комитеты рәисе, «Берлек» милли-агарту оешмасы рәисе урынбасары.

Без, оештыручыларның, максаты – яшьләрнең энергиясен матур һәм якты эшләргә юнәлтү. Конкурста без тышкы кыяфәткә генә игътибар итмибез. Кызларның рухи дөньясы да, таланты, иҗади казанышлары, шәхси сыйфатлары да зур роль уйный. Яшьләрне республикада үткән мәдәни чараларга мөмкин кадәр күбрәк җәлеп итәсебез килә. Азга гына булса да интернеттагы фотолардан, телевизор, төнге клублардан «тартып алу», фотошопсыз һәм фонограммасыз чын матурлыкны, виртуаль түгел, ә чын бәйгене күрсәтү өчен тырышабыз. Сәхнәдә безнең күрше авыл яки күрше урам кызлары бит! Һәм алар һич кенә дә модельләрдән ким түгел!

Конкурс һәрвакыт дустанә мөнәсәбәттә үтә. Конкурстан соң барлык катнашучы кызлар да үзгәрә. Нигездә, кызлар авылдан килә, ә аларның күбесе сәхнә һәм куелган шоу белән таныш түгел. Профессиональ дефиле мәктәбе генә түгел, психологик яктан да зур мәктәп бу. Ун көн дәвамында кызлар белән профессиональ иҗат төркеме эшли: режиссер, хореограф, дефиле куючы, актерлык осталыгы, сөйләм теле буенча репетиторлар, тавыш куючы, тавыш-көйне яздыручы, фотографлар, бизәндерүчечәчтарашчылар... Шулай ук сәхнә бизәлеше, яктылыкның дөрес кулланылышы, монитор-экрандагы видеорәтләр дә бик зур роль уйный.

Узган ел Мәскәүдә үткән «Татар кызы» бәйгесендә дә, Казандагы «Авыл кызы» конкурсында да безнең «Нәүрүз гүзәлләре» җиңеп чыкты!

Быел конкурсның исемен алыштырып кына калмадык, аңа башка юнәлеш тә бирдек. «Татар кызы» матурлык бәйгесенең үзенчәлеге шунда: конкурс гүзәлләр ярышы, шоу-тамаша форматыннан киңрәк. Быел без аның концепциясен заман сулышыннан чыгып билгеләдек.

Проектның иң зур казанышы – интеллектуаль конкурста татар хатын-кызының бай рухи дөньясын күрсәтә алдык. Бу идея күренекле мәгърифәтче Мәрьям Солтанова-Акчурина истәлегенә багышланган кичәдән соң туган иде. Исемнәре тарихка алтын хәрефләр белән язылган, без үрнәк алып яшәрлек шәхесләре байтак халкыбызның. Аларның һәрберсендә безнең күңелләрне баетырлык аерым сыйфатлар бар. Нәкъ энҗедәй тезелгән күңел бизәкләре милләт анасының җыелма образын гәүдәләндерә дә инде. Сәхнәдән күңел матурлыгын күрсәтә алу – бар иҗади төркемнең осталыгын билгеләгән зур казаныш ул.

Чараның тагын бер матур җиңүе – татар эшкуарларының милли проектларга җәлеп ителүе. Алар милләтебезнең матур киләчәгенә багышланган уртак эшебездә үз өлешен тоя башлады инде. Бар уңышларыбыз да менә шул бердәм команда эшчәнлеге нәтиҗәсе.

Оештыру төркеме күбесенчә милләтебезнең асыл хатын-кызларыннан торгангамы, аларның күңел җылысы тигән һәр башлангыч аеруча матур һәм эчтәлекле уза. Гүзәлләрдән-гүзәл нәфис затлар борын-борын заманнан көчле ир-егетләребезне рухландырып, яхшы гамәлләргә этәргән түгелме соң? Кызларыбыз бүген әти-әнисенең өмете булса, иртәгә – гаилә тоткасы, ил ышанычы. Нәкъ хатын-кыз тудырган гүзәллек – мәхәббәт, дуслык кебек мәңгелек хисләрнең бердәнбер башлангычыдыр. Һәм «Татар кызы» моңа булышлык итә. Без бу чарада иң-иңнәрне күрсәтеп, милләтебезнең өметле кызлары белән таныштырып, кешеләрнең күңелендә үз халкының үткәне һәм бүгенгесе өчен горурлык хисе уятырга тырышабыз.

PRESSA.RU

Исеме үк үзенчәлекле булган бу бакча Казанның үзәгендә, Гоголь, Щапов, Мөштәри һәм Горький урамнары киселешендә урнашкан. Кечкенә булуына карамастан, казанлыларның яратып йөри торган урыннарының берсе ул.
Бакчаның «Лядской» дип аталуының кызыклы тарихы да бар.










Хәзер Державин һәйкәле торган урында XVIII гасырда генерал Александр Лецкойның бер катлы агач йорты урнашкан була. Нәкъ менә шушы кеше бирегә агачлар, куаклар утыртып, бакча булдыра. Аны карап, тәрбияләп тору өчен көчен дә, вакытын да кызганмый. Ул чорда бакчаны кулына кувшин тоткан кыз сыны бизи. Төнлә бакчаны 600 шәмле дуга сыман фонарьлар яктыртып тора.
1798 елда Казанга килгәч, император Павел I нәкъ менә Лецкой йортында туктала. Шәһәрдән киткәннән соң, кунакчыл хуҗага рәхмәт йөзеннән, бакча янындагы урамны (хәзерге Горький урамы) генерал Лецкой исеме белән атарга боера. Соңрак урам янындагы бакчаны да Лецкой исеме белән атап йөртә башлыйлар. Генерал аны атаклы кешеләрнең ял итү урынына әверелдерә. Монда бай катлам кешеләре үзара очраша, агачлар күләгәсендә рәхәтләнеп гәп корып утыра торган була.





ЛЯДСКОЙ БАКЧАСЫ



Халык арасында Лецкой фамилиясен бозып, Лядской дип сөйләшү таралган булган.
Тора-бара бакчаның исеме дә үзгәреп, Лядской бакчасы дип йөртелә башлый.
Совет елларында бакча шактый үзгәрешләр кичерә. Анда Горькийга һәйкәл куела, халык телендә «алма» дип аталучы фонтан урнаштырыла (шар формасында булганлыктан, «алма» атамасы аңа бик туры килеп тора), генерал Лецкойның агач йорты сүтелә.
2000 елың җәендә Лядской бакчасы тулысынча төзекләндерелә. Аллеялар чистартыла, агачлар һәм куаклар тигезләп киселә, яңа юллар, сукмаклар салына. Гавриил Романович Державинның элек «Бакыр бабай бакчасы»нда торган бронза һәйкәле монда куела.



Быел җәй Лядской бакчасы янә бер кат яңартылды. Анда йөздән артык агач һәм куак утыртылды, сукмакларга яңа таш җәелде, фонтан үзгәртелде. Хәзер монда балалар өчен өр-яңа уен мәйданчыгы, спорт мәйданы бар. Түләүсез wi-fi эшли. Киләчәктә бакча түренә сәхнә дә ясап куярга ниятлиләр.
Яңартылган бакча тантаналы төстә 2015 елның 6 сентябрендә ачылды. Аның ачылышында Татарстан лидеры Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Рәхәтләнеп ял итәсегез, җан тынычлыгы табасыгыз, тарих белән күзгә-күз очрашасагыз килә икән, Лядской бакчасына рәхим итегез!

Сәхифәне Татарстан Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре Ленар НӘГЫЙМОВ алып бара.
Фотолар: Татарстан Республикасының Милли музей фондыннан.

PRESSA.RU



Гүзәл Яхина Китап фестивалендә чыгыш ясый. Мәскәү, 28 июнь, 2015 ел.
© Фото АСТ нәшриятының матбугат үзәгеннән алынды.

ҮЛЕМНЕ ҖИҢГӘН МӘХӘББӘТ



«Бәхет әрнүле дә була. Минем китабым шул хакта, – ди ул. – Себергә элеккеч кенә Зөләйха мәхәббәтен очрата, дуслар таба, әни була... Бәхете аны әнә шунда – җир читендә көтә. Дөньяга күзләре дә шушында ачыла...»
Утызынчы елның кышы. Татар авылы. Ирен атып үтерәләр, йөз яшькә җитеп килүче кайнанасын ялгызын ташлап калдыралар, ә аны «кулак хатыны» дип, вагон-теплушкада Себергә сөрәләр. Унбиш яшендә кырык биш яшьлек иргә кияүгә барган, Мортазасы сукса да: «И-и, ирем нинди әйбәт, үтергәнче кыйнамады бит әле», – дип чын күңелдән сөенеп торган Зөләйханы яшәү өчен көрәш бөтереп ала...
«Большая книга» дигән милли әдәби премиягә (Россиядә әдәбият буенча иң саллы бүләк!) быел тәкъдим ителгән 338 китап арасыннан «кыска исемлек»кә узган тугыз әсәрнең берсе – «Зөләйха күзләрен ача» («Зулейха открывает глаза») дип атала. Аның авторы – Гүзәл Яхина – безнең якташыбыз. Казан дәүләт педагогика университетының чит телләр факультетын тәмамлаган. Мәскәү кино мәктәбе дипломына ия. Мәскәүдә яши. Кияүдә, бер кыз үстерә. Рус телендә яза.
«Гаҗәеп дебют! Ел ачышы!» Китапка язган кереш сүзендә язучы Людмила Улицкая якташыбызның романына шундый бәя бирә. Фазыл Искәндәр, Анатолий Ким, Олжас Сөләйманов, Чыңгыз Айтматов... Гүзәл Яхинаны ул шушы атаклы язучылар белән бер рәткә куя. Алар мәктәбен дәвам итүен: милли материалны тирәннән белеп, үз халкын яратып, башка милләтләргә карата хөрмәт белән иҗат итүен искәртә. «Чын әдәбият шундый була – ул йөрәккә үтеп керә», – бу да Улицкая сүзләре.
«Зөләйха күзләрен ача» – яшь язучының иң беренче романы. Ә хәзер сүз Гүзәлнең үзенә. Әти-әнисе янында бик еш була ул – аның белән Казанда күрештек.

P. S. «Зөләйха күзләрен ача» романы «Ел китабы» бәйгесенең «Ел прозасы» номинациясендә җиңүче дип табылды. Котлыйбыз!

«Мин бәхетле бала: әби-бабайлар белән үстем. Шуңа күрә балалар бакчасына киткәнче фәкать татарча гына сөйләшүем гаҗәп түгел. Әниемнең тамырлары авылдан, Саба ягыннан. Дөрес, бабайлар алтмышынчы еллар ахырында ук Казанга күчеп килгәннәр. Әмма монда да алар үз йортлары белән тордылар. (Китапта татар авылы тормышын сурәтләгәндә әби белән бабай өен искә төшердем. Аларда татар гаиләсендәге бөтен гореф-гадәт, тәртип саклана иде: бусагага басмыйча, атлап чыгу, бабай килмичә, табын янына утырмау, аңардан алда ризыкка үрелмәү, ипине уң кул белән генә сузылып алу... Ипине бабай үзе кисә, үзе өләшеп чыга иде. Романга кергән татарча сүзләр дә барысы да әби белән бабайдан ишетеп, күңелгә сеңеп калган сүзләр. Мин аларны хәтеремнән яңарттым гына.)

Романның беренче өлешендә татарча сүзләр – җөмлә саен. Бу – әсәрне баета, аңа үзгә төсмер өсти, укучыны татар дөньясына алып керә.

Әтием ягыннан әбием белән бабам – Казан татарлары, алар шәһәрнең үзәгендә яшәде – мин алар янында үстем дисәм дә була. Әтиемнең әнисе – ихтиолог, Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, Балык Бистәсендә эшләгән. Аннан, балалар тугач, өйдә генә торган. Юк, безнең нәселдә язучылар булмаган. Әмма иҗат белән шөгыльләнүчеләр бар. Гыйльметдин бабам Гыйләҗиевның (әнинең әтисе) Казанда, күргәзмәләр залында шәхси күргәзмәсен үткәрүен, ул чакта кечкенә булсам да, мин дә хәтерлим. Ботаклы-чатаклы агачлардан әллә ниләр ясый иде ул! Өйләре музей кебек иде аларның.

Китабымда күтәрелгән сөргенгә сөрелү темасы, кызганычка каршы, безнең нәселне дә урап узмаган. Бу хакта үземне белә башлаганны бирле ишетеп үстем. Рәйсә әбиемнең (әнинең әнисе) гаиләсен беренче тапкыр Себергә озатырга дип килгәч, бөтен Җөри авылы халкы күтәрелеп чыгып, яклап кала. Икенче юлы алар капкасын кара төндә шакыйлар... Җиде яшьлек кызчык олылар белән бергә шул озын, авыр юлны уза. Маршрут нәкъ китаптагы кебек: вагон-теплушкаларда Красноярск

PRESSA.RU

шәһәренә, аннан су юлы белән Ангарага... Романымда күченүчеләр төялгән баржа батуы сурәтләнгән урын бар. Әбиләр белән, чыннан да, шундый хәл була: аларны алып баручы ике баржаның берсе су төбенә китә. Аннан соң да барысы да нәкъ китапта язылганча: халыкны яр читендә, кыргый тайгада ташлап калдыралар. Суга батудан котылганнарның күбесе землянкалар казып кергәнче кырыла. Исән калганнар әкрен генә җайлаша: тайга читендә, биек яр өстендә кечкенә генә бистә калка – Пит-Городок. Чынлыкта ул әнә шулай аталган. Янәшәдә генә – «Аяхта» руднигы. Рәйсә әбием дә, аның барча туганнары да алтын юалар. Боз кебек салкын суда... Рәйсә әбиемнең уналты ел гомере Ангара ярындагы шушы бистәдә уза. Байлар Сабасына ул 1946 елны кайтып төшә. Кире әйләнеп кайтканда, татарчага караганда Себер акценты белән русча әйбәтрәк сөйләшә торган була – туган телен өр-яңадан өйрәнә. Педучилище тәмамлап кайткан кызны башлангыч сыйныфлар укытучысы итеп куялар. (Сүз уңаеннан әйтеп китим әле, әбием Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның беренче укытучысы!) Ә булачак бабам шушы ук мәктәптә директор булып эшли, немец теле укыта. Алар шулай танышалар... (Байлар Сабасындагы 1 нче санлы мәктәптәге кечкенә генә музейда әбием белән бабама багышланган стенд та бар. Каберләрен зиярәт кылырга кайткач, мәктәпкә дә сугылырга тырышабыз.)

Китап сөргенгә сөрү, НКВД, татарлар, мөселманнар, христианнар, Казан һәм Себер хакында. Әмма иң беренче чиратта ул Хатын-кыз турында.

Әби Ангарада узган балачагы, яшьлек еллары турында искә төшерергә бик яратмый иде. (Төпченеп, ныклап сорашырга өлгермәдем шул. Алда гел вакыт бар кебек тоела бит, аннан карыйсың, ул кешеләр инде киткән була. Минем дә булды шундый ялгышым...) Себер чоры аның холкында шактый сизелә иде: көчле, нык, ир-атлар кебек. Ә үзе кечкенә генә буйлы, ябык, мөлдерәп торган яшел күзле... Минем Зөләйхам әбиемә бик охшаган. (Ә Зөләйханың кайнанасы – Убырлы карчыкның прототибы, чыннан да, бар дип әйтә алам. Бабаемның әнисенә охшатып яздым мин аны. Ул шундый көчле рухлы, кырыс хатын булган. Юк, тормышта беркемне дә үтермәгән, ачтан тилмертмәгән, әлбәттә. Безгә – оныкларына – бердәнбер фотосурәте һәм аның турында килеп ирешкән хикәятләр буенча билгеле иде.)

Китап язу уе миндә ике ел элек туды. Архивларны хәзер интернет алыштыра: «Сахаров үзәге» сайтында бик озак утырдым, мемуарлар, хатирәләр укыдым, шушы темага язылган фәнни эшләр белән таныштым. Бистәне барып күрәсе иде, дигән уй китапка тотынганчы ук туган иде. Шактый талпындым... Кызганычка каршы, ул бистә хәзер юк икән инде. «Аяхта» руднигы тора-бара саега, аннан ул бөтенләй ябыла. Дөрес, күпмедер вакыт бистә яши әле. Анда әйбәт кенә колхоз була, яшелчә, җиләк-җимеш үстерәләр. Әмма тора-бара тормыш сүнә. Советлар Союзы таралгач, 2003 елларда халык аннан китеп бетә. Бистәнең интернетка куелган соңгы фотосурәтләре астына «2005 ел» дип язылган. Янәшәдән байдаркадаларда үтеп баручы туристлар төшергән аны. Шактый кызганыч күренешләр. Ташландык өйләр, нигезләр... Тайга барысын да басып, йотып килә. Бәлки, бу дөрестер дә, тайганың үзеннән тартып алганны кире үзенә кайтаруы, дим. Пит-Городокны күрү өчен Лесосибирск шәһәреннән 300 чакрым су буйлап барырга кирәк. Дөресен әйтәм, ераграк тоелды, куркытты.

Китапны бастыру өчен нәшрият бик озак эзләдем. Бик күп җирләргә мөрәҗәгать итеп карадым – уңай җавап көтеп җиткезә алмадым. Аннан очраклы рәвештә генә Елена Костюкович белән таныштым. Ул атаклы тәрҗемәче, язучы, Европада яши, үз әдәби агентлыгы бар. Аның аша инде Елена Шубинага, аның нәшриятына чыктым. Шулай итеп, китабым дөнья күрде... Улицкаяның сүз башы язуы – анысы да агентлык эше. Аңардан шундый җылы фикерләр ишетү – көтелмәгән сөенеч, язмышның бер бүләге булды, дисәм дә ярый. Премиягә дә китапны нәшрият үзе куйды. «Кыска исемлек»кә эләгү хакында мин, әлбәттә, хыяллана да алмадым. Моңа әле дә ышанып бетмим! Фантастика! Илнең генә түгел, дөньядагы иң зур премияләренең берсе бит бу. Бу вакыйга сөенеч кенә түгел, бер үк вакытта зур җаваплылык та.

Китапны иң беренче булып якыннарым: әти белән әни, кайнанам, ирем, дусларым укыды. Әбием исән булсын иде хәзер – ничекләр сөенер иде ул!.. Гаяз Исхакыйның «Зөләйха»сы белән мин таныш, фильмын карадым. Әмма төп героиняны ничек атарга дигәч, бүтән исем башыма килмәде... «Зөләйха күзләрен ача» буенча кайчан да булса фильм төшерелерме, юкмы, анысын белмим. Әмма бу тарихны мин башта сценарий итеп язган идем.

Ленинградның затлы, зыялы галиме Константин Арнольдович һәм аның хатыны Изабелла, рәссам Иконников, Казаннан профессор Лейбе, кызыл командир Игнатов, төрмәче Горелов... Юк, Себергә алып китүче юлда Зөләйха ялгыз булмый. Аның алдында ачылган яңа дөнья хатыннан сүзсез буйсынуны түгел, уйлауны, һәрнәрсәгә үз фикере булуны, һәр адымы өчен җаваплылык тоюны таләп итә. Ә Ангара ярында туган бердәнбер улына булган Ана Мәхәббәте барлык авырлыкларны җиңәргә булыша...

Укучыларның китап өчен тавыш бирүе бүген өч сайтта бара (ЛитРес, PeadRate Bookmate). Көз ахырына кадәр, шушы сайтларга кереп, премиягә куелган 9 китап белән танышырга һәм үзегезгә ошаганы өчен тавыш бирергә була. Премия тапшыру тантанасында укучылар тавышын иң күп җыйган әсәрне дә билгеләп үтәчәкләр.

Әңгәмәдәш – Гөлнур САФИУЛЛИНА.

Гүзәл ЯХИНА

ЗӨЛӘЙХА КҮЗЛӘРЕН АЧА

(Шул исемдәге әсәрдән өзек)

Йөкле? Әйе, бертуктаусыз ашыйсы килде – ашатмадылар ич. Әйе, соңгы араларда эче зурайды – әмма ул моны олыгаю галәмәтенә юрады. Кызыл кунаклар килүдән туктады – борчу-хәсрәтләре күплектән дип уйлады. Әмма йөкле булуы... Ай-һай, Мортаза – әҗәлне алдаган ич. Үзе әллә кайчан кабердә, ә орлыгы исән, тере – хатын корсагында үсепме-үсеп ята... Яртылаш үскән дә инде.

Кабат кыз бала? Билгеле бит инде, тагын кем булсын. Убырлы ничек диде әле? Дөньяга кызлар гына китерәсең? Юк, ул алай әйтмәде: фәкать кызлар гына китерәсең, шулар да яшәми, диде.

Әллә монысы да?.. Ничек булсын, әлбәттә, шулай. Монысы да туар-тумас көе китеп барыр. Нарасыйга хас якты чибәрлеге нәфис тиредән җуелырга, ә нәни күзләр аны күреп-танып белергә дә өлгермәс, иреннәренә елмаю кунмас.

Зөләйханың күзләре караңгы түшәмгә төбәлгән. Тәгәрмәчләр тукылдавына кушылып бары тик уй гына агыла да агыла. Юка такта стена артыннан җылы май киче җилдерә. Яртылаш бушап җиңеләеп калган киң вагон бишек кебек тирбәлә. Һәммәсе тынган – ярты төн аның кулын сыйпап утырган изге күңелле Изабелла да, сөенеп-яктырып аңа озаклап карап торган сәер профессор да йокыга талган. Аңа да онытылырга иде дә бит – оеп китеп булмый.

Алладан баласының һичьюгы аякка басуын сорарга ярыймы икән аңа? Бу дөньяны ташлап киткәнче беренче адымнарын булса да атласын иде ул. Әллә мондый үтенеч бик зур әдәпсезлек саналырмы? Киңәшергә янәшәдә берәү дә – Мортаза да, мулла-хәзрәт тә юк шул. Кодрәт иясе, Үзең белгерт, ичмасам, бу хакта сорасам ярыймы? Артыгын сорарга базмыйм. Шуны гына үтенсәм... Рөхсәтме?

Һәм шунда ук каршы фикер туа: әгәр Хак Тәгалә сине ишетеп газиз балаңа беренче адымнарын атларлык көч бирсә – шуннан соң аны югалту җиңел булыр дисеңме? Шунда ук, балага иярләшергә, җаның-тәнең белән берегергә өлгергәнче үк мондый хәлнең булуы яхшырак түгелме икән? Хәтерлә, бер айлык гомер бирелгән беренче кызыңнан аерылу сагышыннан үлә язган идең бит. Икенчесе – ике атнадан дөньяны ташлап киткән Фирүзәң өчен алай ук бетеренмәдең бугай. Җиде көн дә яшәргә өлгермәгән Халидәң өчен дә... Дүртенчесе, тугач та җаны күбәләк булып очкан Сәбидә өчен еларлык яшең калмаган иде шул...

PRESSA.RU

Шәмсия–Фирүзә, тәгәрмәчләр тукылдый. *Халидә–Сәбидә.* Һәм янәдән: *Шәмсия–Фирүзә, Халидә–Сәбидә.*

Шунда ук – шулай яхшырак түгелме? Әнисе мондый уйны гөнаһ дияр иде. Барысы да Ходай иркендә, нәрсәнең, кайчан яхшырак икәнен уйлап безгә баш ватасы түгел. Әмма башны кисеп ташлап булмый. Уйлый-уйлый, җәтмә балык белән тулгандай аңа уй тула.

Ә бәлки, беркем тумас та әле. Хатыннар кое эргәсендә сөйләшеп торган иде, нарасый анасы эчендә яши, әзрәк үсә дә, аннан... вакыты җиткәнен көтмичә урыныннан кузгалып өзелә дә төшә. Бер йомарлам канга әйләнеп.

Убырлы да янда булмагач ни булып бетәсен әйтүче юк. Алдан белеп тору әйбәтме соң? Көтү газабы гына. Әгәр белмәсәң?

Арыды, тоташ янулардан арыды ул. Ачлыктан интегү, туймас тамакны алдау, үгетләү йончытты. Ашарга яраксыз нәрсәләрдер ашап эч авырту, төнге суыклар, иртән сөякләрнең сызлавы үзәккә үтте. Бетләр, янәшәдәгеләрнең үлеме, туктаусыз калтырану, курку... Һәм иң кыены – үтмәс-бетмәс кебек тоелганы – оят.

Аңа гел оят: айлар буе юынмаган тәннән килгән ис өчен дә, көндәлек обход вакытында яланбаш хатынның чәч толымнарына солдатларның гамьсез генә күз төшерүеннән дә ояла ул. Тоткыннар белән шыгрым тулы вагон почмагында чүпрәк белән генә бөленгән бәдрәф кебек җирдә тышка чыкканда ничек ояла. Төнлә, җылынырга теләп, йоклаган профессорга аркасын терәве дә оят, оят! Кичә кич чит докторның симез бармаклары белән аның тәнен битараф капшавы ничек гарьләндерде, оятыннан җир ярылса җир тишегенә кереп китәргә әзер иде. Бөтенесенә ишеттереп, аның йөкле икәнен хәбәр иткәч үкереп елады. Ә шул оят-гарьлекне бөтенесе алдында күтәрәсе дә бар ич әле. Гомерендә беренче мәртәбә серен ире йортындагы биек койма артына яшереп асрый алмаячак. Көннән-көн үсә барган корсак эчендә тууга ук аны ташлап китәчәк нарасые яши.

И Аллам, минем үз юлым кайчанрак төгәлләнер икән соң? Син моны тылсымлы бер селтәнүдә хәл итә аласың ич. Зөләйха мендәр урынына баш астына төреп салган тунына йөзен яшерә. Маңгае каты, үткен нәрсәгәдер төртелеп дертләп китә. Кесәләрен әйләндереп караса, таш кебек каткан бер нәрсә күреп аптырап кала. Шикәр! Мортаза сыер һәм атларын алып чыгарга килсәләр малкайларның авызына каптырырга кушып әзерләгән, күсе агуы сеңдерелгән агулы сый. Зөләйха оныткан да иде, әмма ул исән икән. Ап-ак үзе, агу исе сизелми, ризык исе генә. Кайчаннан бирле чакырып йөдәткән әҗәле ничәмәничә айлар Зөләйха кесәсендә посып ятканмы? Шушы ачы мизгелдә табылсын өчен. Кайнарланып дога кылуына җавап шул булса?

Зөләйха шикәрне битенә якын ук китерә. Әзрәк тешләргәме, әллә бөтенесен берьюлы авызга кабып суырыргамы? Агу шунда ук үтерерме, әллә бераздан-мы? Озак газапланасы булырмы? Хәер, барыбер түгелмени?

– Шикәр! Кайдан? – Профессорның шатлыклы-гаҗәпләнүле күзләре янәшәдә генә. Уянган, терсәгенә таянган да Зөләйхага карап тора. Ай яктысында пеләшен камап алган көдрәләре көмешләнгән. Зөләйха дәшми, шикәрне йодрыгына кыса, үткен кырые тирегә кадала.

– Ашагыз аны, тизрәк ашагыз! – Лейбе дулкынланып пышылдый. – Беркемгә дә күрсәтмәгез, бигрәк тә Гореловка – талап алыр. – Ул бармагын иреннәрә тидерә. – Ә мин... беләсезме... – Профессор аның корсагына күз төшерә, күзен кысып, икеләнеп тора, аннан кыюланып: – Үзен ничек хис итә? – дип сорап куя.

– Кем?

– Бала, билгеле.

– Ул – кыз. Нәсел бетә. Мин кызлар гына таба алам.

– Кем әйтте моны? – Лейбе кисәк торып утыра һәм баш түбәсе чак кына түшәмгә бәрелми кала. Ул Зөләйханың эченә озаклап карап тора: башта канәгатьсез, аннан икеләнгәндәй һәм, ниһаять, сөенечтән балкып: – Ышанмагыз! – ди. Рәхәтләнеп көлә, кулын болгый. – Ышанмагыз!

Тәгәрмәчләр каты итеп шакылдый. Сүз өзелә. *Шәмсия–Фирүзә. Халидә–Сәбидә.*

– Йөрәге тибә дип уйлыйсызмы?

– Сорап торасыз тагын! – Профессор ачулы. – Ике ай инде.

Ул картларча ахылдап сәкедә борылырга тырыша. Иелеп, колагын аның корсагына якынрак китерә, эчтә яшеренгән сабыйның йөрәк тибешен ишетергә тели, әмма яңагын тидерергә кыймый.

Зөләйха учын аның агарган көдрәләренә куя һәм профессорның башын эченә таба этә. Оят чигенә. Чит ир йөзен аның тәненә тидерә, исен тоя – ә аңа оят түгел. Фәкать беләсе килә: эчтә, анда ни бар?

Лейбе озаклап, игътибар белән, күзен йомып тыңлый. Аннан башын күтәрә – карашы йомшарган, хыялый – һәм дәшми генә ымлый: барысы да яхшы.

– Шикәрне ашагыз, – дип исенә төшерә, урынына яткач. – Ашагыз, хәзер үк.

Кулын баш астына куеп, елмаюлы йөзен түшәмгә текәп – гүя йолдызларга соклана – ул йоклап та китә.

Зөләйха шикәр шакмагын толып кесәсенә салып куя. Хәзер, аның үз әҗәле – татлы, нәзакәтле исле, гадәти шикәр кисәгенә әйләнгән үлем табылган, янәшәдә генә яткан чакта күпкә тынычрак икән. Теләсә кайчан, үз теләге белән, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтеп, ул аны кабул итәргә әзер. Аның догасын Ул ишетте бит.

Состав озын, әйләнеч юллар, чуен күперләр үтеп, ай яктырткан күлләрне артта калдырып чаба да чаба. Алар озак, бик озак барачак әле. Март башында ты-

ныч кына яшәгән илләреннән куылган көчләп күченүчеләр барып урнашырга тиешле җиргә килеп җиткәнче август ахырлары якынлашыр... Ә аңарчы...

Баржа

Зөләйха авырып кыен күтәрде – эче зур, ә аяклары чуен кебек, тыңлаусыз. Эчтә сабые тынгысызлана: әле орчыктай бөтерелә, әле аяклары белән туктаусыз тибешә. Олы апасы Шәмсиягә охшаган, ахры, анысы да бер тынгысыз, уенчак бала иде. Ә бәлки, ачыккангадыр. Үзе дә бик нык ябыкты, егерме беренче елгы ачлыктагы сыман коры сөяккә калды. Бармакларга кадәр нечкәрде, хәлсезләнде. Ул сабый ничекләр түзәдер?

Ул еш кына күлмәк тукымасы шартлардай булып тартылган эченә карап тора, ә анда – эчтә чәнти бармак тырнагы кадәр генә борынын җыерган нарасый нәни авызын ачадыр, ашарга сорыйдыр кебек. Шул чакта күкрәкләренә сөт төшкәнен тоя. Аңа бит нибары җиде ай, ә сөт төшә! Сәбидәне көткәндә дә шулай булган иде.

Зөләйхага кызларын уйламаска иде дә бит. Әмма дулкыннар баржа читенә бәрелгән саен, *Шәмсия–Фирүзә–Халидә–Сәбидә* дип кабатлап торгач соң... Су өстенә канаты тияр-тимәс очкан акчарлакка кадәр Шәмсия дип ачыргаланып кычкыра, аны икенчесе эләктереп ала, өченчесе: *Фирүзә, Халидә... Сәбидә...*

Ишетмәскә тырышып колакларын томалап карады. Юк! Арыды ул. Исәп-саннары югалган көннәр, атна, айлар буе каядыр барудан туйды. Красноярда аларны көчкә сөйрәлүче шушы баржага шыплап тутырдылар. Сөер профессор Лейбе, үз булып беткән Изабелла, кырыс Константин Арнольдовичны, рәссам Илья Петровичны, хәтта сөйкемсез Гореловны – Ленинградтан чыкканнарның һәммәсен кара мыеклы кызылурдалы пристаньнан ук катерга төяп каядыр алып китте. Зөләйха аларны кабат күрмәстер, шәт. Алар үткәндә калды. Мортаза һәм Убырлы кебек күзгә генә күренгән өрәкләр сыман, узганда инде алар хәзер. Якыннарын югалтудан да арыды. Аерылышу хәвефен тоеп яшәүдән дә туйды. Баласының үлемен, үзенекен көтүдән... Чыны – яшәп арыды. Бердәнбер юаныч – күлмәк кесәсендә. Ихлас күңелле тугры дус, һәрчак ярдәм итәргә әзер әнисе сыман, шул шикәр кисәге бар. Бүтән берни кагылмый аңа, урап үтә яки читкә чәчелеп кала: югыйсә янәшәсендә – шыплап тутырган вагондагыларның күпмесе акылдан язды. Көн саен күпме кеше үлә – кемдер авырып, кемдер ачлыктан: мәрхүмнәр юл читендә ятып кала, аларны җирләргә, хәтта өсләренә туфрак сибәргә дә өлгермәгән чаклар була, эшелон алга ыргыла. Пышмага җитәрәк шул эшелоннан күпмедер кешенең кача алуын белеп, тагын шул ук ысулны сынап карарга теләүчеләр булды. Качкыннарны тиз тотып, вагон читенә тезеп аттылар.

Ә Зөләйха исән. Димәк, аның өлешенә тигәне – шул шикәр шакмагындадыр. Шуңа да түземлеге тәмам төкәнгәч, суырырга дип саклап тора. Әлбәттә, сабые туганчы, икәү берьюлы, аерылмыйча китеп барсалар яхшырак буласы иде дә...



Н. Васильева рәсеме

PRESSA.RU

Зөләйха күзләрен ача. Томан эчендә шәйләнгән ерак яр алсу нурга төрелгән. Кинәт таныш тавыш: «Әйдә!» Баржа борынында билгә кадәр ялангач Игнатов. Бер матрос аның өстенә чиләге белән елга суы коя. Игнатов яңгыратып көлә, башын чайкый, юеш чәчләреннән су тамчылары чәчри, колакларын, күкрәген уа. Елмаюы матур аның, тешләре ак. Шикәр кебек. Ә аркасында – тирән яра эзе.

...Енисей буйлап тәүлек буе бардылар, иртән Ангарага чыктылар. Көн эссе, тирләтә. Кай арада көн бозылды, яшен уты күкне урталай ярып үтә. Күк күкри. Давыл кинәт, көтмәгәндә башланды, баржаны йомычка кебек бөтерә, айкый-чайкый, дулкыннар күбекләнеп өскә сикерә.

– Төпкә китәбез! – дип акыра кемдер. Палуба янтая. Зөләйханы дулкын бөтереп ала, каядыр аска ыргыта. Авыз-борынга су тула. Күзне ачып булмый. Ул кулларын күкрәгенә кушыра. Ниндидер каты әйбергә бәрелә. Аллаһы Тәгалә синең юлыңны кисәргә карар кылган – Ангарада батып калырга язган икән.

Бисмилләәһир рахмәәнир рахиим...

Авызга су тулган, әче. Сулап булмый, тешләр шыгырдый.

Әлхәмдү лилләһии раббил... гәәләмииин...

Толымнары өскә калка, әкрен генә селкенеп тора, суүсемнәрмени... Үкчәләре йомшак ләмгә бата. Инде берни шәйләнми. Бала кисәк уяна. Аяклары белән тибә, бер, ике, өч... Куллары хәрәкәткә килә, бәргәләнә. Зөләйханың корсагы дер-дер килеп селкенә, нәни үкчә эчтә ярсып тибенә дә тибенә.

Зөләйханың аяклары дерелди. Бармаклары төпкә тиюгә бөтен көченә гәүдәсен этеп җибәрә, куллары бер кысыла, бер языла, ишә, көрәшә...

Ни гаҗәп, ул өскә калка. Өскә, өскә... Кул-аяклары белән бөтен көченә ишә, тизрәк, тизрәк! Ә өстә дулкыннар котырына. Менә ул зәңгәр күкне шәйләп ала. Әллә чыкты?! Су кайный, үкерә, бәргәләнә. Зөләйха йөзә белми. Аяклары тагын аска тарта. Яңадан төпкә китәрмени? И Алла!..

Кемнеңдер кулы чәченнән өстерәп аны өскә тарта.

– Суга ят! – таныш тавыш бик якында гына. – Корсак өстә! – Игнатов ич бу!

Зөләйха әйләнмәкче, куллары белән кемгәдер ябышмакчы була.

– Батырасың! – Игнатов читкә каерыла, әмма кулына урап тоткан толымнарны ычкындырмый. – Ят, дидем. Дура!

Ул йөткерә, көрәшә, чак ишетә. Әмма тырыша, корсагы белән өскә әйләнә, суга ята. Дулкыннар арасында чайкалган эче утрау кебек кабарып тора. Өстән койган яңгыр йөзне камчылый. Сулыш алырга гына хәл җитсен, сулыш алырга!

– Тотам сине, тотам, – тавыш якында гына. – Толымыңнан тотып торам.

Сабые тынычланды, комачауламый. Дулкыннар тынар кебек, яшен ерагая.

– Син мондамы? – Зөләйха авызына су туласын белеп башын борырга курка.

– Монда, – ди тавыш. – Синнән аерылып кая китим инде хәзер.

Агым уңаена аккан, тәмам хәлсезләнгән бу икәүне бер-ике сәгатьтән баржа белән очрашырга тиешле катер куып җитте. Исән калган Зөләйха белән Игнатовны, тагын берничә матросны палубага тартып алдылар. Өс-башларын салдырып, киптерергә куяр алдыннан Зөләйха кулын кесәсенә тыкты. Ярты уч ак кесәлдән башка анда берни калмаган иде. Кесәл бармак арасыннан шунда ук агып бетте.

Йосыф

– Берәмләп – санагыз! – дип боера Игнатов.

– Беренче! – Горелов шуны гына көтеп торган диярсең.

– Икенче, – дип эләктереп ала кемдер. – Өченче... Дүртенче...

– Сезнең белән утыз, гражданин начальник, – монысы Изабелла тавышы.

Зөләйха башын күтәргәндә Игнатов әле һаман Изабеллага карап тора иде.

Аллага шөкер, давыл узды бугай. Зөләйха учакта кайнаган тоз шулпасын болгатырга дип озын таяк ала. Шул мизгелдә эчтәге бала уяна, эчен тарткалый-йолыккалый. Кычкырыр иде, тыны кысылган, ни сулый, ни дәшә алмый. Тезләнә, җиргә чалкан ава. Күз алдында йолдызлар сикерешә. Башланды!

– Су җылытыгыз! – Игнатовның тавышы ерактан ишетелә.

– Ирләр, безне калдырсагыз икән, – Изабелла тавышы.

– Учаксыз катабыз ич. Хатыннарның бала тапканын күрмәгәнмени без!..

...«Менә, булды да! Өлгердек!» Лейбе аркылы яткан, әле генә үзе тартып чыгарган сабыйның юеш тәнен беләгенә ыграк кыса. Яңа туган бала беренче мәртәбә авызын ача, шундый каты итеп кычкырып җибәрә... Вульф Карлович Ангарага төшә, яр кырыенда канлы кулларын озаклап юа. Таш өстендә утырган Игнатов аңардан нидер сорый.

– Малай! – Озын, нечкә бармагын Лейбе югары күтәрә. – Йосыф! Уйлап кына карагыз, аю-бүредән башка беркем яшәми торган, дөнья читендәге буп-буш җирдә... Йосыф һәм Зөләйха! Шаккатырлык хәл бит бу!

– Әйтегезче, – Игнатов фуражкасын сала, – әгәр сез булмасагыз? Ул... Ул...


– «Әгәр дә ки... ни булыр иде» дип сез еш уйланасызмы?

– Юк.


– Дөрес эшлисез. Нәрсә бар, шул гына бар. Фәкать шул гына бар.

...Игнатов ярдан менгәч соры папканы табып ала. Ача, эре, кәкре хәрефләр белән – күмер белән буш почмакка: «Юзуф» дип язып куя.


Роза МУЛЛАНУРОВА тәрҗемәсе.













Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ

«Ак чәчәкләр»

Бу роман язылуга быел – 50 ел. «Ак чәчәкләр» – шул чорда яшәгән кешеләр, аларның уй-кичерешләре һәм мәхәббәтләре турында сөйли. Әсәрнең үзәгендә – күпне күргән, күпне башыннан кичергән атаклы профессор Әбүзәр Таһиров. Аның өчен халыкка намус белән хезмәт итүдән дә изгерәк бурыч юк. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр карт профессорның иң яраткан укучысы, профессор өендә үз кеше булган Гөлшәһидәнең мәхәббәт тарихы тасвирлана.

Гамил АФЗАЛ

«Үз туксаным туксан»

«Әсмабикә җаным, ахирәт», «Өф-өф итеп...», «Мыек борам», «Ир бала яхшымы, кыз баламы?»... Без аның бу шигырьләрен сәхнәләрдән бүген дә яратып тыңлыйбыз, алай гына да түгел, үзебез яттан сөйлибез! «Кызлар күңеле», «Ялкау кызлар» кебек җырларының әле дә җырчылар репертуарыннан төшкәне юк. Татар әдәбияты классигы Гамил Афзалның бу китабына тупланган тирән юмор һәм үткен сатира белән сугарылган шигырьләре, кыска хикәяләре, юморескалары укучы өчен шуңа да зур бүләк булыр, мөгаен.

Алмаз МАНСУРОВ

«Мәхәббәт әкияте»

Яшь язучының беренче китабына яшьлек һәм мәхәббәт хисләре белән өртелгән, хыял-уйны яктылыкка тоташтырырга сәләтле хикәяләре тупланган. Алмаз – шәһәрдә туып-үскән егет. Шуңа да ул тасвирлаган вакыйгалар күбесенчә шәһәр урамнарында, тукталышларда, биек-биек йортлар эчендә бара. Алай да төп герой табигатьтән аерылмаган, аның күңел түрендә ландышлар чәчәк ата. Гомумән, Алмазның һәр хикәясендә кешеләрне ярату, күңел җылылыгы, хәтта балалык самимилеге бар.

Әнәс ХӘСӘНОВ

«Бәхет кайда оя кора» «Где гнездится счастье»

Язучының бу романында яшь замандашларыбызның җәмгыятьтә тирән иҗтимагый үзгәрешләр чорында (XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы), илдә кыргый капитализм шартларында бәхеткә омтылулары, эзләнү, хаталары, югалту-табышлары аша тормышта үз урыннарын табулары тасфирлана.
Язучының хикәя геройлары – ихлас күңелдән ясратып сурәтләгән өлкән буын, гомерләрендә күпне күргән хезмәт кешеләре, тормышны сөеп яшәүче милләттәшләребез.

Касыйм ТӘХАУ

«Өч әкият»

«Кырмыска улы Кырмыскак маҗаралары», «Кондызлар илендә», «Кыштуган»... Өч кичкә – өч әкият. Беренче көнне кырмыскалар, ә икенче кичне кондызлар дөньясында яшәп алырсыз. Ә Кыштуган – су чыпчыгы. Кыштуганның әллә никадәр дусты бар: чәберчек малае, керәшәләр, шәүлегән, күке, тукран, чукыр белән суер... Һәркайсының үз мәшәкате. Кошлар дөньясында да төрле чаклар була, ачуланышып, тарткалашып та китәләр. Ярый араларны җайларга шунда ук Кыштуган килеп җитә...

К. С. ФӘТХУЛЛОВА, Ә. Ш. ЮСУПОВА, Э. Н. ДЕНМӨХӘММӘТОВА

«Татарча сөйләшик. Давайте говорить по-татарски. Lets speak tatar»

Татар теле белән кызыксынучылар өчен тәкъдим ителгән әлеге уку әсбабы үз эченә 13 бүлекне – әзерлек курсын һәм көндәлек тормыш белән бәйле аралашу темаларын ала.
Аны укытучы җитәкчелегендә татар телен өйрәнү өчен дә, мөстәкыйль рәвештә сөйләм күнекмәләрен камилләштерү өчен дә кулланырга мөмкин.

ТӘЭСИР.



Ландыш ХӨСӘЕНОВА, «Татарстан– Яңа гасыр» каналының алып баручысы:



Романның герое – автор үзе. Көн яктысын ул беренче тапкыр 3 яшендә генә күрә. Уйнаштан туган баланы әбисе белән әнисе беркая чыгармыйча, кешедән яшереп, 3 яшенә кадәр караңгы чоланда бикләп тота. Бала үз көнен үзе күрә: караңгы почмактагы кисмәктән он табып, аны су белән бутап ашый. Беренче уенчыгы – бака, соңрак соры тычкан була. Авазлар белән генә аралашырга күнеккән малай бары 9 яшьтә җиткәч сөйләшергә өйрәнә.
Әмма кеше нинди генә шартларда яшәсә дә, Ходай Тәгалә биргән сәләт ачылмый калмый – әсәрдә шул фикер ачык чагыла. Килмешәк урамга чыгу белән кулына таш кисәге алып җиргә сызгалый башлый, нидер ясарга омтыла. Тора-бара үзе күзаллаганча Галәмне, йолдызларны, Кояшны ясый. Куллары гел иҗади эзләнү, яңалык таләп итә: кәгазь-каләмсез тора алмый. Шушы эзләнүләр аны сәнгать училищесына алып килә... Кырыс шартларда үскән малайның сынау баскычларын үтеп белем алуы, үзалдына куйган максатларына ирешеп, җәмгыятьтә үз урынын табуы зур хөрмәт уята. Әсәрнең герое – авторы Кадим абый Җәмит – әбисе белән әнисенә үпкәләми, ачу сакламый: минем монысы тагын да зуррак ихтирамга лаек, минемчә. Танылган сынлы сәнгать остасының күңел матурлыгы иҗатында чагыла.

PRESSA.RU


Ризидә ГАСЫЙМОВА

мәчеттә

МӘЧЕТТӘ

(нәсер)

Мәчет капкасыннан ир-ат белән хатын-кыз килеп керделәр. Ир-ат озын буйлы, асаба матур гәүдәле. Хатын-кыз, киресенчә, кеп-кечкенә, юп-юка иде. Өстенә караңгы зәңгәр төстә плащ кигән, башына, плащына иш итеп, зәңгәр төстәге яулык бәйләгән. Тәрәзәдән урамга карап торган хәзрәт аларның атлап килешенә игътибар итте. Шул кечкенә хатын: «Без бик дөрес киләбез», дигәндәй, ышанычлы адымнар белән алдан атлый, ә зур гәүдәле ир икеле-микелерәк кыяфәттә аңа ияргән иде. Хатын-кызда тәвәккәллек зуррак шул...

Алар мәчет ишегенә килеп җиткәч, туктап, бер-беренә карашып алдылар да, ипләп кенә эчкә үттеләр. Хатын мөселманча сәлам бирде. Аннары кыю атлап (кыю гына түгел, күзгә бәрелерлек матур да икән әле ул!), хәзрәт каршына килде:

– Хәзрәт, без хәер бирергә дип кергән идек.

– Бик рәхмәт, узыгыз, утырыгыз.

Тик хатын утырырга ашыкмады, ишек төбендә таптанып торган иргә борылып, сабый бала белән сөйләшкәндәй, әниләрчә кайгыртучанлык белән эндәште:

– Әйдә инде, кил!

Аннары үзе, сезгә комачауламыйм, рәхәтләнеп сөйләшегез, дигәндәй, гел читкә үк барып утырды.

Хәзер инде хәзрәт ир-атка күз салды. Хатын кебек «чатнап» тормаса да, күркәм генә кеше иде бу. Күренеп тора, үз тормышын үзе алып баручы. Әмма карашында ниндидер таркаулык сизелә. Урысларда «потерянный взгляд» дигән сүз бар бит. Татарчасы «аптыраган кеше карашы» була микән соң аның?

– Тыңлыйм сезне.

– Хатыным төшкә керә, – диде ир, – бу арада көн саен. Үлгәненә ике ел булды.

– Рухына дога кылыйк алайса.
Ир ризалык белдереп баш какты.
Доганы гадәтенчә бик җиренә җиткереп кылды хәзрәт. Бу ир-ат аңардан, һичшиксез, канәгать булып китәргә тиеш иде. Әмма аның яхшы итеп багышлауларын ишеттеме ул, юкмы, һаман күңеле тынычланып бетмәгәндәй утыра бирде.
– Хатыныгызның үлемен бик авыр кичердегезме? – диде хәзрәт, сүзсез калуны килештермичә.
– Ул авариядә үлде. Ә мин... рульдә идем.
– Аңладым инде. Тик үзегезне гаепләргә кирәкмәс. Язмышына шулай язылган булган аның.
Ир-атның йөзендә, кем әйтмешли, «бер бөртек кылы да селкенмәде». Моның ише юату сүзләрен ул, күрәсең, күп тапкырлар ишеткән булгандыр.
– Үлгән артыннан үлеп булмый. Өйләнеп яшәү кирәк, – дип дәвам итте сүзен хәзрәт. Бу фикер белән ир-атларның, гадәттә, барысы да килешә – әмма яңа танышына монысы да ошап җитмәде бугай. Инде сез дә шул турыдамы, дигәндәй, ризасызлык белән урыныннан кузгалды.
Бу вакытта хатын-кыз да торып баскан иде.
– Син чыга тор, – дип эндәште ул, ишек катында тукталган ир-атка. Ә үзе аның урынына – хәзрәт каршына килеп утырды да, ир артыннан ишек ябылганын көтеп, беркавым эндәшми торды. Аннары хәзрәткә борылды:
– Ул бит мине ярата, – диде хатын, мине сүзенә басым ясап.
Күпне күргән, күпне ишеткән хәзрәт өчен дә көтелмәгәнрәк сүзләр булды бугай бу – аның йөзендә гаҗәпсенү чагылды.
– Ә мин кияүдә, – дип дәвам итте хатын. Моны әйткәндә читенсенеп киткән кебек булды, әмма карашын хәзрәттән алмады.
Хәзрәт исә һаман берни эндәшмәде.
– Нишләтим соң, яраткач? – диде хатын, аның белән бәхәсләшкәндәй. – Нигә сез бер сүз әйтмисез?
Хәзрәт җавап итеп көлемсерәде. Тик көлемсерәве җылы, мөлаем килеп чыкты. Игътибар белән караган кечкенә соры күзләрендә борчылу катыш аңларга, хәлгә керергә тырышу чагылып китте.
– Ни дип әйтим соң? – диде ул. – Сез бит мин әйтергә тиешле бөтен сүзләрне үзегез дә бик яхшы беләсез.
– Беләм...
– Шулай булгач?
Хатын беркавым эндәшми торды.
– Бик яшь идек шул әле без ул вакытта, – дип сөйләп китте ул кинәт. – Без бергә эшләдек. Ничектер якынаеп киттек инде. Үзем дә белмим. Минем ирдән дә, гаилә тормышыннан да җан суынган вакыт иде ул. Тик бер башлагач... аерылышу бик кыен була икән. Аның хатынының да, минем ирнең дә сизенгән, шикләнгән чаклары булды, ләкин... безнең мөнәсәбәтләр беркайчан да бетеп җитмәде.
– Нигә аерылып, никах укытып яшәү турында уйламадыгыз соң? – дип кызыксынды хәзрәт.
– Белмим, – диде хатын, – күрәсең, кыюлык җитмәгәндер. Аннары – балалар бар бит. Аныкылар да икәү, минекеләр дә. Ә ул гел әйтә иде: «Без барыбер бергә булырбыз кебек, мин нәрсәдер көтәм әле», – ди иде. Мин дә шулай – нәрсәдер көтеп яшәдем инде... Ләкин юк, юк, хатынына үлем теләмәдем мин аның! Бу хәбәрне ишеткәч тә... ниләр кичергәнемне үзем генә беләм. Ул үзе дә авыр хәлдә иде бит. Табиблар исән калмас, дигәннәр иде. Шундый чакта кешене ничек ташлап китәсең? Хәзер ул әнә минем бөтенләй күчеп килгәнне көтеп яши. Ә мин... гомер иткән иремне ташлап китә алмыйм. Бәлки, сез миңа бирәр киңәш бирерсез?
Нигә дип хәзрәткә шундый сорау бирде икән ул? Никахлы ире була торып, башка бер ир белән очрашып йөргән хатынга хәзрәтнең ни дип әйтәсе билгеле иде бит! Ләкин бу дөньяда гаҗәеп хәлләр дә була икән. Хәзрәт җитдиләнде, әмма күтәрелеп бәрелмәде:
– Миңа андый сораулар бирмәгез әле сез, – диде ул, тыныч кына. – Мин дә бит сезнең кебек үк адәм баласы. Сез Аллаһ Тәгаләдән сорагыз. Догалар беләсезме?
– Беләм...
Хатын урамга чыккач, кай таба китәргә белмәгәндәй, беркавым аптырап басып торды. Аның фикере таралган иде.
...Ә бит чыннан да догалар белә иде хатын. Ничек белмәсен – әбисе гомер буе дин тотты. Балачакның иң истә калган, иң матур күренеше шул – олы якның түрендә ап-ак намазлык өстендә ак яулыгын озынча итеп бәйләгән әбисе сәҗдә кылып утыра. Әбисе өйрәткәннәр һаман тел очында.
...Ир, машинасына сөялеп, аны көтеп тора иде.
– Бик озак, – дип каршы алды ул аны. – Ә мин чыгып киттем тизрәк. Өйләнү турында сүз башлауга...
– Син догалар беләсеңме? – дип бүлдерде хатын ирне.
– Юк.
– Мин сиңа иртәгә язып алып килермен, яме.
– Хәзер миңа кайтмыйбызмыни?
– Юк, минем бу тирәдә эшләрем бар әле.
Эшләрем бар, дисә дә, хатын парк эченнән җәяүләп кенә туп-туры тукталышка таба китте. Үзен нишләптер бәйсез-иркле-рәхәт хис итеп атлады да атлады ул. Үзе авыз эченнән бертуктаусыз дога укыды:
– Кульһүүәллаһү әхәде. Әллаһү самәде. Ләм йәлиде. Үә ләм йүүләде. Үә ләм йә күлләһү күфүүән әхәде...
Бу илаһи яңгырашлы сүзләрне кабатлаган саен, күңеленә тынычлык иңә баруын тойды. Тынычлык һәм... ниндидер рухи ялгызлык. Хәер, нишләп ялгыз булсын, ди, ул? «И, Ходаем, – дип эндәште хатын, ап-аяз күк йөзе аша бик еракка төбәлеп. – Бу азаптан коткарсаң иде син мине. Калган гомеремне тыныч кына яшәп бетерә алсам иде. Амин...»

PRESSA.RU



Равилә ШӘЙДУЛЛИНА

Равилә ШӘЙДУЛЛИНА – шигърияттә яңа исем. Аның нәниләр өчен берничә шигырь китабы бар. Бүген исә сезгә аның хатын-кыз күңелен ачкан, хыял, хис, кичерешләргә төрелгән бер шәлкем шигырьләрен тәкъдим итәбез.

ХЫЯЛ КЫЗЫ

Сурәт

Киемнәрең затлы синең,
Бармак саен алтын йөзек...
Тик йөрәгең генә тузган,
Тузган йөрәк күпкә түзеп!

Бармагыңда алтын йөзек –
Күз тимәскә бер алдау ул.
Белмәсеннәр ят карашлар
Йөрәгеңнең мең ямавын.

Нахак сүзләр, агу сүзләр –
Елан телнең бер ялмавы.
Түзә белгән йөрәкләргә
Елан чагу бер дәва ул!

Хыял кызы

Хыялый мин – күккә ашып үстем.
Урак Айны таган итеп кайчак,
Тирбәлдем мин күктә – биектә.
Болытларны кочты минем кочак.

Йолдызларны калфак итеп кидем,
Җилкән болытларны киердем.
Йолдызларга кадәр җитәм диеп,
Сабый хыялымда тилердем.

Җил кызыдай болытларны кочтым,
Болыт тауларыннан боландай
Җиңел чаналарда мин очтым.
Ак болытлар белде. Күрде Ай.

Ак болытта калды Балачагым!
Сезнең арагызга мин төштем.
Хыялый кыз һаман Күктә йөри,
Җирдә яшим – гади бер кеше.

Халәт

Юк, коенмыйм бүген таң нурында,
Таң-иртәдән җаным яралы.
Аяк асларымда аунап ята
Сынган канат каләм-каурые.

Әрәм үткән мизгел-көннәрдән
Ел-гомерләр җыйнап мескенем –
Тәмам арды инде карт Күке.
Гасыр кебек үтә һәр көнем.

Арыган җанны җилләр җилгәрә,
Каеннар да, әнә, кайгыда.
Җир кызының узгын газабына
Битарафтыр фәкать Ай гына.

Бу халәтем, бәлки, узгындыр да,
Сызлана шул җаным, сызлана.
Балачагым, әнә, кубыз уйный
Хәтеремнең каен тузында.

Иң зур гөнаһ

Иң зур гөнаһ кайсы гамәл –
Гайбәтме ул, ялганмы?
Әллә сүз йөртеп бозумы
Ике кеше арасын?
Андый кеше белә микән
Ут-тәмугка барасын?

Уллы яки кызлы берәү!
Сөйләмә ят баласын.
Мәкер кушкан сүзләр белән
Бозма туган арасын.
Бакыйлыкта ялачылар –
Утлы таба ялаучылар.

Үзгәрү

Инкыйлабны кичкән халык бер чак
Байрак читләп чикте хыялын.
Шул байракның шигарьләре бизи
Әбиләрнең ыштан балагын.

Яңа буын Җиргә килгән саен
Эзли тагын яңа мажара.
Яңа байракларга чигәр өчен
Яңа шигарь эзләп нужара.

Эзлисе юк – әнә киштәләрдә
Сүрәләре изге Коръән бар!

Алга таба юлны акыллылар
Китап сүзе белән яралар.

Җаным өши

Өши җаным, өши җаным,
Учакның уты сүнгән.
Ялкыны сүнгән мәхәббәт
Җылытмый җанны бүтән.

Сөйләшергә уртак сүз юк,
Күзләр ике тарафта.
Икебезгә уртак түшәк
Ятим таралып ята.

Бер өшегән җанны, бәгырь,
Җылыту кыен, диләр.
Үзем әле синең белән,
Ә җаным иләс җилдер.

Адашып йөри кайдадыр –
Җылылык эзләп киткән.
Син дәш әле аңа, бәгырь,
Әйләнеп кайтмас микән?

Туңган җанны эретергә
Бер җылы сүзең җитәр.
Иркә сүздән күңел гөлем,
Бәлки, терелеп китәр.

Кем урлаган?

Бер энәсен тартып алдым
Ай нурының.
Бер сапламын өзеп алдым –
Тоҗымнарның.
Яулык чиктем сөйгәнемә
Көмеш нурдан.
Югалды шул кулъяулыгым.
Кем урлаган?

Чәчүргечем төшеп калды
Толымнардан.
Шуны эзләп йөрим бүген
Болыннардан.
Кулъяулыгым, ефәк тасмам
Кем урлаган?

Гомер узмас кебек иде
Су юлыдай.
Диңгезләргә агар диеп
Уйланылган.
Бу гомерләр кар сулары
Булган икән,
Аккан эзен яңа язлар
Җуйган икән.

Кулъяулыгым, ефәк тасмам
Тапмам инде...
Дәрьяларга гомеркәйләр
Аккан инде.

***

Ишеткәнең бармы синең
Йолдызлар серләшкәнен,
Җемелдәшеп, бер-берсенә:
«Сөям», – диеп дәшкәнен?

Күрдеңме йолдыз яңгырын
Болытсыз айлы төндә?
Зөһрә кыз белән бергәләп
Айның төшкәнен күлгә?

Зөһрә кызны Йолдызлардан
Ай көнләде – белдеңме?
Ай кебек сине яратсам,
Йолдыз булыр идеңме?

Күктән эзләмим бәхетне,
Син – Җирдәге йолдызым!
Ай да бит өзлеп сөйгәнгә
Урлап киткән Җир кызын.

* * *

Әйтмә миңа авыр сүзләр.
«Рәнҗетим моны», – димә.
Минем күңел күбәләгем
Бер кырын сүздән үлә.

Мин – күбәләк, син чәчәк бул!
Шайтан таягы нигә?
Чәнечкеләрең кадалса
Иреннәрем тиюгә,
Түзәр, түзәр, түзәрмен дә
Очып китәрмен җилдә.

Ә хәзергә инәле син.
Белеп торам: инәлерсең!
Бәлки әле үтенерсең,
Үкенгәндәй итенерсең...
Ни файда соң үкенүдән,
Күбәләкне үтерүдән?

Иремә

Дертләндереп күкләр күкрәгәндә
Җан тынычы табам күкрәгеңдә.
Караңгылык каплап алса барын,
Белеп торам ныклы кыям барын.

Янәшәмдә генә, бәгырь, син бар.
Янәшәмдә генә минем сагым.
Кочагыңда – миңа җылы урын;
Назлан гына шунда, сылан, сарыл!

Шул бәхетнең кадрен белмим кайчак,
Татлы телем гүя үткен пычак.
Үпкәләшкән минутларым әрәм,
Хәләлеңә кинә тотма, бәгърем!

Кем санаган әрәм төннәр санын?
Шул төннәрне җәлләп
сыкрый җаным.
«Кичер!» дия белмәс горурлыңны,
Бүген сорыйм синнән: кичер, җаным.

* * *

Кайтып барам машинада.
Бер кыз бала!
Тузанлы юл... Яланаяк
Кызкай бара.

Күрә мине: кызыга ул.
Кызыкмасын!
Ул бит минем балачагым,
Юлы озын.

Туктыйм. Мин дә – яланаяк!
Йә, кызыкмы?
Мин дә бастым синең янга.
Әй кызыкай!

Нинди хозур басып тору
Бу туфракта.
Кызыкма син, юлым илтә
Тик офыкка!

Ә синеке озын әле...
Әй кызыкай,
Синең садә яшьлегеңә
Кызыгамын!

Гомер көзе

Көз. Салкын. Яңгырлы.
Эзлим мин югалган җылыны,
Кыш өчен җылытыйм җанымны.

Көз. Салкын. Чәчәкләр.
Иелеп чәчәкләр таҗына,
Дәшәм мин чәчәкнең җанына.

Көз. Салкын. Кырпак кар.
Чәчәкнең таҗына кунган кар.
Миндә дә чәчәкләр зары бар.

Көз. Салкын. Ак томан.
Кышларга кергәндә кемдә дә
Куерган сагышлар бар сыман.

Чәчәкләр. Елыйлар!
Көзләрнең яңгыры күзләрдә.
Көзләрдән юату эзләмә!

Яшьлекне эзләү

Чәчкәләрем көзләр булып елый.
Юатырга янда ишем юк.
Кочаклашып уза япь-яшь парлар,
Аларның шул миндә эше юк.

Бәхетлеләр уза янәшәмнән.
Ел фасылы тими парлыга...
«Бу бит безнең сукмак!» – диеп,
Эчтән генә дәшәм аларга.

Әй бу сукмак! Мәхәббәтне саклап,
Басып торам монда ялгызым.
Таныш шәүлә күрми китеп бара...
Хыялында калган хур кызын.

Куеныма алдым, җылытырмын –
Ялгыз күшекмәсен хыялым.
Кара төнне икәү кичәрбез без,
Төн артында көтә уяну.

Ә әлегә – җанда кайтавазмы,
Китеп барган кошлар өнеме?
Алар көнгә, ә мин төнгә керәм –
Ялгызлыкның тәүге төненә...

PRESSA.RU

Күңелемдә ике яз

Бу көннәрне якты дию генә,
Алтын дию генә аз мәллә?!
Нәрсә булды күзгә?
Нәрсә булды безгә?
Тирә-юньдә яшел яз мәллә?

Бу күңелдә нинди шатлык хисе,
Каян килә җылы май нуры?!
Нәрсә булды безгә?
Нәрсә булды күзгә?
Җанга ява ләйсән яңгыры...

Бу гөлләр, күр,
сонгы гөлләрмени?
Күпме матур төсләр, күпме наз!
Нәрсә булды безгә?
Нәрсә булды күзгә?
Килде җиргә быел ике яз!

Рәдиф ГАТАШ

АЛТЫН КӨЗДӘ КИЛГӘН ЯЗ ТУРЫНДА

Гомер буена җырларга гашыйкмын. Халык җырларына: озын, бормалы, гаҗәеп бер могҗизадай татар, башкорт көйләренә мөкиббән булып яшим. Аларны башкаручы кабатланмас моң ияләре Фәридә Кудашева, Рәшит Ваһапов, Мөгафүр Хисмәтуллин, Илһам Шакировларга рәхмәтлемен: нинди бай милли дөнья, илаһи рухи кичерешләр белән бәхетле иткән алар безнең чордашларны, дим. Шагыйрьләрдәге халыкчанлык та, һичшиксез, шул җырлар, җырчылар тәрбиясе бит. Тукайдан башлап бу шулай. Аның заманында ук шагыйрь сүзләренә язылган җырлар туган. Бүген дә композиторларыбыз чордашларыбызның шигыренә көй язып, нәтиҗәдә, бик матур җырлар туа тора. Без бу хәлләрнең шаһиты. Яшермим: халык үзенеке кебек үк яратып, дәррәү кабул иткән җырлары булган бәхетле шагыйрьләргә гел көнләшеп карыйм. Ә үземнең аз санлы, әмма җаныма бик газиз, кадерле җырларым – ягъни аһәңсазларыбыз көен язып, «канат куйган», үз вакытында шактый яңгыраш тапкан җырлар булып киткән шигырьләрем гел дә яз белән бәйле икән ләбаса! Әйе, әйе, «Язгы ташу», «Язлар белән бер ташыйлар сулар» һәм, әлбәттә инде, «Күңелемдә ике яз»... Хәтта шул ук чордан «Аңлашу» (көйләрен Вәсим Әхмәтшин, Риф Гатауллиннар язган) җыры да хисләрне әнә шул яз белән бәйли икән бит:

Сөйләшик – җилләрнең
Ак хәбәр йөрткәнен,
Мәхәббәт илендә
Безнең яз икәнен, – ди

«аңлашучы» җан, галәми мәхәббәт турында хыял белән. Әй, беркатлы, саф хисләр!

Әмма бу шигыремнең һәм башка шундый ихлас эндәшләрнең башы – нәкъ менә «Күңелемдә ике яз» җыры булды. Узган гасырның мәгълүм бер елының истәлекле, якты, алтын бер көзе тудырды аның шигырен, һәм аны язарга илһам биргән гади җир кызы, Такташча әйтсәк, «буй кыз» карашы... Хәер, карашы гына түгел, ә хаты, хатындагы безнең, очрашкач, шигъри халәтне тасвирлау сүзләре: «Нәрсә булды көзгә? Нәрсә булды безгә?» Шул сүзләрнең кагылуын гына көткән гүя: күңел кыллары җырлый, көйли башлаган икән... Нәкъ шул көннәрдә:

Шигърияттә күпме илаһият,
Шагыйрь яры булса – шагыйрә,

дип инанган чаклар бу! Әле ул чакта, чынлап та, шагыйрәләр санаулы гына иде, күңел аларның килүен көтә, яшьлек ашкынуларын аңлатыр өчен шигырьдә дә гүзәл заттан тугры дус, яр, суфи шагыйрьләр эзләгән «шәмс» (кояш) сурәте тансык иде шул. Шигырь башта шундый сүзләр белән тәмамлана иде:

Мәңге шул халәттә калыр идем,
Дөнья агышына яраса:
«Нәрсә булды көзгә?
Нәрсә булды безгә?» –
Дөнья тоташ яна лабаса.
Иске дөнья – яңа лабаса!

Шундый рефрен-кабатланулар белән бара иде ул (җыр язылыр дип әле уйлаган да юк!). Кырык шигырьдән торган ул циклны Сибгат ага Хәкимгә укыгач, ул минем «лабаса»ларны яратмады. «Туфанда бар ул, үз урынында», – диде. Артык интим, шәхси шәлкем дип бәяләде. Аңа ышанып, китапта бер өлешен генә чыгардым. Ул арада композитор Фасил Әхмәтов безнең буын шагыйрьләр белән якынаеп китте. Равил Фәйзуллин шигыренә «Аккошлар», Рөстәм Мингалим сүзләренә «Иделкәй» кебек көй-җырлары халык арасында танылды. Ренат Харис, Гәрәй Рәхимнәрнең дә («Бер күрешү – бер шифа», «Онытмның бугай») беренче җырлары яңгырый башлады. Аннан – Разил, Зөлфәт, Роберт, Марсель, Фәннурларның тәүге уңышлары... Шигъри илһамлы җитмешенче еллар бу! Мин дә, ниһаять, әлеге көз китергән язны күңелдә кабат яңартып, «Күңелемдә ике яз»ның бүгенге текстын яздым: инде өр-яңа ритмлы шигырь килеп чыкты. Фасил дустыбыз аңа көй язгач, җыр булып тиз арада таралды да...

Әүвәл аны, башлап, Вафирә Гыйззәтуллина җырлады... Аның инде үсеп килгән, бик «сөйкемле сөяк» чагы иде. «Нәкъ менә шушы җыр белән күзаллана Вафирәбез», – дип, Мөхәммәт Мәһдиев язып та чыкты. Сибгат Хәким дә яратып кабул итте. Радио да... Соңрак милли көрәшче булып та танылачак Вафирә җырны Казан сәхнәләрендә дә, Чабаксар, Нукус, Уфаларда узган татар мәдәнияте көннәрендә зур кичә-концертларда да яңгыратты (мәрхүмәнең рухы шат булсын, мәңгелек истәлеген калдырып китте ул җыры белән!). Аннары «Күңелемдә ике яз»ны Зилә Сөнгатуллина, Рәхилә Мифтаховалар җырлады, радиофондта да бар язмалары... Рәниф Шәриповның апасы Люция ханымның да җырны башкаруы үзенчәлекле. Кыскасы, «Нәрсә булды безгә?» дип башланган алтын көз китергән яз исереклеге моңга әверелде – ике күңел очрашуы турында гына җыр булып калмады, күпләр өчен бер матур истәлек булды, ахрысы... Һәм, әйткәнемчә, башка җырларымның да башы булды инде: Марс Макаров, Сара апа Садыйкова, Резеда Ахиярова, янә Вәсим Әхмәтшин көйләренә кереп яткан сүзләр булып дәвам итте. Җырларның да үз язмышы!

...Бу җыр сүзләре язылганга да илле елга якын вакыт үткән икән. Әмма яшьлек хисләре онытылмый: гел яшь кебек! Шулай булмаса, җырга әйләнеп, күңелләргә күчеп яши аламыни хисләр хатирәсе? Ул – күпләрнең язмышында, күңел дөньясында кабатланган бер моң кыйссасы, бәлки? Яшьлек сүзе ул!

Кем белә, бу язмамны укыса, җыр язылуның сәбәпчесе, илһамчысы да, күп еллардан соң шул тарихны күзаллап, җырны (һәм үзенең сүзләрен!) искә төшереп, көен дә көйләп куяр әле. Шагыйрьләр йөрәгендә уртак гамь-хисләрне кузгаткан андый җырларның кадерен, әлбәттә, гүзәл затлар ныграк аңлыйдыр ул. Мөгаен, шулайдыр...

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды



Мәдинә
АВЗАЛОВА

«МИН СИНЕ КИЧЕРДЕМ...»

БУ ДӨНЬЯГА БЕЗ ЕЛАП ТУАБЫЗ. КЕМНӘРНЕДЕР УЛ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ ГОМЕР БУЕ ЭЗӘРЛЕКЛИ. ТОРМЫШ ГАЗАПЛАРЫ БЕРТУКТАМЫЙ АРТТАН КУА КИЛӘ.

Баашта коеп яңгыр яуды. Күк йөзен каплап алган ул кара шыксыз болытларның очы-кырые күренмәде. Көн бер дә йөзен күрсәтмәс, аязмас шикелле тоелган иде. Менә бит, Ходайның рәхмәте, болытлар кай арада гына таралашып юкка чыкты да ялтырап кояш күренде. Ул да түгел, күк йөзенә салават күпере сирпелде.

Шәһәр уртасындагы тугыз катлы йортта урнашкан фатирны тиз эзләп таптым. «Йөрешкәнебез юк», – дисә дә, адресны ул бик төгәл белә булып чыкты. Килер алдыннан телефон аша аралашкангамы, фатир хуҗабикәсе миңа бер дә гаҗәпләнмәде.

– Юешләнденме бик? – дип каршы алды ул мине. Аннан ни өчендер: «Яңгырдан соң кояш чыкса, җан рәхәте инде...» – дип куйды.

Мин аның бу сүзләренә әллә ни игътибар итмәдем. Нindider мәгънә салып әйткәндер дип тә уйламадым.

– Хат китердем менә сезгә, – дидем, зур конвертны әйләндерә-әйләндерә. – Кулыгызга тапшырырга сүз бирдем.

– Почта белән дә килә бит ул, алай ярамады микәнни?

Мин, белмим шул дигәндәй, җилкәмне җыердым.

Хатның кемнән икәнлеген күргәч, куырылып куйгандай булды, йөзендә каушау-югалып калу галәмәте чагылып китте. Ул нык дулкынлана иде. Ике арада арадашчы булып, нindider ялгышлык җибәрүемне күңелем белән тоеп алсам да, сер бирмәдем: «Сөенечле хатка охшамаган, ахрысы, кәефегезне җибәрдем», – дидем. Ул ишетмәде, мине бусага төбендә калдырып бүлмәсенә кереп китте. Биш-ун минут таптанып торганнан соң, барлыгымны искәртеп, тамак кырып куйдым. «Әйдә, нәрсә торасың анда, эчкәре үт, – диде хуҗабикә теләр-теләмәс кенә. – Килгәнсең икән, сөйләшик».

Мин аның каршысына килеп утырдым. Өстәлдәге ачылмаган конвертны күргәч йөрәгем жу-у итеп куйды. «Ачып та карамагансыз, кызык түгелме?» «Беләм мин аның ни язганын, беләм...» – диде ул авыр сулап. Һәм шундук хат җибәргән кешене минем каян белүем, ничек танышуым, ниләр сөйләшүебез хакында төпченеп сораштыра башлады. Ниһаять «сорау алу» тәмам сыман иде. Инде чират миңа җитте.

– Үзегез генәме? – дим, як-ягыма күз ташлап. – Үзегез генә яшисезме?

– Үзем генә калдым шул, үзем генә... – «Әби»гә иртәрәк, ханым дисәң, чәчләренә чал кунып, шактый ук бетерешкән танышыма ничек дип дәшәргә дә белмичә уңайсызланып торуымны сизенде бугай.

– Менә шулай илле яшемдә япа-ялгыз калырмын дип кем уйлаган? Ул тирән көрсенеп куйды. Узгандагы гамәлләреңне белер өчен аның бүгенгесенә күз төшер, чөнки ул синең үткәнең нәтиҗәсе, дип тикмәгә әйтмиләр. Башкача без аны карма дип атыйбыз. Белә идеме ул моны, белмичә әйттеме? Тик ул аны йөрәк өзгеч шундый бер тетрәнү, күңелне айкап алырдай ачы бер җан авазы белән әйтте ки, сискәнеп киттем. Бер мәлгә ялгызлык кереп оялаган өй эче янә тып-тын калды. Ташкын булып, ургылып агылырга торган хисләрен көч-хәл белән генә йөгәнләп-тотып торуын күргәнгәме, мин аннан: «Ничек алай булды?» – дип сорамадым. Тәмам ачылып киткәнче, ул элгәре: «Кешене нахакка рәнҗеткәнең булдымы?» – дип аптыраашта калдырды. Көтелмәгән бу сораудан югалып калдым. Башымнан яшен тизлеге белән тормышымда булган төрле хәлләр йөгереп үтте. «Беркем дә андый хәлнең булганы юк дип әйтә алмый, – дим, – үзе сизмәстән дә шуны эшләргә мөмкин бит кеше моны».

Чыннан да, нигә, ни өчен гел бер кешегә төшә икән ул газаплар? Нинди хата җибәргән, кай җирдә ялгышкан ул? Туганнан бирле бер рәхәт күргәне юк бит аның?!

– «Үзең дә сизмәстән», дисең алайса... – Ул тагын уйлана калды. – Юк, – диде ул аннары, – минем «сизмәстән» булмады. Белдем аның гаепле түгеллеген, шуны белгән килеш тә рәнҗеттем. Ул миңа шул чагында: «Гомерең утлы кисәү булсын», – диде. Менә шул утлы кисәүдә инде мин – ни исән, ни тере... Иремнән бик көнләшә идем, – дип дәвам итә хатын. – Бик чибәр иде ул. Бирсә дә бирә бит Ходай ир кешегә шундый матурлыкны! Буе-сыны да сөбханалла гына. Йә Раббым, ничекләр яшәп бетерергә бу бәндәң белән дип уйлаган чакларым да аз булмады. Яшәп бетереп булмады. Аерылыштык.

Уйламыйча әйтелгән сүзнең зур тавыш-гауга китереп чыгарасын, әйтеп бетергесез хәсрәт-борчулар алып киләсен күз алдына да китереп карамагандыр ул. Аны өнендә дә, төшендә дә бер генә минутка да калдырмаган ул каһәр көн тора-бара мәхшәргә әйләнә. Ике тату гаилә, якын дуслар булып йөрешкән вакытлар аңа хәзер әкияти бер могҗиза булып тоела.

– Гел бергә идек, кая барсак та ике гаилә бергә... – дип эчтән сыза ханым. – Шулай бервакыт туган көнемне җыйнаулашып урманда – табигать кочагында уздырырга булдык. Барып җиттек тә, учак дөрләтеп җибәрдек. Балалар шундук шау-гөр килешеп, кайсы кая таралашып бетте. Ә без дүртәүләп учакта ит кыздырырга керештек. Бераздан ирем, су алып киләм дип, елгага төшеп китте. Юктан да кызык табып көлешкән булабыз, бер-беребезгә анекдотлар сөйлибез... Күпме вакыт узгандыр, әйтә ал-

PRESSA.RU

мыйм, Алсуыбыз да юкка чыкты. «Хатын кая?» – дип ире дә як-ягына карана башлады. Бер-берсен куышып йөргән балалардан сорыйбыз, алар да белми. Минем күңелгә шундук шик керде. Икәү югалды бит болар, җүнле хәл түгел, дим. Анда чабам, монда чабам, таба гына алмыйм бит тегеләрне. Елга буена да төштем, урман буйлап сузылып киткән сукмак буенча да йөгереп килдем. Юк кына. Мин аңгыраер дәрәҗәгә җитеп йөргән арада алар, учак янына кайтып, гөр килеп шашлык ашап утыра. Килдем дә, Алсуның каршына барып бастым: «Җир бит, өстерәлчек», – дип, дөньяда калмаган сүзләрне калдырмый кычкырырга тотындым. Балалар бар дип тә тормыйм, ярсыганнан-ярсый барам. Әйтерсең, мин аларны өсләрендә тоткан. Шулай кыланам. Аңлыйм да шикелле үзем: үпкән-кочканны да күрмәдем, ләкин тезгеннән ычкынган идем инде. Әйткәннәремнән Алсу телсез калды. Ире исә, берни әйтми, җыенды да өйләренә кайтып китте. Ирем мине бик озак тынычландыра алмады. Бер мизгелдә бөтенесен дә юкка чыгаруымны, дус хатынымның гына түгел, үземнең дә матур гына башланган тормышымны чәлпәрәмә китерүемне мин шунда аңладым.

Ул үзенең шундый хәлләргә юлыгуын, бәхетсезлеген, бу дөньяда япа-ялгыз калуын бары үзеннән күрә.

Алсуны ире шул кичне бик каты кыйнаган дип сөйләделәр. Ул шуннан соң сәламәтлеккә туя алмады. Гарип калды. Шул сәбәпле эшеннән китәргә мәҗбүр булды. Ирем ул көннән соң минем белән сөйләшмәс булды. «Белеп тор, син нахакка кеше рәнҗеттең, әҗере үзеңә төшми калмас», – дип, бер генә сүз әйтте. Безнең аралар тәмам бозылды. Ә бервакыт ул өйгә кайтмас булды. Һәм көннәрдән бер көнне сөяркәсе янына чыгып китте. Киткәндә әйтте: «Син бу көнне көнче сулышың белән тартып китердең. Син үзең шуны теләдең», – диде. Мин яшүсмер улым белән бер ялгызым утырып калдым. Уналты яшен тутырып килгән улыма әти кирәк иде. Ул гел әтисен сөйләде, кадерле кешесен югалтуда мине гаепләде. Мин аңа шул көннән әти дә, әни дә булырга, һәр адымын тикшереп-күзәтеп торырга тырыштым. Ул миңа: «Суларга ирек бирмисең», – дип зарлана торган иде. Бәлкем шулай булгандыр да. Бер-беребезне аңламый башлагач, ирексезләп диярлек психологка алып бардым. Әңгәмәдән соң белгеч миңа әйтте: «Улыгызга авыз ачып сүз әйтергә дә ирек бирмәдегез, сез аны шәхес буларак тәмам изгәнсез», – диде. Үземне ничек тотарга, ничек сөйләшергә кирәклегенә кадәр өйрәтеп җибәрде. Ләкин бу киңәшләрнең берсенең дә кирәге булмады. Улым-газизем, күз нурым, балтасы суга төшкән кешедәй бер-ике ай йөрде дә, үз-үзенә кул салды. Барын да искә төшерә башласаңмы... акылдан язарсың. Баламны – соңгы өметемне баудан алганда янә Алсуның сүзләрен искә төшердем. Баламны харап иттем, дидем. Соңгы юлга озатканда килгән ирем дә шул сүзләрне кабатлады. Ни гаҗәп, үзен бер дә гаепле санамады. Баласы янына сукмакны онытуын да бернигә куймый. Менә бит ирләрнең ничек аларның: хатын-кызга гына ялгышырга ярамый, гөнаһысы да кичерелми. Ә үзләренә... үзләренә теләсә ни ярый.

Кылган гамәлләребез өчен кайчан да бер җавап бирәсе анысы. Ни генә эшләмик, ул безгә кире әйләнеп кайта. «Ни чәчсәң, шуны урырсың», дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр борынгылар. Бу урында янә «карма»ны искә төшерергә мәҗбүрбез. Ләкин шунысын онытмыйк: бу тәгълимат тарафдарлары әйтүенчә, карма ул беркайчан да соңгы хөкем карары була алмый. Тик ул һәрчак синең өчен игелек яки явызлык булып әйләнеп кайтырга мөмкин. Кайсысы булып? Анысы инде безнең башкарган эшләребезгә, үз-үзебезне тотышыбызга бәйле. Әйе, бернәрсә дә югалмый, ә бары икенче бер төс ала, үзгәреш кичерә. Бер дә уйламыйча әйткән нахак сүзләр, рәнҗетүләр дә эзсез югалмый. Ул сабыр гына үз сәгатен көтә. Шуны истә тотсак икән без. Күңелендә тынычлык булмаган, үз-үзенә урын тапмаган кешенең беркайчан да бәхетле булмаячагы турында сөйләп тору кирәк микән? Биредә дә нәкъ шундый очрак менә... Әгәр дә сине үткәндәге уйлар бертуктаусыз эзәрлекли икән, син гомер буе үткәндәге шул хәлләргә килеп кабачаксың. Шул рәвешле тормышыңдагы яңа үзгәрешләргә мәңгелек киртә куячаксың. Мондый нәтиҗәгә килү өчен зур акыл кирәкми, тормышның үз тәҗрибәсе, үзенең гыйбрәтле сабаклары бар аның.

– Менә... ни дип җибәргән инде ул бу хатны? Янә авыр сүзләр, үпкә-каргышлар...

– Ачып карагыз, бәлкем... – дип әйтә башлауга ук, ул мине шундук туктата:

– Бәлкем түгел, нәкъ мин әйткәнчә.

Тик шулай да ул түзми, тиз генә конвертны ача башлый. Аннан килеп чыккан берничә рәсем һәм хат кисәге. Фотосурәтләрнең әле берсенә, әле икенчесенә озак кына карап тора да миңа суза: «Без...» – ди ул, кирәкле сүзен таба алмыйча. Сурәттән безгә ике яшь пар елмая. Һәм икегә бөкләнгән кәгазь битен ачып җибәрә.

– Нәрсә дигән? – дим сабырсызланып. Ханым хатка күз генә төшереп ала да янә миңа суза:

– Мин сине кичердем, дигән, – ди ул ишетелер-ишетелмәс кенә. – Кичердем, дигән...

– Сезнең дә аннан гафу үтенәсегез килмиме? Чыгып киткәндә генә бирелгән соравымнан ул каушап кала, бер мәл дәшми торгач әйтеп куя:

– Кемгә кирәк хәзер минем гафу үтенүем? Кичердем, дигән бит инде...

Хаталык – миннән, кичермәк – синнән, алайса...

УКЫТУЧЫЛАР КӨНЕ ӨЧЕН ОКТЯБРЬ АЕ ТӘГАЕНЛӘНГӘН БУЛСА ДА, БЕЗ СЕНТЯБРЬНЕ МӘКТӘП, СЫЙНЫФТАШЛАР, УКЫТУЧЫЛАР ТУРЫНДА ХАТИРӘЛӘРНЕ ЯҢАРТЫП КАРШЫЛЫЙБЫЗ.

Асия Юнысова

СЕЗ ИҢ ГАДЕЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!

Сентябрь ул Белем ае. Беренче битеннән үк «бишле» белән башланып китәргә тиешле ап-ак дәфтәр бите, типография буявының исе дә җилләмәгән яңа китаплар, әле аяк киеме эзләре сызылып калмаган идәннәр, акбурга батмаган кара такталар... Һәммәсе, һәммәсе садә һәм саф. Матур киенгән укытучылар, дөрес формадан килгән укучылар – барысы да тормышны бүгеннән, нәкъ менә 1 сентябрьдән – чиста биттән башлап җибәрергә әзер халәттә. Парта өстенә яңа дәфтәрен ачып салып, беренче биремне киләчәккә якты өмет белән башкарган баланың эшенә кайсы укытучының «икеле» куярга йөрәге җитсен! Һәрхәлдә, безнең укытучылар куймый иде. 1 сентябрьнең яме киткәнен хәтерләмим. Гаделсезлек булган булса, онытылмас иде.

Бала укытучыдан өендә күрмәгән, дөньяда күзәтелмәгән абсолют гаделлекне көтә. Укытучысының үзе игътибарга да алмаган игелеген бала-чага гомер буе йөрәгендә йөртә.
Шушы бер җылы хатирә аңа дөньяның иң хәтәр сынауларын җиңеп чыгарга көч бирә, котып салкыннарында туңмаслык итә. Бүген менә хезмәттәшләремне юри сораштырам. Гаделлекнең капма-каршысы – гаделсезлек белән очрашырга туры килгәнме аларга? Юк, юк, игелекккә мисал сорасам, хатирәләрнең иге-чиге булмас иде. Мәктәп елларындагы гаделсезлек мисалы кирәк иде.

Беренче мисал: «Бервакыт озынайтылган көн группасында шашка уйнадык. Малай-шалай гына түгел, кызлар да шаярыша. Ара-тирә шашкалар идәнгә дә тәгәрәп төшә. Уеннан соң шашкаларны тартмаларга тутырып, шкафка куя торган идек. Бу юлы бер шашканың оясы буш булып чыкты. Әй эзлибез, әй эзлибез шашканы. Юк кына бит. Берзаман итәгемне сыпырып җибәрсәм, теге шашка минем кесәмдә икән. Мин, сөенеп: «Менә ич ул», – дип, теге шашканы тартып чыгардым. Укытучы апа мине тәмам тиргәп ташлады. Алай гына да түгел, кара такта янына урындык куйдырып, миңа шунда менеп басарга кушты. «Менә, балалар, карагыз: бу кыз – карак!» – дип, хурлык тамгасы якты. Һич онытасым юк. Хурлык баганасына хөкемләнгән Чернышевский турында укыгач, миңа ул бик җәл булган иде».



Икенче мисал: «Әгәр математика укытучысы миңа – класстагы иң көчле математикка «бишле» куярлык эшемә «дүртле» куймаган булса, апагыз журналист булмый иде. Хыялымда математик идем. Вуз сайлар көн килеп җиткәч, шул укытучыга үпкәләп, тарих факультетына кердем. Шул һөнәрне сайладым. Әмма, күрәсең, ул һөнәр буенча да эшләргә язмаган икән миңа».

Өченче мисал: «Дәрес вакытында алдагы партадан арттагы партага язу җибәрделәр. Мин – арадашчы. Артка борылып язуны сузуга укытучы күреп алды. Аны-моны аңышып тормады – мине класстан куып та чыгарды. Мондый хурлыкка калганым юк иде. Әле дә оныта алмыйм».

Дүртенче мисал: «Минеке, гомумән, реплика гына. 1 нче сыйныфка кергәндә русчам әйбәт түгел иде әле. Беренче чирек ахырында укытучыбыз әнкәйгә мине акылы зәгыйфь балалар мәктәбенә күчерергә киңәш иткән. Шул укытучыга мәктәпне тәмамлаганда алган көмеш медалемне, программист дипломымны күрсәтәсем килә».

Сагындырып искә төшә торган мәктәп елларыннан берничә әрнүле мизгел... Юк, болары да үпкә түгел, наз гына. Чөнки шунда ук сөйләшүебез аналардай кайгыртучан укытучыларыбызның игелекле гамәлләрен искә төшерү юнәлешен алды. Алар сабыр да, матур да, фидакарь дә булган икән. Кемдер тормышта юнәлеш биргән, кайсыдыр иң четерекле бер мизгелдә ялгыш юлдан саклап калган. Тормыш ул ярминкә дә, базар да түгел. Яхшысы да, яманы да тигез анда. Менә шул тормыш капкасы янында маяк кебек торган фәрештәләргә – укытучыларга сабыр да, гадел дә, матур да, көчле дә – ягъни үрнәк кеше булып калу өчен сәламәтлек телик. Яңа уку елы хәерле башлансын!

PRESSA.RU

Сүз — уй-фикернең киеме, калыбы. Ә сүз энергиясенең структурасы күпкә тыгызрак. Шунлыктан ул энергия тизрәк материальләшә икән. Бусы ачыш түгел, күптән билгеле хакыйкать. Ә менә иң хәтәр авыруларны да сүз белән дәвалап булуын әйтсәк... Менә монысын инде ачыш дияргә дә була.

СҮЗ ХИКМӘТЕ

«Иң элек Сүз булган. Ул – Аллаһ дигән сүз», диелә Тәүратта. Коръән дә куәтли бу тәгъбирне. Димәк, сүзләр, тел безгә Аллаһы Тәгалә бүләге. Ә тел күрке – сүз. Аралашу, уй-фикереңне үз телеңдә җиткерү, Тукай әйткәнчә, тел-лөгать алмашып яши алу бик зур нигъмәт бит ул, уйлап баксаң. Кешене җәнлек-җанвар, хайваннардан аерып тора торган төп билге дә шул – сөйләм теле түгелмени?! Телнең, сүзнең олы хикмәткә ия икәнен борынгылар гасырлар буе искәртә килгән. «Тел дигән дәрья бар, төбендә энҗе-мәрҗән бар, белгәннәр чумып алыр, белмәгәннәр коры калыр». Яки «Татлы тел иясенә бал ашатыр, татсызы таяк ашатыр». Халыкның сынамышлары, мәкаль-әйтемнәре сүз дигән хикмәт белән бик сак булырга өнди дә... Йә, кайсыбыз, борынгылардан акыл-үрнәк алып, сакалны сыйпап, дәшми генә утыра соң бүген?! Сөйләшәбез, бәхәсләшәбез, юкны-барны сөйләнәбез... Кайчак, урынлы-урынсыз, кирәксә-кирәкмәсә дә карганабыз хәтта ки. Тел сөяксез, ни сөйләмәс, дип җаваплылыктан качарга омтылабыз. Авыздан чыккан бер сүз кырык кешегә җитәр, диләр. Әмма ләкин яхшы-яман сүзнең хәтта ки язмышларны үзгәртергә сәләтле икәнен кемнәр генә белә дә, кайсыбыз гына сүзен үлчәп сөйләве белән мактана ала. Гәрчә, «Таш ташны ярыр, яман тел башны ярыр», «Кеше сүзе кешене үтерә» дигән әйтемнәрне һәммәбез дә акыл савытына күптән салып куйган бит...

Уйламыйча, телдән ялгыш ычкынган яисә уйнап кына әйткән сүзнең дә киң җиһанда яңгыраш табуы һәм яхшы-яман булып үзеңә кире әйләнеп кайтуы, киләчәкне программалаштыру көченә ия булуы хакында дөнья галимнәре, күптөрле тәҗрибәләр үткәреп инанган. Әйткән сүзне юкка гына аткан укка тиңләмиләр. Димәк, кемгәдер тия, яралый, җәрәхәтли ул. Күңелне генә түгел, тәнне, әгъзаларны да! Чынында, ничек сөйлибез, шулай яшибез.

Немец психотерапевты Носсрат Пезешкиан тән авыруларын китереп чыгара торган сүзләр булуын ачкан. Шуларны зарарсызландыру ысулларын эзли башлаган. Вакытлар үтү белән галим, җимергеч сәләткә ия булган сүзләрне һәркем диярлек, һәрхәлдә, күпчелек уңга-сулга чәчүен ачыклаган. Югыйсә чирсырхауларны программалаштыра торган сүзләр алай ук күп тә түгел, әмма без алардан саклануга әһәмият

итмибез икән. Шуңа күрә алар тәнгә үтеп керә, савыгырга ирек бирми. Галим андый сүзләргә органик – тереклек сөйләме дигән атама бирә.

Әлбәттә, татарча алар башка төрлерәк яңгырый, әмма асыл мәгънәсе шул ук: органик сөйләмнең кешенең орган – әгъзаларына турыдан-туры тәэсире бар. Андый җөмлә-сүзләрне без бик яхшы беләбез. Тик аларның җимергеч көче хакында уйланмыйбыз гына. Куркыныч, җимергеч көчкә ия энергия бик көчле. Сау-сәламәт кешене дә чиргә сабыштыра ала икән. Иң кызыгы, андый гыйбарәләр шулкадәр оста яшеренгән ки, гап-гади, зарарсыз тоелган моң-зарның никадәр хәвеф китерүе хакында уйлап та тормыйбыз.

Җимергеч сүзләрнең кайберләре: сабыр канатларым сынды, сабыр итәлмам инде; башым каткан; эчтән мине нидер кимерә; өзгәләнәм, эч поша.

Башымны ашыйлар инде болар; үзәк-бәгыремә үтте (кемдер, нидер).

Бугазга пычак салалар; аркага пычак кададылар; күрәсем дә, ишетәсем дә килми берсен дә.

Җанымны алалар; канны кайнаттылар; колак итемне ашыйлар; төкерәм һәммәсенә!

Туйдырдылар; гарык булдым, бер кабарлыгым калмады; дер калтырап торам...

Муенга менеп атландылар, күңелне кайтардылар; үтерәләр болар мине.

Кычытмаган җирне кашый; бугазга басалар; тын алырга ирек бирмиләр.

Кирәккәндә-кирәкмәгәндә телдән ычкына, ычкына гынамы – оча торган мондый гыйбарәләрне тагын да дәвам итәргә булыр иде. Сүзгә кесәгә керми, шулай тапкыр сөйләшәбез, үткен-шәп гыйбарәләрне генә кабатлыйбыз сыман тоела безгә. Ә чынлыкта... без үз тәнебезгә төп-төгәл боерыклар биреп, аны чиргә сабыштырабыз икән бит! Ә тәннең тыңламый хәле юк. Буйсына!

Сөйләмнең сәламәтлеккә бәйләнеше хакындагы нәтиҗәләрен табиб Пезешкиан күптән түгел генә бәян итсә дә, моның хакыйкатькә туры килү-килмәвен күп тапкырлар тикшерергә өлгергәннәр инде. Сөйләм теле чир китереп чыгарамы, әллә авыру хакында белгертә генәме? Бу сораулар аеруча мөһим тоелган. Җавап: нәкъ менә китереп чыгара! Баштарак җимергеч көчкә ия сүзләр әллә авыру башлануын хәбәр генә итәме дигән фараз да булган. Янәсе, чир теге яки бу әгъзасын зарарлаган авыру кеше, үзе дә аңламыйча, теленә килгән сүзне кабатлыймы? Шул хакта әйтәме? Бу фараз расланмый.

Ә хәзер икеләнми шуны әйтергә була: җимергеч сүзләр кулланырга яратучы кеше конкрет авыруны үзе программалаштыра. Шуннан соң бу чир тамыр җибәрә. Андый-мондый чир түгел, нәкъ менә тел белән әйткәне.

Ни гаҗәп, чиргә сабыштыра торган сүзләр үзләре дә шул рәвешле сөйләшүче сөйләмендә ныгый, тамыр җәя. Әмма максаты бүтән аның: авыруга таруы хакында хәбәр бирү, кисәтү түгел. Ә бәлки чиргә ныгырга ярдәм итү икән. Бу аңлашыла да: сөйләмнең мөстәкыйль психологик программасы – үзе булдырган нәрсәгә булышу ич. Немец галиме һәм аның ярдәмчеләре меңләгән авыруны күзәтеп, гаҗәеп кызыклы нәтиҗә ясаган. Әгәр дә сез үз сөйләмегездә еш кулланыла торган сүзләрне анализлап, сәламәтлекне какшата торганнарын билгеләсәгез, ярты эш эшләнгән дип исәпли аласыз. Ышаныгыз, сөйләмегездәге җимергеч сүзләрне ачыклагач, алардан котылу юлы да ачыклана. Тотылган каракны фаш итү кыен түгел бит. Ә җимергеч сүзләрдән котылсагыз, чир дә чигенәчәк.

Кайсы сүзләр һәм гыйбарәләр чиргә этәрә соң? Менә кайберләре:

Косасы килә; бугаздан гарык; күңел кайтты – нерв авыруларына ишарә.

«Телнең михнәтен баш күрә», дип юкка әйтмиләрдер. Тормышта моңа мисаллар җитәрлек.

Өстә йөк булып тора; җилкәгә менеп атландылар – остеохондрозга;

Нидер буа, тормышны агулый; үз-үземә хуҗа түгел; үләселәр килә – онкологиягә.

Үз-үзеңне ашау, мыскыллы сүзләр әйтү, кемнедер күралмау – ашказаны җәрәхәтен китереп чыгара.

Бөергә таш утыргандай, көч юк, үләрлек булып арыдым – урология авыруларына.

Йөрәк ярыла; йөрәккә кадалды; йөрәккә якын алу – инфарктка.

Кычытмаган җирне кашый; тиресе калын – тире авырулары, аллергиягә.

Баш ярыла; мием череде; баш чатный – мигрень, һава торышына бәйлелек.

Канымны эчәләр; канны сыгалар; кан тамырларына, үзәгемә үтте – кан авыруларына, аллергиягә.

Йөри-йөри аяксыз калдым; аксап-туксап бара; табаннар кызыша – көзән җыеруга, тамырлар тартышуга.

Сабыр итәлмам инде; түземлегем бетте; эссе капты – гипертониягә.

Күзем күрмәсә иде; карарга куркыныч; күреп туйган – күз авыруларына.

Ишетәсем дә килми; әйтмә дә; дәшмә; шаулама – саңгыраулануга.

Җенем котыра; калтырата; күңел болгаткыч – депрессиягә.

Мондый сүз-гыйбарәләрнең кемгә атап әйтелүе мөһим түгел, хикмәт шунда: сезнең авыздан чыккан сүз чиргә әйләнеп, үзегезгә үк әйләнеп кайта.

Моннан котылу юлы бармы?

Иң әүвәл сөйләмегезне «сөзәргә» өйрәнегез. Әлбәттә, махсус әзерлексез килеш моны эшләү җиңел түгел. Янәшәдәгеләрнең сөйләменә ныграк колак салыгыз. Якыннарыгыз нинди җимергеч сүзләрне кыз-

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

ганмый сибәләр икән? Акыл өйрәтергә тотынмагыз. Үгет-нәсыйхәт бирергә алынгансыз икән, моны кемне дә булса үпкәләтми, рәнҗетми генә дә эшләп була бит. Әдәпле, нәзакәтле итеп әйткән сүз генә хәтергә кереп калучан. Аннан, һәркемнең үз сөйләм рәвеше. Моны да онытырга ярамый.

Зынҗыр сүзләр

Җимергеч сүзләрне белгәч, аларны зарарсызландыру кыен булмас дип ышаныйк. Әгәр кызып китеп ычкындырсагыз да, гел кабатлап тормагач, алар зур зыян сала алмас дип уйлыйк. Әлбәттә, иң яхшысы, алардан тәмам котылу. Димәк, авызыңнан чыккан сүзгә хуҗа була белү сәламәтлек турында кайгырту ул. Кошны орлык, кешене сүз тозакка төшерә, дип юкка әйтмиләр.

Ә зынҗыр сүзләр дип нинди гыйбарәләрне атыйлар икән соң? Аларны кулланып, ирегебезне чиклибез түгелме?! Тумыштан бирелгән сәләт, мөмкинлекләребезгә алдан ук чик куябыз. Дөрес, зынҗыр – богау сүзләр әллә ни күп тә түгел. Әмма аларны таный белергә кирәк.

«Сүз белән кешене терелтергә дә, үтерергә дә була», дип юкка әйтмибез.

Иң күп таралганы: «Миннән бу эш барып чыкмас яки моны мин булдыра алмам», – дип, үз-үзеңә ышанмау, сәләтең булуга шикләнү. Шуның белән бу җөмлә иясе үз алдына киртә куя. Бер урында таптана һәм эшлекле сыйфатларын эшкә җигә, мантый алмый. Бу гыйбарәдә нинди мәкер яшеренгәнен белмибез генә. Югыйсә Ходай бар кешеләрне дә тигез, тумыштан сәләтле итеп яраткан бит. Ә теге яки бу эшне майтара алуыңа шикләнү, икеләнү ул Кодрәт иясенә ышанмау, димәк, зур гөнаһ була икән.

«Булмый миннән»; «булдыра алмыйм»; «моңа көчем җитмәс»; «миннән тормый»; «җаваплылыкны өстемә ала алмыйм»; «каян булсын инде ул бездә»... Болар барысы да табигать тарафыннан тәгаенләнгән бурычыңны үтәмәскә саллы сәбәп кенә. Ә менә татарстанлылар шигаренә әйләнгән «Без булдырабыз!», чынлыкта, гаять зур көчкә ия икәненә күпләр инанды инде.

«Мин моңа лаек түгел!» Монысының бурычы бүтәнрәк. Гадәттә, мондый гыйбарәне яратып кулланучылар бер урында тормый, алар эштә, гыйлем җыюда үсә, үзгәрә, тырыша. Алар яшәү мәгънәсен, түбән хезмәттә таба, җаваплылыктан курыкмый торган «эш атлары». Ләкин «мин лаек түгел» дип өсләренә ишелергә мөмкин булган дан-дәрәҗә, матди байлыкка киртә куялар. «Әле вакыты җитмәгән», «миннән генә торамыни...», «кем соң мин ул кадәр» – тыйнаклык билгесе кебек тоелса да, бу сүзләр сезнең файдага түгел.

«Теләмим, әмма мәҗбүрмен» – безнең иң яраткан сүзләребезнең берсе түгелме икән? «Шулай кирәк», «мин тиеш», «проблема» сыман сүзләрне дә мәкерле дип атарга була. Көненә ничә тапкыр без шул сүзләрне кабатлыйбыз, бүтәннәрдән ишетәбез. Аларның асыл мәгънәсе хакында уйламыйбыз да. Шул сүзләрнең борчуга салуын, гел бурычлы булу шатлык түгелен әллә белмибез... Әллә алар үзләре безне ычкындырмый, телдән тартып тора?

Зынҗыр сүзләрнең тагын бер төркеме: «мөмкин түгел».

Хыял канатларын кисүче сүз шул үзе түгелме? Ә бит хыялыйлар – мөмкин булмаганны тормышка ашыручы романтиклар булмаса, бу җир бик кызыксыз булыр иде. Электр, телефон, интернет... хыялыйлар казанышы ич.

Зынҗыр сүзләрдән ничек котылырга? Әйдәгез, кара исемлек булдырыйк та, безгә алга атларга, максатка ирешергә комачаулаучы сүзләрне шунда теркәп куйыйк. Күренә торган җиргә, әйтик суыткыч ишегенә беркетеп атна-ун көн тотсак, җитәр. Аннан алып ыргытырга да була. Әмма алар күз алдында торганда баш, зиһен эшли – димәк, котылу мөмкинлеге бар.

Канатлы сүзләр

Андыйлары да аз түгел. Шөкер, бар алар.

Әйтик, «мин булдырам».

«Минем барысы да әйбәт булыр». Ә иң куәтлесе – изге ният белән, алдан ук исәп итеп, зур теләк белән тотынган эш: «Илаһи, ният кылдым» дип башланганы түгел микән?!

Халык әйтсә, хак әйтә. Сынамышларын халык мәкаль-әйтемнәргә таслап салган.

Ачы тел – зәһәр, татлы тел – шикәр.

Авыздан чыккан сүз – очкан кош, һавага җәелә – түз.

Дөньяда сүздән көчле нәрсә юк.

Агач башын җил бора, адәм башын сүз бора.

Кеше сүзе кеше үтерә.

Тел җәрәхәте сөңге җәрәхәтеннән дә яман.

Теле яманның көне яман.

Телнең буе кечә, гөнаһысы олы.

Телчән теленнән табар.

Тик тормаган тел башка бәла китерә.

Үтергән дә тел, тергезгән дә тел.

Теле авызына сыймый.

Теле белән тере агачны корытыр.

Теле татлы, күңеле каты.

Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.

Сүз артыннан сүз чыга, күп сөйләсәң күз чыга.

Усал эштән түгел, усал сүздән саклан.

Яман сүз йөрәккә таш булып утырыр.

Явыз тел мылтыктан куркынычрак.

Яхшы сүз аркасында адәм – адәм, яман сүз аркасында адәм – әрәм.

Роза КАМАЛЕТДИНОВА



ЖАМАЛИ Нурания

Казан театр училищесы, Казан дәүләт университеты.

Кияүдә, ике улы бар.

Карьера:
режиссер, сценарист

«Уңыш сере бик гади: талантың һәм сәләтең янына тау кадәр тырышлыгыңны кушасың».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Таулар холкын таулар гына аңлар...

Улым Булат быел җәй Кавказга барды – Эльбрус тавына күтәрелделәр. 5642 метр биеклеккә! Дүрт көн менделәр! Кешене сынап карарга теләсәң, аның белән тауга мен, диләр. Булатның исә үз-үзен, мөмкинлекләрен, ихтыяр көчен сынап каравы булды бу. Спорт белән даими шөгыльләнә, физик яктан әзерлекле ул. «Тау түбәсенә Татарстан флагын кададым!» – дип хәбәр итүен гаилә белән көттек. Безгә дә сынау булды бу: ул көннәрдә күңелебез белән без дә Булат янәшәсендә, Эльбруста идек бит.


Казан – икенче яшьлеген кичерә!

Мин Сибгат Хәким урамында торам. Яныбызда – яңа спорт комплекслары. Шуңа күрә өй тирәсендә дә гел туристлар очрый: кафе, тукталыш кая икәнен сорыйлар. Сөйләшеп китәбез. «Шәһәрегез шундый матур!» – диләр. Бу сүзләр күңелгә сары май булып ята – үз өеңне мактыйлармыни! Арттырып әйтмиләр анысы. Әнә урам буйлап чәчәк тә чәчәк! Чемпионат вакытында, кайсы каналны ачсаң да Казанны күрсәттеләр. «Безне монда шундый әйбәт кабул иттеләр», – диделәр. Кунакчыллык – татарга хас сыйфат. Без шуның белән башкалардан аерылабыз да.

Кайту өчен киту

«Формула-1»нең элеккеге узышчысы 37 яшьлек Джастин Уилсон «500 миль Поконо» ярышы вакытында авариядә һәлак булды. Фаҗига күпләрне тетрәндерде. Әмма аның үлеме кемнәрдер күңелендә өмет тә уятты: Джастин донор булырга ризалык бирү турындагы килешүгә кул куйган булган. Сулышы өзелгәннән соң, бер тәүлек эчендә аның 6 әгъзасын 6 кешегә күчереп утырттылар. Мондый көчле рухлы кешеләр мине бик сокландыра!

сөендерде









көендерде

сөендерде







көендерде

сөендерде



көендерде

Сер калмады

Эштән кайтам. Автобуска бәби көтүче яшь ханым керде. Аны күргәч, олырак кешеләр шунда ук күзләрен читкә алды... Игътибар иткәнегез бармы икән, хәзер йөкле хатыннарның күбесенең корсаклары кендеккә кадәр яртылаш ачык йөри. Элеккеге кебек киң, иркен, озын күлмәкләр кию бетте ул. Борынга җиткән корсакны күрсәтеп журналларга да төшәләр, шул рәсемнәрне социаль челтәрләргә дә куялар... Кендек – ана белән баланы тоташтырып, бәйләп, бербөтен итеп торган урын. Ул чит күзләрдән барыбер яшерен булырга тиештер.

Үтәлмәгән канун нигә кирәк?!

Җәмәгать урыннарында тәмәке тартмау турында бик кирәкле закон чыгардылар. Тик ул күбрәк коры сүздә калды, тормышка ашмады. Кибет янында, «Тәмәке тарткан өчен 3 мең сум штраф» дип язылган язу астында басып рәхәтләнеп тарталар. Дөрес, беренче мәлдә азайган иде тартучылар, качып кына төтәтә башлаганнар иде. Ә хәзер тагын иркенәйделәр. Тарту өчен махсус урыннар да эшләнелде югыйсә. Бигрәк тә коляска этеп баручы әниләрнең кулында тәмәке күрү, сискәндереп җибәрә...

Кешеләргә нәрсә җитми?!

Яңалыкларга күз салырга куркыныч: дөньяның төрле почмакларында сугышлар бара. Анда шартлаулар, монда... Шул ук Украина Беренче бөтендөнья сугышын да күрде, икенчесен дә. Чернобыль фаҗигасен дә кичерде. Ничекләр сабаклар алмаска була?! Табигать бит кешеләргә һәлакәтләрне болай да биреп кенә тора: янартау ата, җир тетри, су баса, давыл куба...

PRESSA.RU

16+

ДУСЛАР КҮП, ХАТЫН БЕР ГЕНӘ!

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?



Рөстәм ЗАКИРОВ, жырчы, Татарстанның халык артисты; өйләнгән; гаилә стажы — 15 ел; ике бала атасы.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Яшь барган саен, карашлар үзгәрә икән ул. Кеше турында фикер тусын өчен күзенә-чәченә карау гына инде җитми. Аның белән берәр төрле авыррак тормыш ситуациясендә булып карау кирәк. Кыен чакта ул үзен ничек тота – менә шунда кемнең кем икәне күренә дә. Яшь барган саен, хатын-кызга да акыл, зирәклек өстәлергә тиеш, аны да эше, гамәлләре матур күрсәтә.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Авыр физик эшне синнән башка башкара алмавын, мәсәлән. Әйтик, 30-40 килограммлы бәрәңге капчыгы син кайтканны көтеп көне буе подъезд төбендә торуны ничек гафу итмисең?!

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Бер төрле сөйләп икенче төрле эшләвен. Хыянәтне... Хәер, анысын белмим, хатын-кыз моны кайчак үз ирке белән эшләмәскә дә мөмкин бит. Күңеле, җаны белән хыянәт итмәсен ул. Тормыш кызык инде ул: кайчак юк кына нәрсә өчен дә гафу итмисең, ә кайчак шактый җитди әйберләрне дә җиңел генә уткәреп җибәрәсең.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручылар...

– Мин икесен дә теләр идем... Шулай булганда әйбәтрәк бит. Тик кайберәүләргә аның берсе дә эләкми.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Юк! Дуслар күп булырга мөмкин, ә хатын – хатын инде ул. Аның урыны башка.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Хәзерге яшьләр кафега барып, кыйммәтле балдаклар бүләк итеп ясый тәкъдимне. Аларныкы белән чагыштырганда безнекен тәкъдим ясау дип тә әйтеп булмыйдыр. Бик гади килеп чыккан иде ул. Җәй иде. Дүрт ел дуслашып йөргәннән соң, ике ел аралар суыныбрак торды. Мин ул арада башка берәү белән очраштым.

Яшь чакта үз-үземә әйткән сүзем бар иде: өйләнәм дип хәл итмичә, әти белән әнигә йөргән кызымны алып кайтып күрсәтмәм, дигән. Шулай булды да – безнең өйнең бусагасын Люция генә атлап керде.

7 Ир кеше, хатын итеп, әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр...

– Әнигә охшатып сайламадым хатынны. Кемнекедер, бәлки, үзе дә аңламыйча шулай килеп чыгадыр, минеке хәтта алай да булмады. Алар икесе ике буын кешеләре, бер-берсенә охшый да алмый. Әни – сугыш чоры баласы, тормышны ат урынына җигелеп тартты. Беркайчан иркә хатын булмады, аның ни икәнен дә белмәде. Ул юктан бар ясарга, ничек тә тартып-сузып җиткерергә тырышты.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар... Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Без өйләнешкәнгә 15 ел, матди яктан гаиләне мин үзем тәэмин итәм анысы. Әгәр киресенчә булса... Күп нәрсә кешенең интеллектыннан торадыр. Ярый ла, акча тапкан хатынның өйдәге мәшәкатьләрен үз өстенә алучы булса?! Ә бит шәһәр җирендә дә өйдә үзең генә калсаң, хатын-кызның эше тавык та чүпләп бетермәслек икәнен күрәсең. Без, эштән кайткач, өйдә үзебезне ял итәргә тиеш дип саныйбыз. Ә хатынның аның кнопкасына баскан, ул шулай эшләп йөрергә тиеш дип... Йөри дә!

Өйдә кемнең баш булу-булмавы акчаны кемнең күпме табуына бигүк бәйләнмәгән бугай ул. Зур гына җитәкчеләр бар, акчаны күрәп алалар. Ә өендә бөтен нәрсәне хатыны хәл иткәнен күпләр күз алдына да китерми... Цирк аренасында арысланны, юлбарысны үзенә буйсындырган дрессировщик хатын-кызлар бар бит, бу да шуның кебек. Мин моны дөрес түгел дип әйтә алмыйм. Үзең ихтирам иткән хатын-кызга буйсынып була ул. Эш-гамәле, җылы сүзе, ихласлыгы, затлылыгы белән буйсындыра андыйлар.

Кайбер хатын-кызның күз карашына ук буйсынасың. Әмма мондый көч бик азларга бирелә.

9 Гашыйк булуын башлап хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Мәктәп еллары искә төште әле... Ул кыз мине якын иткәндерме, юктырмы, белмим. Әмма ул минем беренче мәхәббәтем иде... Әгәр шул чакта ул үзенең дә гашыйк икәнен берәр ничек белдерсә, гаҗәпләнүемнән сөенүем күбрәк булыр иде... Үкенеч белән искә алуым түгел. Кем белән бәхетле булачагыңны алдан кайдан беләсең?! Бүгенгеләр гашыйк булганны гомумән беренче белдерә бугай. Татар эстрадасында яңгыраган кайбер җырларның сүзләренә генә игътибар итегез: «Син килмәсәң, үзем киләм», – дип җырлый сәхнәдән туташлар.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?

– Кеше белән аралаша башласаң, күпләрнең иң беренче соравы бертөсле яңгырый хәзер: «Нинди машинада йөрисең? Машинаңны алыштырмадыңмы әле?» Хатын-кызларны да ир-атларның тышкы кыяфәте, ничек киенүе, нинди телефоннан сөйләшүе беренче чиратта җәлеп итә бүген. Машинасын әйтмим дә. Хәер, дөньяны кем ничек күз алдына китерә?! Карашлар туры килү, интеллект дәрәҗәсен беренче урынга куйганнар да юк түгел.

11 Хатын-кызның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Иллегә җитеп киләм... Җырыма, иҗатыма игътибар итсәләр, миңа бүген шул җитә.

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр.

– Әйе, кем өчендер ул көчле булырга мөмкин. Әмма әллә кемнәрне үзенә буйсындырган хатын-кыз берәү алдында юашның юашына әйләнә дә куя... Бар булмышы белән көчле хатыннар сирәктер алар. Кемдер кайсыдыр абзыйга таянып көчле була. Андыйларны хөрмәт итеп булмыйдыр инде. Ә чибәрдән курку... Матур әйберне тотып карыйсы килә бит, монда да шулай. Дөрес, башта: «Мин моңа лаекмы икән?» – дип уйлыйсың инде.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Бар андый очраклар! Аңларга бик тырышсам да, мин үзем менә бер нәрсәне һаман аңлап бетерә алмыйм. Безнең бит көн саен йөри торган эш түгел. Люция бу яктан башка күп хатын-кызларга караганда бәхетле: вакыты иркенрәк. Торгач, итне суыткычтан чыгарып куя ул. Өч-дүрт сәгать эри ит. Алланың рәхмәте белән берзаман пешә башлый. Тагын бер-ике сәгать үтә... Ир кеше буларак гел бер нәрсәне уйлыйм: аш пешерергә ниятләгәнсең икән, ул итне суыткычтан кичтән үк чыгарып калдырырга да буладыр бит... Ярый, шулпа кайный тора, ул арада син эш белән каядыр барып киләсең, хәзер аш ашармын, дип кайтасың. Ит пешкән, аш юк! «Мунча ташы»ндагы кебек: «Аш кайнап чыкты, әни, итне кайчан саласың?» дигән шикелле... «Токмачны хәзер салып алам, югыйсә ул бит куера», – ди Люция. Ә мин барыбер моны аңламыйм!

14 Ир кеше ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Әгәр мин, әйтик, тәүге булып эшләсәм, өйдән иртән сәгать алтыда чыгып китеп, кичке биштә-алтыда гына кайтсам, төш вакытында банкада алып килгән ризык белән генә тамак ялгасам... Менә бу очракта кайткан җиремә өйдә кайнар ризык көтмәсә, тавыш чыгарыр идем, әлбәттә. Гастрольгә чыгып китсәм дә, ач йөрмим бит мин. «300 километр барасың бар, менә сиңа бензинга шуның кадәр акча», – дип, хатын киткәндә кулыма акча тоттырмый. «Ачуланмасаң, кереп ашап чыккан идем», – дип, кайткач, кайберәүләр кебек, мин дә аңа отчет бирмим – акча үз кулымда. Бүген өйдә ашарга булмаска мөмкин, булса да, мин теләгәне әллә пешкән, әллә юк, дип, юл өстендә ашап кайта алам.

Бик кирәк булса, дүрт-биш төрле ризык кына үзем дә әзерли алам.

15 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Люция инде алты ел үзе машина йөртә: мине көтмичә-көттермичә үзе генә дә каядыр барып кайта ала. Ә гаилә белән каядыр барырга җыенганда мин алдан ук: «Шул сәгатьтә китәбез», – дип әйтеп куям. Бала-чаганы хатын-кыз киендерә бит инде – һәрхәлдә, бездә шулайрак. Шуңа күрә алар, гадәттә, соңга кала да. Күп еллык күзәтүләрем буенча тагын шуны әйтә алам: үзләре ягына – Лениногорск районына кайтасы булса, Люция бик тиз җыена, ә минем авылга – Арчага дип кузгалсак, аны шактый озак көтәсе...

16 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Мин, әйткәнемчә, утыз өч яшьтә генә өйләндем. Тормышны үзем алып барырга инде шактый җайлашкан идем. Кием-салымны хәзер дә шуңа күбрәк үзем сатып алам. Алам дип... Андый хәл чынлыкта сирәк була. Үгезбозау йолдызлыгы астында туучыларның барысына да хас гадәт бугай бу: киемне тәмам тузганчы кию кирәк безгә. Америкадан алып кайткан ак курткамның өстемнән 13 ел төшкәне юк әнә. Кием-салым арзанлы булырга тиеш дигән нәрсә дә кечкенәдән канга сеңгән. Люция миңа бүләккә кыйммәтле әйбер эзләми дә – бу уңайдан ачы тәҗрибәсе бар аның... Миңа биргән иң файдалы бүләге – антирадар булды. Бер елны Төркиягә ялга барыр алдыннан шактый штрафым җыелганы ачыкланды. Шуннан соң бүләк итте ул аны. Хатын-кызларча, төрттереп: «Штрафыңа акча җәлләмисең. Ә миңа кайчак юк-бар гына әйбер алганга да бәйләнәсең», – дип.

PRESSA.RU

ЭШЛЕКЛЕ ХАНЫМГА ЭШЛЕКЛЕ СТИЛЬ



ЛЮКС
BOUTIQUE
ул. Калинина, д.37
(843) 264-51-61
Одежда только для Женщин!
Казан, Калинин ур., 37
+7(843)264-51-61
luxkazan.ru
БЕЗ КЕШЕЛӘРНЕ КИЕНДЕРЕП КЕНӘ КАЛМЫЙБЫЗ. БЕЗ ОБРАЗ ТУДЫРАБЫЗ.
РЕКЛАМА

Эшлекле ханым ул – бәйсез, акыллы, һәм иң мөһиме, заман белән бергә атлаучы кеше. Бизнес эшләрендә ир-егетләрдән калышмый, кайчак әле хәтта аларны да уздыра.

Карьерасын үстерергә ниятләгән хатын-кыз катлаулы сайлау алдында тора: гаилә учагын сүндерми саклаучы хуҗабикә роленнән ваз кичәргәме яки инде ике арбаны бергә тартып барыргамы? Бизнес белән шөгыльләнүче ир-егетләр арасында эшлекле дә, шул ук вакытта нәфис тә хатын-кыз була белергә кирәк. Беренче карашка, капма-каршы бу ике сыйфат бер кешедә яраша алмас сыман, ләкин җиңел юл сайлаучылар без түгел ул. Турыга тегелгән артык эшлекле костюм белән генә дә без шушы кырыс даирәдә бик урынлы күренерлек нәфис образ тудыра беләбез.

Пиджак:

эшлекле ханым гардеробындагы иң кирәкле кием ул. Ул кара, көлсу, күксел төстә, твид, йон, җитен тукымадан тегелгән булырга мөмкин. Ел дәвамында сезгә кечкенә, зур, тар, туры, классик – үзегезгә туры килә торган пиджак кирәк булачак.

Кыш көне ул сезне җылытыр, җәй көне ансамблегезне тулыландырыр. Язгы-көзге җиләс көннәрдә дә алыштыргысыз бу кием – топик өстеннән киден киттең...

Пиджакның башка киемнәрдән өстенлеге шунда – ул мизгел эчендә кешенең образын үзгәртә дә куя.

Дөньядагы иң классик киенү рәвешен күз алдына китерегез әле: джинсы чалбар – ак футболка – балеткалар. Футболка өстеннән кара-соры төстәге блейзер киеп куйдыгыз исә – ир-егет/хатын-кыз образы туа. Хәзер смокинг киеп карагыз – сез инде ресторанга кичке ашка барырга да әзер. Смокингны сәдәфләре алтын төстәге ике бортлы блейзерга алыштырыгыз – сез нинди затлы!

Көндәлеккә кию өчен гәүдәгезгә килешле пиджакны сез үзегез сайлыйсыз. Без исә бер-ике киңәш кенә бирәбез. Пиджаклар бер генә фасон белән тегелми, алар әллә никадәр!

Турыга тегелгән блейзер:

бу кием безгә ир-егетләр өстеннән күчте. Ул күп очракта костюм пиджагы, бернинди бөкләмнәрсез тегелә. Кайчагында түш кесәсе һәм арткы якта ерымы була.

Мондый блейзерлар теләсә нинди тукымадан тегелергә мөмкин, хәтта кыек шакмаклысыннан да, шевронлысыннан да!

Кулай төс – кара, караңгы зәңгәр.

Кулай тукыма – кыш өчен йон, кашемир яки алар катыш тукыма, кыскасы, җылы тукыма сайларга кирәк. Җәй көне киҗе-мамык, ефәк, җитенгә өстенлек бирегез.

Билле блейзер:

чып-чын хатын-кыз киеме. Ул бер яки ике сәдәфле була ала. Бил тирәсендәге бөкләмнәре аны гәүдәгә ятышлы итә. Мондый пиджакның түш кесәсе дә булырга мөмкин. Блейзер кыска икән – сәдәфе берәү генә. Озынрагына алтын төсендәге дүрт сәдәфкә кадәр тагарга мөмкиннәр.

Кулай төс – сезнең инде турыга тегелгән блейзерыгыз бар икән, билле блейзерның башка төстәгесен яки инде башка төрле тукымадан тегелгәнен сайлагыз. Мәсәлән, кара-соры төстәге киемне кыш көне дә, язгы-көзге айларда да киярге була.

Кулай тукыма – турыга тегелгән блейзерга ярашлы тукымалар билле блейзер тегү өчен дә яхшы.

Твидтан тегелгән кыска пиджак:

турыга тегелә, кыска, изүе түгәрәк, җиңнәре терсәктән чак кына озын. Сәдәфләре – алтынлы яки ниндидер үзенчәлекле. Бу пиджак атаклы Шанельнекен хәтерләтә – беркайчан да модадан чыкмаячак, һәр яңа коллекциядә тәкъдим ителә.

Кулай төс – тукыма һичшиксез ике төстәге бизәктән гыйбарәт. Соры белән кара үзара бик килешә.

Кулай тукыма – йон яки шуңа охшаш тукыма.

Смокинг пиджагы:

тантаналарга кию өчен хатын-кызларның смокинг пиджагы. Ул һәрвакыт кара төстә була, якалары ялтыравыклы ефәк яки атластан тегелә. Пиджакның эчке ягы фил сөяге яки комач төсендәге ефәктән дә тегелергә мөмкин. Сәдәфләре пиджак тукымасы белән тышланган. Бу модель турыга тегелергә дә, билле булырга да мөмкин.

Кулай төс – кара.

Кулай тукыма – йон яки ефәк.

Үз гәүдәңә килешле фасонны ничек билгеләргә? «Люкс» бутигында эшләүче белгечләр, кемгә нинди фасондагы кием килешкәнен генә әйтеп калмый, ә хатын-кызны ир-егетләр сокланып артыгыннан карап калырлык итеп киендерә дә белә.

Гәүдә рәвешенә, буй-сынга, күкрәк үлчәменә карап, үзегезгә генә үлчәп тегелгән кебек булган пиджак һичшиксез табылачак.

Тукымага килгәндә – бернинди дә чикләүләр юк, фасонының нинди булуы гына әһәмиятле.

Әгәр дә сез кечкенә гәүдәле икән, бер сәдәфкә төймәләнүче билле блейзер сайлагыз. Ул кыска булсын, гәүдәгезгә ятып торсын.

Шулай ук кыска твид пиджак та килешергә тиеш. Җиңнең терсәктән чак кына төшеп торганына игътибар итегез. Кыскасы: сезгә кечкенә пиджаклар килешәчәк.

Тулы гәүдәлеләргә турыга тегелгән пиджаклар матур. Күкрәк, янбаш тирәләренә сыланып тормаганы яхшы.

Камыштай зифа гәүдәлеләргә теләсә нинди билле блейзер килешә. Ул гәүдәнең ябыклыгын яшерә, кирәк урыннарны тулырак итеп күрсәтә.

Рәмзия КАШАПОВА

ЛЮКС
BOUTIQUE
ул. Калинина, д.37
(843) 264-51-61
Одежда только для Женщин!



PRESSA.RU

Ел буе көткән җәй үтеп китсә дә, никадәр хатирәсе калды! Сукмакларны сары яфрак сарып, тәрәзләрне кыйгач яңгыр юган шушы көзге көндә кемнәрдер зәңгәр диңгез кочагын сагынадыр, кемнәрдер — туган авылының җиләкле тугайларын. Бәлки әле шул көннәрдән истәлеккә фотолар да калгандыр, яр буеннан җыелган диңгез кабырчыклары да үз сәгатьләрен көтеп ятадыр. Әйдәгез, шушы хатирәләрне, фотокысага ябыштырып, стенага эләбез. Киләсе җәйгә кадәр күңелне юатып, хатирәләрне уяу тотсын.





Мастер-классны Лилия ГӘРӘЕВА үткәрә.

ҖӘЙ ХАТИРӘСЕ

Кирәк:

- иңе-буе 45-50 см булган ике катыргы кисәге (тартманыкы бик кулай);
- ПВА, «Момент-Кристалл» җилеме;
- бинт яки гофрланган ак кәгазь;
- йомырка кабыгы;
- диңгез кабырчыклары;
- 25-30 мм калынлыгындагы 4 м алтын төсендәге бау;
- акварель буяу;
- алтын төсендәге акрил буяу;
- төссез акрил лак;
- киңчә пумала, губка кисәге;
- аз гына түземлек һәм ярдәмгә балалар.







Эш барышы:

■ катыргы кисәгеннән диаметры 35 см булган 2 түгәрәк кисеп алабыз. Аның берсе – өске якка, икенчесе – аска.

■ Өске якка дигәненә фотолар өчен 5 түгәрәк «тәрәзә» уябыз. Зур «тәрәзәнең» диаметры – 12 см, кечкенәләрнеке – 7 см.

■ Хәзер шушы катыргының өслегенә җилем сылап, ике кат бинт урыйбыз. Бинт урынына юка ак кәгазь ябыштырсаң да ярый. Максатыбыз – катыргының кисем урыннарын каплау. Бик пөхтә итеп эшләргә кирәк. Бинт белән урасагыз, калын булмасын, тигез ятсын. Җилемнең кипкәнен көтәбез. Гадәттә, ул бер төн кибә.

■ Бизәү эшенә керешик. Йомырка кабыгын юып киптерәбез, эчке элпәсен кубарабыз. Бинт өстенә мул гына ПВА җилеме сылап, вакланган йомырка кабыгын ябыштырабыз. Буш урыннар калдырмаска тырышыгыз. Кипкәнен көтик, йә булмаса фен белән тиз генә киптереп алыйк.













Фото: Ксения Богданова

■ Йомырка кабыгы өстеннән зәңгәр төстәге акварель буяу белән буйыйбыз. Пумала чылатасы суга аз гына ПВА җилеме тамызыйк. Буяуның бер каты кипкәч, тагын бер кат буяп чыгабыз. Ул да кипкәч, губка белән алтын төс йөгертәбез. Губканы өслеккә җиңелчә тидереп-тидереп кенә алырга кирәк.

■ «Момент-Кристалл» җилеме белән «тәрәзә»ләр тирәли алтын төсендәге бау ябыштырабыз. Фотокысаның үзен дә алтын бау белән каймалыйк.

Бауның артып калганын ерак алып куймагыз, ул кирәк булачак әле.

■ Бизәгән катыргыбызны икенче түгәрәк өстенә салып, карандаш белән «тәрәзә» урыннарын төшерәбез. Күңелебезгә якын фотоларны шул эзгә турылап ябыштырабыз. Стенага элү өчен кысага элмәк ясарга да онытмыйк. Моның өчен астагы катыргының өске ягына без белән ике тишек тишәбез. Шушы тишек аша бау уздырып, очларын «Момент-Кристалл» җилеме белән эчтән ябыштырып куябыз.

■ Шул ук җилем белән ике катыргыны бер-берсенә ябыштырабыз. Кырыен алтын төсле бау белән каймалыйбыз. Диңгез буеннан җыелган кабырчыкларны да «Момент-Кристалл» җилеме белән ябыштырып куйыйк. Соңыннан кысаны бер кат акрил лак белән лаклыйбыз.

■ Фотокыса әзер – әлсе урынын гына тәгаенлисе калды. Мондый кыса әти-әнигә, дусларның туган көннәренә бүләк итү өчен дә әйбәт. Ул очракта «тәрәзәләргә» фотолары ябыштырыла.

киңәш...

■ Фотога төшергәндә яктылыкны дөрес сайлау мөһим. Көндез, кояш иң югары ноктасында булганда, фотога төшерү кыен – фотога төшүченең алдына куе күләгә ята. Фотосурәттә төсләр дөрес чагылсын дисәгез, иртәнге вакытны сайлагыз яисә кояшның болытлар арасына кереп качканын көтегез. Кояшлы көнне күләгәдә яктылык (вспышка) белән төшергән сурәтләр дә матур чыга.

■ Фотояктылык (вспышка) кулланып, шактый проблемаларны хәл итәргә мөмкин. Барыннан да битәр, караңгы урында төшергәндә объектны яктырту өчен кирәк ул. Икенчедән, яктылык белән контрастлылыкны арттыралар йә киметәләр. Мәсәлән, кояш яктысы кирәгеннән артык булганда фотояктылык күз төпләрендәге, борын астындагы күләгәләрне тигезләргә булыша.

■ Кешене кояшка аркасы белән бастыру дөрес түгел. Алай иткәндә йөзгә куе күләгә ятып, караңгы чыга. Кояшка йөз белән басарга кирәк. Кояш яктысы яннан төшеп, сурәткә төшүченең башын шул якка таба чак кына авыштырсаң да кешенең йөзе фотода ачык булып чыга.

■ Фон да мөһим. Кеше күзе, үзе дә сизмәстән, башкалардан ачык аерылып торган төсле объектларны эзли. Шуңа күрә дә объект арттагы фоннан төсе белән аерылып торсын. Мәсәлән, аксыл төстәге объектларны – караңгы җирлектә, караңгы әйберләрне аксыл җирлектә төшерәләр.

■ Кадрны дөрес итеп кора белергә дә кирәк. Төшерә генә башлаучылар объектны нәкъ кадр уртасына куярга омтыла. Кешенең күз карашы сурәтне сулдан-уңга һәм өстән-аска таба «укый». Кадрны шартлы рәвештә 2 аркылы һәм 2 буй сызык белән тигез шакмакларга бүләбез. 4 кисешү ноктасы барлыкка килә. Төшерәсе объектны уң яктагы нокталарга урнаштырсаң, фото отышлы килеп чыга.

■ Кадрдан барлык артык-портыкны алабыз, ул гадирәк булган саен отышлырак. Сурәткә төшүченең баш түбәсеннән, ян-ягыннан бернәрсә дә тырпаеп тормасын. Аның үзен кадрга эрерәк итеп кертергә тырышабыз. Бер төркем кешеләрне төшерәсез икән, аларны мөмкин кадәр бер-берсенә якын бастырыгыз – иңбашлары арасында ачыклыклар күренмәсен.

PRESSA.RU

ҖЫРЧЫ ИЛСАФТАН ГАЕТ СЫЕ

ИлСаф (Илсур Сафин) белән мастер-класс әзерләү хакында яз башында ук сөйләшкән булсак та, җырчыны тиз генә тотармын димә икән. Әле бер шәһәргә гастрольгә чыгып китә ул, әле икенче шәһәргә. Без килгән көнне дә иртән генә Стәрлетамактан кайткан иде. Иртәгәсен тагын юлга кузгаласы икән. «Мин хатыным Зилә пешергәнне ашарга яратам, аш бүлмәсендә кайнашырга үземнең вакытым юк», — дисә дә, ИлСаф чын осталык күрсәтеп, гает бәйрәмендә табын күрке булырлык сый пешерергә өйрәтте безне. Бу ризыкны әзерләргә Һиндстанда яшәүче дусларыннан өйрәнгән булган. Ризыкның бөтен уңышы — тәмләткечләрдә.





Кирәк:

- 1 кг сарык ите;
- 2-3 баш суган;
- 4-5 тырнак сарымсак;
- артык зур булмаган имбир тамыры;
- яшел төстәге ачы борыч;
- тәмләткечләр: кардамон, дарчин, зира, кориандр, канәфер, лавр яфрагы, паприка һәм зәгъфран (боларның барысы да кирәк).
- 2-3 аш кашыгы сөт;
- 4-5 аш кашыгы катнашмаларсыз табигый йогырт.

Эш барышы:









■ чынаякка сөт агызып, шунда 1 чеметем генә вакланган зәгъфран салып куябыз – ул сөттә җеби торсын.

Яшел борычны орлыгыннан арындырып, имбирның кабыгын әрчеп, икесен дә эрерәк итеп турыйбыз. Сарымсакны тырнакларга аерып, кабыгын чистартабыз. Боларның барысын да бер савытка салабыз. Кашык очына элеп, төелгән кориандр белән зира сибәбез. 2 аш кашыгы чамасы кайнаган су белән 1 аш кашыгы үсемлек мае өстәп (тәмләткечләр булган җирдә һәрвакыт май булырга тиеш, ул – тәмне ачу өчен кирәк), куе ботка хәленә килгәнче блендер белән вaклыйбыз. Әлегә аны бер читкә алып куябыз, ул безгә соңрак кирәк булыр.

■ Суганны чистартып, ярымбоҗралап турыйбыз. Табага аз гына үсемлек мае һәм 2 аш кашыгы атланмай салып, утка куябыз. Май эрегәч суганны салып, алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз. Суган кызаргач, аның өстенә гуляшка тураган кебек турап сарык итен салабыз. Кечерәк сөякләре керсә дә ярый. Алар тәм бирәчәк. Итне болгатмыйбыз! Кашык белән тигезләп кенә куябыз. Итне кызган суган өстенә салу бик мөһим. Суган өстенә салгач, итнең сүле акмый, йомшак булып пешә. Утны бераз көчәйтәбез.

■ Ит куырылган сыман булып, сүле акмаслык хәлгә килгәч, болгатып, кардамон, паприка, канәфер, лавр яфрагы, дарчин һәм блендерда издергән пастаны салабыз да 30 минут томалап пешерәбез. Итнең шулпасы кимергә тиеш. Таба читендә май күзләре күренә башлагач, сөтле зәгъфранны кушабыз. Утны арттырып, болгата-болгата, шулпасын кайнатып бетерәбез.

■ Ит пешкәч, 3-4 аш кашыгы йогырт кушабыз һәм көчле утта янә 2-3 минут чамасы тотабыз. Итнең шулпасы куе булып, иткә ягылып торырга тиеш. Тәмләткечләр белән пешкән бу ит искиткеч хуш исле, тәмле була. Сарык итенә хас тәме дә беленми. Аннан соң тагын бер нәрсәгә игътибар итегез: без тоз кулланмадык. Кирәк тәмне ашка тәмләткечләр бирә. Кыркурак ашарга яратучылар исә бер чеметем генә тоз салсалар да зыян итмәс.

■ Ит янына бирергә дөге пешереп алыйк. Дөгенең «Басмати» дигәне яхшы. Андые булмаса, гап-гади – озынча дөге алсагыз да ярый.

■ Зур матур тәлинкәнең ярты ягына дөге, ярты ягына ит салып, ризыгыбызны табынга чыгарабыз. Ит өстен яшел тәмләткечләр белән бизибез.

■ Ашларыгыз тәмле булсын! Барыгызны да Корбан гаете белән тәбрик итәбез!

Фото: Ксения Богданова

«ТУНЛЫ» ТАВЫК

Роза САФИУЛЛИНА – «Сөембикә»нең даими укучысы. «Аш-су» рубрикасында аның үзенең дә катнашканы бар. Казан сырхауханәләренең берсендә 30 елдан артык шәфкать туташы булып эшли ул. Буш вакыты булды исә аш бүлмәсендә кайнашырга ярата. Кызы белән киявен, нәни оныгын тәмле ашлар белән сыйлый. Шушы көннәрдә Роза ханымның икенче оныгы туарга тиеш. Сау-сәламәт, бәхетле бала булып тусын!

Кирәк:

- 2 тавык түше;
- 2 йомырка;
- 1 аш кашыгы крахмал;
- 2 аш кашыгы майонез;
- 1 аш кашыгы соя соусы;
- 200 г каты сыр;
- тәменчә тоз, борыч;
- кыздыру өчен үсемлек мае.

Эш барышы:

■ тавык түшен озынча көйгә берничә кисәккә бүлəбез, яхшылап тәпәлибез, тоз-борыч сибәбез.

■ Йомырка, майонез, крахмал, соя соусыннан сыек камыр ясыйбыз.

■ Сырны вак угычтан уабыз.

■ Тавык түшен камырга манып, уылган сырда әвәлибез. Шул рәвешле өч тапкыр кабатлыйбыз.

■ Итне майлы табада ике ягын да әйләндереп кыздырабыз. Ул бик тиз әзер була.



Кадерле укучыларыбыз! Конкурс дәвам итә. Сездән хатлар көтеп калабыз.

PRESSA.RU

Соңгы вакытта чирләр һаман яшәрә бара. Әле кайчан гына «әбиләр чире» дип саналган кан басымы өянәге, буыннар кату (остеохондроз), күкрәк бакасы (стенокардия), ишемия ише хасталыклар белән 30 яше дә тулмаган кешеләр дә интегә башлады. Яңа дарулар чыга тора, әмма бу зәхмәтләр даруларга бирешергә ашыкмый. Бәлки, гомер бакый гади халык даруланган чараларга мөрәҗәгать итеп карыйсыдыр. Бу хакта сөлек белән дәвалау серләрен белүче беренче категорияле табиб-гирудотерапевт Гүзәл БИКМӨХӘММӘТОВА белән әңгәмә кордык.





СӨЛЕККӘ САВАП

? Гүзәл ханым, югары белемле табиб ни өчен халык медицинасы белән дәвалауга керешә икән?

– Сөлек белән дәвалау кебек сыналган ысулга электән үк ышанып карый торган идем. Безнең әбекәйләрнең теше сызласа да, кан басымы күтәрелеп китсә дә, сөлек салуларын ишетеп тә, күреп тә белә идем. Аннары бу төр дәвалауга үзем дә игътибар иттем. Югары белемемә өстәп, махсус курсларда укып, бу җан ияләренең хасиятләрен өйрәндем. Әйтергә кирәк ки, бик күп кызыклы әйберләр белдем. Ул белгәннәремне файдаланып, иң әүвәле гипертония өянәге белән интегүче яшь укытучы ханымны дәвалап карадым. Гипертония стажы ун-унбиш елдан узып киткән авыруларым да бар иде. Югыйсә бу авырулар вакытында хастаханәгә кереп ятып, тиешле дәвалау курсын да үтәләр иде. Әмма билгеле бер вакыт үтүгә алар кабаттан кан басымыннан интегә башлый торганнар иде. Еллар дәвамында бер үк кешеләр шул ук чир белән әйләнәләр дә киләләр. Күрәсең, даруларның файдасы вакытлыча гына була.

? Менә шуларны уйлый торгач, Сез сөлеккә тукталдыгыз инде?

– Дарулар бирүне туктатып булмый инде анысы, әмма кешеләр гомер бакый шифасын күргән халык дәваларын ярдәмгә чакыруның бер зыяны да юк дип уйлыйм. Укый, өйрәнә торгач, мин Кытай медицинасында бик киң таралган энәләр белән дәвалау (рефлексотерапия) белән сөлек салу арасында бик күп уртаклыклар барлыгын төшендем. Әйтер идем, сөлек белән дәвалауның мөмкинлекләре тагын да киңрәк. Безнең Казанда хатын-кыз авыруларын, әйтик, аналык муентыгы ялкынсынуын, сөлек салып дәвалаучы гинеколог та бар.

? Сөлекче әбиләрне мин дә беләм әле.

– Минем бер пациентым – яшьлегендә «ашыгыч ярдәм» машинасында эшләгән ханым. Инфарктлы кешегә ярдәмгә ашыкканда табибларга үзләре белән сөлек алырга куша торганнар иде, дип сөйли ул. Авыруны машинада алып барган арада шул сөлекләр «беренче ярдәмне» күрсәтә торганнар. Ә бер хатын ике чигәсенә сөлек салынган килеш бәбиләгәнен сөйләде, чөнки аның кан басымы бик югары булган.

? Сезнең пациентларыгыз күптер дип уйлыйм.

– Әйе, сөлеккә өмет арта бара. Дәвалауның шифасы тиз беленә. Аннары сөлек аптека даруларыннан арзанрак бит. Бу ысул хәвефсез. Фәкать өч кенә төрле каршылык бар сөлек салуга: яман шешләр, өч айдан узган

йөклелек, гемофилия – менә шулар. Азып китү җәһәтеннән сөлек салган урынның кызарып торуын, бераз кычытуны әйтсәң генә инде. Әмма моны тозлы яки содалы компресс ябып, бик тиз дәвалап була.

?Сөлек кеше организмына ни рәвешле тәэсир итә соң?

– Сөлек салу урыннарының махсус нокталары бар. Әбугалисина хезмәтләрендә үк кайсы әгъза өчен кайсы ноктага сөлек салырга яраганлыгы хакында язып калдырылган. Гомумән, ул нокталар энә кадап дәвалау нокталары белән тәңгәл диярлек.

?Димәк, сөлек салу рефлексотерапия белән бер дәрәҗәдә шифалы?

– Юк, мин сөлеккә өстенлек бирер идем, чөнки сөлек үзе кадалган ноктага махсус сыеклыгын да кертә. Сөлек сыеклыгында 120 дән артык биологик актив матдә барлыгы билгеле. Бер ампуладагы шушы кадәрле биологик актив дару хакында медицина хыяллана да алмас иде.

?Сөлеккә 120 актив матдә нигә кирәк соң ул?

– Сөлек кан белән туена. Аның үзенә ун фермент та бик җиткән. Ләкин табигатьтә артык әйбер юк диләр бит. Күрәсең, Ходай Тәгалә минем бәндәләрем авырмый тормаслар, дип фаразлагандыр да, табигать имчесе сыйфатында тере шприц яралткандыр. Имә башлаган сөлек тере насос кебек эшли. Бер дигәндә, ул кан суыра; ике дигәндә, шул ярага сыекча сиптерә. Теге ун ферменттан артканнары сөлекнең «корбанын» дәвалауга сарыф ителә. Сөлек салган ярадан зарар күреп, бер тереклек иясенең дә үлгәне юк. Яныпп-пешеп эшләгәндә сөлек үзе сабый бала кебек чын-чынлап тирләп чыга.

?Ул ферментларның хасияте ниндирәк икән?

– Иң беренчесе – гирудин. Ул яра тирәсендәге канны сыеклый. Икенчесе – гиалуронидаза. Шуның ярдәмендә сөлек юлында очраган җәйләрне, каты нәрсәләрне йомшарта. Ферментлар сыегайткан ул катыларны сөлек суырып ала. Кан бик тиз генә оемасын өчен, ярага тагын махсус фермент сиптерә.

?Бу мәшәкатьләр сөлекнең үзе өчен тырышуы түгелме соң? Кешегә аннан ни сихәт?

– Сөлекнең егермеләп төрле сихәте бар, диләр. Иң беренчесе – ялкынсынуны бетерү. Ялкынсыну ике төрле була. Бертөрлесе аның микроблар, вирус-лар шаукымы; икенчесе – безнең аз хәрәкәтләнүдән. Күп утыра торгач, кан тамырлары оеша башлый. Хаста урынга кан бармаганга күрә анда кислород та килеп җитми.

?Кан йөрмәгәч, кислород килмәгәч, таркалу матдәләре организмда утырып кала димәкчеме Сез?

– Әйе, капиллярлар дарулар, азык консервантлары, судагы, һавадагы агулы матдәләр, консервантлар белән тыгыла. Авыру әгъзаның капиллярлары аша кан бөтенләй йөрмәс була. Шул сәбәпле, кеше, дәваланам дип, еллар буе эчкән дарулар авыру әгъзага үтеп тә керә алмый. Шлак белән тыгылган урыннарны безнең организм шешкән урын дип белә һәм шунда ашыгыч рәвештә лимфоцитлар җибәрә башлый. Шеш таралып китмәсен дип, организм аны төреп ала. Андый капсуланың тыгызлыгын әйтеп торасы да юк. Кешеләр әнә еллар буе тәннәрендә ярчык яки ядрә йөртәләр бит. Шуның сыман инде.

?Мондый очракта сөлек ничек ярдәм итә ала?

– Мин сөлекне нәкъ авырткан урынга салам. Әгәр кешенең бавыры авырта икән – бавырга; кан тамырлары сәламәт түгел икән – кан тамырлары янына; умыртка чөбәйләрендә бүсер бар икән – шунда. Якын тирәдә рефлекс ноктасы булмый калмый ул. Сөлек үзе аннары бик җаен белеп кенә теге капсуланы тишә.

?Сөлекнең тагын нинди сыйфатларын мактыйк икән?

– Сөлек безнең организмга 120 файдалы ферментын кертә. Шулай итеп, без кан басымын дәвалаган арада тагын берничә хасталыктан җиңеллек күрәбез. Авыру кешегә якынча 8-12 процедура кирәк. Шушы вакытта җыелган ферментлар кешегә ярты елга җитә. Сөлек сыеклыгы – тромбофлебиттан беренче дәва. 3-4 салудан соң тромб эри, кан тамырларының юлы ачыла, кан әйләнеше эзгә төшә. Холестерин микъдары да шактый кими, кан басымы азая, аллергиядән файдасы бар.

?Алай да нинди чирләрдән безне сөлек коткара ала икән?

– Иң беренчесе – гипертония; аннары варикоз авыруы, тромбофлебит, остеохондроз, умырткадагы бүсерләр. Простата бик яхшы дәвалана. Гомумән, сөлек кан тамыры белән бәйле чирләрнең барысын да яхшы дәвалый. Сүземне йомгаклап шуны әйтер идем: хроник чирләрегез булса, халык медицинасына мөрәҗәгать итүдән курыкмагыз – массаж ясагыз, төрле чәйләр эчегез.

?Бер яхшының бер начары дигәндәй, сөлек белән дәвалануның да үз кимчелекләре бардыр. Аларны да әйтеп китмәсезме?

– Әлбәттә, кемгәдер сөлек килешмәү очраклары булырга мөмкин. Нигездә, болар кан системасы белән бәйле кимчелек.

Сөлек ярамаган авырулар исәбендә гемофилия белән геморрагик диатез бар. Мондый диагнозлы кешеләргә сөлек салсаң, көчле кан китү булырга мөмкин. Әйткәнемчә, сөлек кан тамырына кан сыеклый торган матдәләр җибәрә.

?Кан басымы озак вакыт түбән торганда да сөлек салырга киңәш ителми. Пациентның хәле яхшырасы урынга начарланып китәргә мөмкин.

PRESSA.RU

Үлекле тромбофлебит дигән нәрсә бар. Бу чир вакытында кан тамырлары ялкынсына, тромблар барлыкка килә, кан тамырларының тышчасы эренли. Гемофилия вакытындагы кебек үк, бу очракта да сөлек бүлеп чыгара торган сыекчаның роле зур: тромб йомшара, әмма тәмам эреп бетми һәм шул йомшарган халәттә кан тамыры буйлап сәяхәт итә башлый. Үлекле тромбофлебитны сөлек ярдәмендә дәваларга маташып, кан тамырын тыгылдырырга мөмкинбез.

Азканлылык дигән диагноз куелган кешеләргә дә сөлек салдырудан тыелып торырга кирәк. Анемия вакытында канда гемоглобин нык кими. Ә гемоглобин канда кислород йөртүче вазыйфасын үти. Азканлылыктан йөдәгән кеше өчен кан югалту кирәкле әйбер түгел.

Йөклелек. Сөлек салуда кайбер каршылыклар йөклелекнең икенче һәм өченче триместрларында (өчьайлыкларында) бар. Беренче өч айда сөлек салганнан бернинди дә зыян юк. Бу вакытта хатын-кызның организмында җитди үзгәрешләр бара, иммунитеты бик нык кими. Үзгәрешләр барлык әгъзаларга да кагыла. Йөкле хатыннарның канында тромблар ясалуга комачаулый торган матдәләр барлыкка килә. Шулай итеп, йөкле хатыннарга сөлек салганда, аның карынындагы яралгыга да зыян килү куркынычы туа.

Арыклык, хәлсезлек тә сөлек салудан тыелырга кирәклекне искәртә. Бигрәк тә анемия сәбәпле ябыгу күзәтелсә, сөлек салырга ярамый.

Яман шешләр соңгы стадиягә кергән очракта да сөлек салу ярамас. Ә менә яман шеш авыруларын булдырмас өчен сөлек бик файдалы.

Кайбер кешеләрдә **сөлеккә карата аллергия** булырга мөмкин. Дөрес, ул сирәк очрый. Әмма катгый тыю өчен бу җитди сәбәп.

Әлбәттә инде, **күрем вакытында** сөлек белән мавыкмый торырга кирәк.

Озын сүзнең кыскасы: сөлек салу кебек уникаль дәвалау табиб күзәтчелегендә генә башкарылырга тиеш.

Асия ЮНЫСОВА әзерләде.

КИҢӘШ.

Көз — организм өчен авыр вакытларның берсе. Көннәр кыскара, суыта. Галимнәр организмның җылыдан суыкка күчкәндә бик көчле стресс кичерүен ачыклаганнар. Өстәвенә, дымлы салкын һава хроник чирләрне дә кузгатып җибәрә. Иммун системаны тәмам йончытмас өчен гади генә берничә чараны кулланып карагыз әле. Алар сезгә көзге кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итәр.

Туйганчы йоклагыз дисәк, ирен чите белән генә елмаеп куячаксыз инде. Туйганчы йоклау кайсыбызга гына эләгә икән ул? Шулай да, төнге унбергә кадәр ятарга тырышыгыз. Тәүлекнең нәкъ шушы вакытында организм меланин дигән гормон эшләп чыгара. Ә ул исә иммун системаны ныгыта. Кичке ун белән унике арасындагы ике сәгать йокы уникедән соңгы дүрт сәгать йокыга бәрабәр.

Дөрес тукланырга кирәген дә беләсез инде. Үзебездә өлгерә торган җиләк-җимеш, яшелчәләрне туйганчы ашап калыгыз дип әйтеп торасы юк. Ә менә үрдерелгән бодай белән дуслыгыгыз ничегрәк? Ул В төркеменә керүче витаминнар сандыгы бит. Тимергә бай терлек бавырын да күбрәк куллансаң яхшы. Ашкайнату белән бәйле чирләрне оеган сөт ризыклары бәйдә тота.

Көз көне организмыбыз кыш буена җитәрлек микроэлементлар туплап калырга тырыша. Файдалы ризыклар исемлегенең башында кызыл чөгендер тора икән. Ул эчәклектәге черетүче бактерияләрне юк итә, ә аның составындагы бетаин дигән матдә бавыр эшчәнлеген яхшырта. Организмны яшәртүче фолий кислотасына бай булуы да безнең файдага. Чөгендернең яман шеш авыруын җиңә алуы фәнни тикшеренүләр белән расланган.

Кәбестә бу исемлектә икенче урында тора. Ул эчәклектән авыр металларны һәм токсиннарны чыгара. Кәбестәнең тагын бер кыйммәте – анда U витамины бар. Ә бу витамин башка яшелчәләрдә бик сирәк очрый.

Сарымсакта 400 дән артык файдалы матдә барын белә идегез микән? Ул кан тамырларын чистарта, холестеринны киметә, баш миендә яман шеш китереп чыгаручы зарарлы күзәнәкләрне үтерә, туберкулез, дифтерия таякчыкларын һәм ашказаны җәрәхәтенең сәбәпчесе – хеликобактерларны юк итә.

Суган фитонцидлары белән кыйммәтле. Бу фитонцидлар зарарлы бактерияләрне мизгел эчендә юкка чыгара. Ул әле аппетитны да көчәйтә. Файдасын күрим дисәгез, суганны чи килеш ашарга тырышыгыз.

Көз көне күзәтелә торган күңел төшенкелеген җиңәргә баллы ризыклар ярдәм итәр. Бер-ике шакмак шоколад яки берәр пироженое кабып куйганнан гына фигурагыз бозылмас. Аның каруы, кәефегез ачылып китәр.



 **КУЧКАР.** Бик күңелле вакыйгалар көтелә. Актив тормыш рәвеше алып баручыларга, тормыштан күпне таләп итүчеләргә аеруча кагыла бу. Уңыш – сезнең яклы, теләсә кайсы эшкә курыкмый алыныгыз.

 **ҮГЕЗБОЗАУ.** Мондый уңышлы айны әле сезнең күргәнегез дә булмагандыр. Шулай да мөһим карарлар кабул иткәндә көчегезне дөрес бәяләгез. Авырлыклар булыр кебек күренсә дә, курыкмагыз. Алар вакытлыча гына.

 **ИГЕЗӘКЛӘР.** Эшегез күп, күңелсезләнергә туры килмәс. Киләчәккә планнар кору белән мәшгуль булырсыз. Җиң сызганып эшкә керешегез – нәтиҗәсе озак көттермәс. Дусларыгыз яки танышларыгыздан кызыклы һәм файдалы идея алырсыз.

 **КЫСЛА.** Эштә бар да тыныч, бар да тәртиптә булыр. Хезмәт баскычында күтәрелү яки башка юнәлеш белән китү ихтималы бик зур. Нәрсәнедер үзгәртергә телисез икән, фәкать үзегезгә генә таяныгыз, партнерлар арасында бигүк намуслы булмаганнары очрарга мөмкин.

 **АРЫСЛАН.** Үз-үзегездән, башкарган эшләрегездән канәгать калырсыз. Сез тырыштыгыз, булдырдыгыз, инде бераз ял итеп тә алырга була. Хезмәте иҗат белән бәйле булганнарга уңыш елмаячак.

 **СӨМБЕЛӘ.** Үзегезнең идеяләрегез һәм проектларыгыз өчен көрәшергә туры килер. Финанслар белән кыенлык килеп чыгарга мөмкин. Авырлыкларны йөрәгегезгә якын кабул итмәгез, ай ахырына таба тормышыгызда уңай чор башланачак.

 **БИЗМӘН.** Сәләтегезне күрсәтә торган ай. Яңалыкка омтылыш бик көчле. Һәр үзгәрешкә сабыйларча куанырсыз. Ләкин артык иркенәеп китмәгез тагын, үзгәрешләр яхшы булса да, кеше эшләр өчен яратылган.

 **ЧАЯН.** Якыннарыгыз белән аралашуда кыенлыклар килеп туарга мөмкин. Акчаны юкка-барга туздырмый торыгыз, югыйсә кайчак сез юмартланып китүчән. Иҗат итү өчен уңышлы ай, тик уңышларыгыз белән берәүгә дә мактанмагыз, күз тидерерләр.

 **УКЧЫ.** Ай-яй, кызыксынучан сез! Бу айда моңарчы бар дип тә белмәгән өр-яңа шөгылегез барлыкка килер. Бер сүз белән әйткәндә, октябрь – дөньяга карашыгызны киңәйтү, яңа гыйлем алу өчен бик тә әйбәт вакыт.

 **КӘҖӘМӨГЕЗ.** Күңелегез сәяхәткә, дөнья күрергә әйдәр. Һич югы күрше шәһәрдә яшәүче туганнарыгыз яки дусларыгыз янына барып кайтырсыз. Бу айда хезмәт баскычыннан күтәрелү яки тормыш шартларын яхшырту ихтималы зур.

 **СУКОЯР.** Яңа танышлар барлыкка килер, кызыклы яңалыклар булыр. Сезгә файда китерердәй кешеләр белән танышырсыз. Ерак юлга чыгу, тормышны үзгәртү өчен кулай вакыт. Эшен үзгәртергә теләүчеләргә уңыш елмаячак. Яңа эшкә күчү ихтималы бик зур.

 **БАЛЫК.** Катлаулырак ай. Бәхәсләр күп булыр. Бу ай уңышлы тәмамлансын дисәгез, үзегезне кулда тоту өчен күп көч куярга туры килер. Сезне ярсыткан нәрсәләргә игътибар итмичә генә, бар көчегезне эшкә багышлыйсыз икән, таулар күчерәчәксез.

сентябрьдә кабынган йолдызлар

Татарстан



Люция Фарсина (30.09.1930–4.03.2005) – **Татарстанның атказанган артисты.**
Казанда туа. 1951 елда Казан театр училищесын тәмамлап, Республика күчмә театрына эшкә килә. 1958–1961 елларда Г. Камал театрында эшли. Төрле елларда шулай ике сәхнәдә чиратлаштырып уйный. 1971 елдан кабат күчмә театрга кайта. Әйдәп баручы артистларның берсенә әверелә. Шук малайлардан башлап (Сәгыйть – «Кара йөзләр», М. Гафури), саф күңелле татар карчыгына кадәр (Зөлхия – «Кыр казлары артыннан», И. Юзеев) җиренә җиткереп уйный. Чит телдән тәрҗемә ителгән пьесаларда уйнаган рольләре дә ихлас. Мәсәлән, А. Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» пьесасындагы Кручинина ханым ролендә ул, әйтерсең лә, үз-үзен, үз тормышын уйный. Шундый ук көйләнмәгән тормыш, сәхнәгә булган шундый ук мәхәббәт, шундый ук кыенлыклар.
1980 елдан – ТАССРның халык артисты.

Россия



Лариса Рубальская (24.09.1945) – **шагыйрә, популяр җырлар авторы.**
Мәскәүдә туа. Белеме буенча рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Курсларга йөреп, япон телен үзләштерә, тәрҗемәче булып эшли. Җырлар авторы булып узган гасырның сиксәненче елларында танылa. Беренче җырын – Валентина Толкунова башкарган «Воспоминание»не – Владимир Мигуля белән берлектә яза. Сергей Березин белән иҗат иткән җырлары да күп. Җыр текстлары язудан тыш, кулинария белән мавыга, берара телевидениедә аш-су тапшыруын алып бара. Берничә рецептлар җыентыгы дөнья күргән.

Чит илләр



Агата Кристи (15.09.1890–12.01.1976) – **инглиз язучысы.**
Җир шарындагы иң атаклы язучыларның берсе. Әсәрләре 4 миллиардтан артык данәдә нәшер ителеп, дөньяның 100 теленә тәрҗемә ителгән. 66 роман, 19 хикәя китабы авторы. 16 пьесасы Лондон сәхнәләрендә уйнала. Торки шәһәрендә туган Агата яхшы белем ала, музыкага өйрәнә. Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында госпитальдә шәфкать туташы булып эшли. Соңрак фармацевт була. Шушы эшчәнлеге иҗатына нигез сала да инде – күп детективлары агулап үтерү тарихына корылган. Беренче романы – «Стайлздагы серле вакыйга» («Таинственное происшествие в Стайлз») 1920 елда языла. 1958 елда детективлар остасы үзенең Детектив йортын ача.

PRESSA.RU





АНЫҢ ЗӘҢГӘР МӘМЛӘКӘТЕНДӘ...

Иртәдән яңгыр койды. Очрашырга сүз куешкан идек. Кремльдә. Аның киндерләре вакытлыча яшәгән «Хәзинә» галереясында. Әйтәм ич, иртәдән үк яңгыр койды. Шул яңгырны үземә сеңдереп чапты-ы-ым! Шундый куе иде ул яңгыр, сутлы. Акварель булып кына сибәли башлады да, акрынлап җете, үзле майлы буяуларга әверелде...

Баскычлар... Залларга узам... Һәм... күзгә зәңгәр нур сирпелде. Түрдә – «Җиде кыз» картинасы. Янәшәдә генә – «Әйлән-бәйлән». Легендалардан киндергә күчкән төрки сылулар башта җирәнсу-кызгылт җир яссылыгында тымызык бию бииләр дә, зәңгәрсу нурга төренеп, югарыга, ап-ак яктылыкка таба агылалар. «Бу – минем хәзерге халәтем», – ди рәссам Алсу Тимергалина.

Уңгарак авышам – анда җәйге Казан сурәте. Җылы ләйсән яңгыр, күрәмсең, сибәләр-сибәләмәс кенә кагылып узган шәһәргә. Казансуның киндергә эләгеп калган читендә – салават күперенең бер очы. Караш – югарыдан. Юк, түбәдән дә, балконнан да түгел. Өстән. Кош биеклегеннәндер, бәлки? Әнә, рельслардан трамвай җилдерә, яшел машина каядыр юл тота, тротуар буйлап кулына чүпрәк букча элгән татар әбисе атлый, бер йортның диварына сәпит сөяп куелган. Шул сәпит мине үзенә ымсындыра, мин аңа атланып, салават күперенә тоташып диярлек утырган мәчеткә таба җилдерәм... «Миндә иске Казан сурәтләре күп инде ул...» – рәссам тавышы мине «Хәзинә» галереясына кайтара.

Аннан без Шүрәлеләргә килеп төртеләбез. Миңа аларның шаянлыгы ошый. Җиңеллеге. Алар бер дә усал түгелләрдер кебек. Менә бахбаен җигеп бер агай авыл урамы буйлап бара. Дөньяның зәңгәр, урманлы ягыннан мут, наян карашы белән аңа агачлар һәм Шүрәле бага...

«Кайчан да булса Шүрәлеләрне төшерермен дип башыма да китермәдем, – дип көлә рәссам. – Әмма андый уй бер йөгереп узды. Һәм мин уйлап куйдым: бәлки, төшерермен дә мин аны, әмма ул бөтенләй башка булыр, дип. Менә бит, язмыш, «Татарстан китап нәшрияты»нда балалар китапларына иллюстрацияләр ясаганда, Шүрәле белән күрешергә насыйп булды...»


Карашым каршы як диварга төшә – анда мине ялгыз көймә һәм яңгыр астында калган ялгыз пристань җәлеп итә. «Әстерханда бу, – ди картинаның хуҗасы. – Анда гел яңгырлы булды. Кайтып төшкәч тә мин башта көймәне ясадым, пристань да ияреп кайткан булып чыкты. Шушы яңгырлар аша юл алдым мин тарихка, мифологиягә, этнографиягә...»

...«Сөембикә» журналында эшләгән чакларын сагынып искә алды: «Сөембикә эзләреннән» дигән проектыбыз бар иде. Касыймга бардык, аннан Сарай-Батуга... Төрки тамырларга орынуым шул чаклардан ук килә дер, мөгаен, Әстерхан яңгырларыннан...»


Рәссам белән бик озаклап сөйләшеп утырдык. Әтисе Адлер Тимергалинны искә алды, аның белән тулы бер дәвер киткәндәй булды, дип уфтанды. Ул киткәч тә әле берара аның мәмләкәтендә ялгызым басып тордым. Хуҗалары киткәч, сурәтләрнең карашы мине үтәли тишә башлады. Алар инде хәзер рәссам тәэсирләрен түгел, бары үз тарихларын гына сөйли, бары үз мәгънәләрен генә яудыра иде...


Луиза ЯНСУАР












АЛСУ ТИМЕРГАЛИНА

Язманы тулысынча сайтыбызның «Галерея» сәхифәсеннән укый аласыз.

PRESSA.RU



МАССАКҮЛӘМ МАТБУГАТ ЧАРАЛАРЫ БӘЙГЕСЕ



ЛЕГЕНДАЛАРНЫ БЕЛЕГЕЗ!
БРЕНДЛАРНЫ САЙЛАГЫЗ!

ТМ татмедиа

ЛЕГЕНДАР БРЕНДЛАРЫ

TATMEDIA.RU САЙТЫНДА
ТАВЫШ БИРҮДӘ КАТНАШЫГЫЗ



ДҮРТ НОМИНАЦИЯДӘ ТАВЫШ БИРЕРГӘ МӨМКИН:

- ЛЕГЕНДАР **ГАЗЕТА**
- ЛЕГЕНДАР **ЖУРНАЛ**
- ЛЕГЕНДАР **ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯ**
- ЛЕГЕНДАР **МУЛЬТИМЕДИЯЛЕ РЕДАКЦИЯ**

TATMEDIA.RU — ТМ татмедиа

Реклама, 16+. Акцияне оештыручы – "ТАТМЕДИА" АҖ. Үткәрү сроклары һәм акция турында тулырак мәгълүмат www.tatmedia.ru сайтында.



КОНКУРСНЫҢ ГЕНЕРАЛЬ ПАРТНЕРЫ:
«ПРОСТО МОЛОКО» ИК ҖЧҖ

ЯРАТКАН ЖУРНАЛЫБЫЗ ӨЧЕН ТАВЫШ БИРЕРГӘ СОҢЛАМАГЫЗ!
«СӨЕМБИКӘ» ИСЕМЕН БЕРГӘЛӘП ТАНЫТЫЙК!